ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№01 (384)
ГЫЙНВАР 2024

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ИЛНЕҢ ТЕХНОЛОГИК ИМИНЛЕГЕ САГЫНДА

Республиканы руда булмаган төзелеш материаллары белән тәэмин итәбез!

20 елдан артык безнең компания эре төзелеш компанияләренә, торак һәм автомобиль юлларын төзүче оешмаларга, тимер-бетон эшләнмәләр заводларына, физик һәм юридик затларга материаллар китерә. Без ышанычлы тәэминатчы абруен казандык, югары профессиональлеккә ия команда оештырдык, руда булмаган төзелеш материалларын җитештерү һәм сату тармагында бай тәҗрибә тупладык.

Продукциянең сыйфаты
Безнең продукция берничә параметр буенча ГОСТ таләпләреннән югарырак

Зур запаслар
Без сәгатенә 1000 тоннага кадәр материал озатабыз

Заказга материаллар
Без соралган характеристикалар буенча теләсә кайсы материалны җитештерә алабыз

Шулай ук төрле фракциядәге башка руда булмаган материаллар да бар

КАЗАНСКИЕ НЕРУДНЫЕ МАТЕРИАЛЫ

«Казан руда булмаган материаллар» ҖЧҖ
Тел. +7 (843) 207-10-00
Адрес: Казан ш., Магистраль ур., 66 корылма
E-mail: sales@knm.com.ru

www.knm.com.ru

Реклама

КАЗАНСКИЕ НЕРУДНЫЕ МАТЕРИАЛЫ

Татарстанда руда булмаган материаллар җитештерәбез һәм китереп бирәбез

Тиздән Яшел Үзәндә руда булмаган төзелеш материалларын төяп озату буенча яңа база ачылачак!



РБТМ саклау:	РБТМ эшкәртү:	РБТМ автотранспортта озату:	РБТМ тимер юл аша озату:
500 000 тоннадан артык РБТМ	300 000 тоннадан артык РБТМ	Тәүлегенә 10 000 тоннага кадәр төяп озату	Тәүлегенә 50 вагонга кадәр төяп озату

Машинага тиз һәм төгәл итеп төяү

Төяп озатуларны контрольдә тоту өчен Шәхси кабинет

Менеджерның персональ ярдәме



Яндекс Картада объектны карау

Күмәртәләп сату бүлегендә заказ ясау өчен:

+7 (843) 207-10-00

КАЗАНСКИЕ НЕРУДНЫЕ МАТЕРИАЛЫ

«Казан руда булмаган материаллар» ҖЧҖ

Тел. +7 (843) 207-10-00
Адрес: Казан ш., Магистраль ур., 66 корылма
E-mail: sales@knm.com.ru

www.knm.com.ru

Реклама

№01 (384)
ГЫЙНВАР 2024

16+

Редакция:
420066, Россия, ТР,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов,
Евгения Чеснокова, Дмитрий Сивков
Авторлар: Гомәр Даутов, Илдус Зәһидуллин, Наилә
Хәйретдинова, Әхмәт Шакиров, Луиза Янсуар
Фотографлар: Александр Ефремов, Александр Эшкинин,
Алсу Шакирова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова, Игорь Глушков
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: «Лаеш техника-икътисад техникумы»
ДАҺБУ студенты, басмабызның телеграм-каналында
уздырылган #НаОбложкуТатарстана конкурсы
җиңүчесе Всеволод Черенков
Анна Арахамия **фотосы**

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек
буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы
ПИ № ФС77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә
мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция
җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Россия, ТР, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: С-3517
Басарга кул куелды: 19.01.2024
Чыгу көне: 25.01.2024

РЕДАКЦИЯДӘН

ТАМЫРЛАРЫБЫЗ – АВЫЛДАН

Без барыбыз да авылдан чыккан. Тирән тамырларыбыз шунда береккән. Шуңа күрә редакциябездә күркәм бер гадәт яши – ай саен берәр авылга барып кайтмасак, журнал чыкмас кебек. Кышмы-җәйме, язмы-көзме, һава торышы матур булган бер көнне сайлап, сәфәргә кузгалабыз. Шушы еллар эчендә «Татарстан» журналы республикабызның йөздән артык авылында булды. Араларында кызык исемлеләре дә, кечкенәләре дә, зурлары да бар. Әмма кая гына барып чыксак та, безне уңган, булган авыл кешеләре каршы ала. Аларның һөнәрләренә, тырышлыкларына, тормыштан ямь табып, бүгенге катлаулы чорда да матур итеп яши белүләренә хәйран калабыз. Һәм үзебезгә көч җыеп, матур тәэсирләр алып кайтабыз. Бу юлы Арча районының Пөшәңгәр авылына тукталдык. Чагыштырмача кечерәк кенә сала үзенең төзеклеге, халкының дус, тырыш булуы белән сөендерде. Авылга ике яшь укытучы кайткан. Менә бу вакыйга! Элек булса, моңа игътибар да итмәс идек. Бүген исә яшь укытучының чит авылга килеп, бер апага яшәргә кереп, мәктәптә эшләве гайре бер хәл кебек. Әле аның шунысы кызык: авылда «квартирга керү» дип сөйләшәләр. Югыйсә монда квартиралар юк та бит. Без үскәндә дә авылда «квартирда яшәүче» яшь укытучылар бар иде. Гадәттә укытучы кызларның күбесе шунда кияүгә дә чыгып кала. Саланың тагын бик күп шундый кызыклы, үзенчәлекле күренеш, традицияләре бар. Алар яшәсен, югалмасын иде!

Сезнең авыл яратучы редакциягез

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Алина Майорова,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9033-132-741
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә
тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ
420097, Россия, ТР, Казан,
Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына ТРның барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин:
Индекс **П2381** – татар телендә ярты елга
Индекс **ПА468** – татар телендә бер елга

Индекс **П2378** – рус телендә ярты елга
Индекс **ПА471** – рус телендә бер елга

2024 елның яртыеллыгына ТР буенча язылу бәясе:
1212 сум 00 тиен китереп бирешлә,
1175 сум 40 тиен соратып алганда.
2024 елга ТР буенча язылу бәясе:
2423 сум 92 тиен китереп бирешлә,
2350 сум 66 тиен соратып алганда.

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 103 ЯШЬ

ТАТАРСТАННЫҢ 100 ҖӘУҺӘРЕ

БАРЫ ТИК ТАТАРСТАНДА

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ПРЕЗИДИУМА ЦЕНТРАЛЬНОГО ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА СОЮЗА ССР

О НАГРАЖДЕНИИ ОРДЕНОМ ЛЕНИНА РЯДА РЕСПУБЛИК, КРАЕВ И ОБЛАСТЕЙ

Президиум Центрального исполнительного комитета Союза ССР постановляет:

За выдающиеся успехи в деле проведения основных сельскохозяйственных работ (сев, уборка урожая, засыпка семян), по укреплению колхозов и совхозов и выполнению обязательств перед государством,—наградить орденом Ленина:

Кабардино-Балкарскую автономную область Северокавказского края;
Татарскую автономную советскую социалистическую республику;
Западносибирский край;
Московскую область;
Горьковский край и
Крымскую автономную советскую социалистическую республику.

Председатель Центрального исполнительного комитета Союза ССР **М. КАЛИНИН.**
Секретарь Центрального исполнительного комитета Союза ССР **А. ЕНУКИДЗЕ.**

ҖИҢГӘН КОЛХОЗЛАРГА ГИМН

Җәмгатьләштерелгән кырларның һәр гектарыннан җыелган 10 центнер ашлык һәм күмәкләшү дәрәҗәсенең 90 проценттан артып китүе… Авылны тамырдан үзгәртеп кору барышында 1933 ел ахырына ТАССР ирешкән саннар шундый. Әлеге казанышлар яхшы бәяләнә. 1934 елның 3 гыйнварында автономияле республика СССРның иң югары бүләге – Ленин орденына лаек була. СССР Үзәк Башкарма комитеты Президиумы Указында: «Төп авыл хуҗалыгы эшләрендәге (чәчү, уңыш җыю, чәчүлеккә орлык салу), колхоз һәм совхозларны ныгытудагы һәм дәүләт алдындагы йөкләмәләрне үтәүдәге зур уңышлары өчен» дип язылган. Социалистик үзгәртеп корулар барышында авылда юкка чыгарылган 14 меңгә якын хәлле крестьян хуҗалыгы, республикадан читкә сөрелгән, атылган, махсус поселениеләрдә үлемгә дучар ителгән дистәләрчә мең гаилә турында Указда, әлбәттә, әйтелми.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

6. Күтеп алынган юл
«Көнчыгыш» М-12 тизйөрешле трассасы кай ягы белән шаккатырды

14. Корылыклы ел рекордлары
Табигать сынауларына авыл хезмәтчәннәре ничек каршы тора алды

32. Кукмара феномены
Сөтчелек терлекчелегендә рекордларга ничек ирешәләр

36. Уңыш сере
Икмәк бизнесында ничек сынатмаска

42. Кадрларга кытлык
Республика икътисадына нинди кадрлар таләп ителә

44. Иң югары пилотаж
Пилотсыз очкычлар белән идарә итәргә кайда өйрәтәләр

игелекле эшләр

48. Гамьле әңгәмә
Академик кайчан ял итә

54. «Стейнвей»лар табибы
Мацуев уйнаган рояльне кем төзәтә

56. Тормышка ашкан хыял
Иске «Запорожец»ның элеккеге данын ничек кайтарырга

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: **protatarstan.ru**

мәңгелек кыйммәтләр

62. Замана чире
Алдакчылар тозагына ничек эләкмәскә

66. Тарихи сәхифә
Хәсән Туфан кемне «аяклары бәйле Прометей» дип атаган

70. Китап киштәсе
«Кышкы» китаплар арасында нәрсәләр бар

74. Әдәбият дөньясы
«Тормыш яме»

78. Татар авыллары
Пөшәңгәр авылында ни өчен яшьләр кала

Фото: kazan-history.livejournal.com

Акыллы гамәлләр



30.12

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Рәисе, – татарстанлыларга Яңа ел уңаеннан мөрәҗәгатендә:

– Республика алгарышында фән һәм инновацияләрнең мөһим ролен танып, 2024 ел Татарстанда Фәнни-технологик үсеш елы дип игълан ителде. Әйдәп баручы фән һәм мәгариф үзәкләренең эшчәнлеге, талантлы яшь галимнәргә һәм өстенлекле фәнни башлангычларга ярдәм күрсәтү бу өлкәдәге казанышларыбызның тагын да артуына китерер һәм илнең технологик яктан бәйсезлегенә ирешү мөмкинлеге бирер, дип ышанам.

15.12

Антон Силуанов, Россия финанслар министры, – ТР Финанслар министрлыгы, Федераль салым хезмәтенең ТР буенча Идарәсе, Федераль казначылыкның ТР буенча Идарәсенең уртак коллегиясендә:

– Без технологик суверенитетны тәэмин итү буенча күп кенә бурычларны тормышка ашырабыз. Республикада да моңа зур игътибар бирелә. Бу станоклар төзү, авиация тармагы, пилотсыз аппаратлар. Бу юнәлешләргә игътибар да, федераль ресурслар да бирелә. Бу юнәлешләр республикада эшләячәк. Шул исәптән оборона-сәнәгать комплексын модернизацияләү, ул хәзер махсус хәрби операция бурычларын тәэмин итү өчен мөһим. Болар барысы да монда эшли, Татарстан Республикасында үсеш алган.

Игелекле эшләр

Мәңгелек кыйммәтләр

25.12

Ирада Әюпова, Татарстан Республикасы мәдәният министры:

– Бүген без «кәсеп», «сувенир» төшенчәләрен тигезләүдән туктадык, халык сәнгать кәсепләренә туристларга нәрсәдер күрсәтү күзлегеннән генә карамыйбыз, мин моңа бик шат. Традиция – ул без. Әгәр без баштан ук үз яшәү мохитебезне нейтраль ясап, аны үзенчәлекләрдән мәхрүм итсәк, ул үз йөзен җуячак. Без әлеге мохитнең үз йөзен югалта баруын туктатуга ирештек.

Фото: rais.tatarstan.ru, kremlin.ru, tatar-inform.ru

игелекле эшләр
акыллы гамәлләр
мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

«Көнчыгыш» юлыннан Мәскәүгә **күпме** барырга

Табигать сынауларына бирешмичә, **ничек** 3,7 миллион тонна ашлык җыеп алырга

Кукмара **ни рәвешле** итек басуны ясалма интеллект белән бәйләп эшли

Республика икътисадына **нинди** кадрлар җитми

Илнең технологик бәйсезлеген **кем** тәэмин итә



«КӨНЧЫГЫШ» М-12: КРЕМЛЬДӘН – КРЕМЛЬГӘ

Тизйөрешле «Көнчыгыш» М-12 трассасы ачылуга ук тарихка керде. Безнең илдә моңарчы беркайчан да шундый озынлыктагы һәм шулкадәр югары сыйфатлы юлның нибары өч ел эчендә төзелгәне юк иде әле. Хәзер Казаннан Мәскәүгә кадәр 810 километр араны алты сәгать ярымда үтеп була. Әлеге магистраль бер-берсенә тагын да якынайган төбәкләр икътисады үсешенә дә куәтле этәргеч бирер, дип фаразлана.

Әскәр Сабиров

Мондый шәп юлны мактау өчен аның турындагы фактларны укып белү генә җитми. Үзеңә сынап карарга кирәк, менә шул чакта рәхәтләнеп фикереңне әйтә аласың. Рөстәм Миңнеханов юлның рәсми ачылышына бер көн кала нәкъ шулай эшләде дә. Йөреп караганнан соң, соклануын яшермәде:

– Әлегә кадәр мондый юлны күргәнем юк иде – бу бөтенләй башка сыйфат, башка ил, – дип тәэсирләре белән уртаклашты Татарстан Рәисе. – Хезмәт күрсәтү урыннарында дүрт тапкыр туктадым, ягулык салдым – барысы да бик яхшы уйланылган. Юл өчен автомат түләтү системасы да эшли. Барысы да иң югары дәрәҗәдә!

Республика башлыгының профессиональ автоузышчы булуы беркемгә дә сер түгел. Димәк, ул үз гомерендә бик күп юл күргән һәм сынаган кеше – яхшыларын да, начарларын да. Шуңа күрә аның фикере бик мөһим. Мөгаен, нәкъ менә Миңнехановның трасса ачылышы тантанасында (ул видеокүпер форматында үтте) ясаган тәэсирле чыгышы Россия Президентын да кызыктыргандыр:

– Сездән көнләшәм бераз, кайчан да булса үзем дә бу юлдан бер әйләнермен дип өметләнәм, – диде Владимир Путин.

Рөстәм Миңнеханов «Көнчыгыш» М-12 магистрален «Аурус» автомобилендә сынады, һәм ул Татарстан территориясе аша үткән 142 километр белән генә чикләнмәгәндер кебек тоела. Һәрхәлдә, пилот үзе тиешледән бераз артыграк тизлектә җилдерүен яшерми. «Аурус»та? «Бераз гына» артыграк тизлектәме? Казаннан Мәскәүгә кадәр түгелме? Хәер, хәзер моны теләгән һәркем эшли ала. Влади-

Фото: Александр Ефремов, tatar-inform.ru, tatarstan.ru

мир Путин фатихасы белән «Көнчыгыш» М-12 трассасы рәсми рәвештә ачылды.

КИЛӘЧӘККӘ КҮПЕР

Яңа трассадан Мәскәүгә юнәлгән беренче машиналарны озату урыны бик шәп сайланган иде. Казаннан ерак түгел Идел аша салынган яңа күпер янәшәсеннән кузгалды машиналар. Әлеге күпер – барлык 800 километрлы участокта иң зур һәм мәгърур корылма. Инженерлык фикеренең чын могҗизасы! Озынлыгы 3,3 км булган күперне салганда киләчәк технологияләреннән файдаланганнар.

Инде өч дистә ел буе Татарстан халкы хыялланган әлеге күпер чыннан да һәркемне таң калдырырга сәләтле, дип уйлыйм. Аның иң куәтле терәге су өсте тигезлегеннән 14 катлы йорт биеклегендә күтәрелгән. Тагын 17 метры су астына яшерелгән, ә нигезе, 33 метры, инде су төбендәге туфракта урнашкан. Корылманы төзү вакытын ярты елга киметә алганнар: бу вакытлыча күперләр кую һәм терәкләргә торыкларны берьюлы ике яктан сузу хисабына мөмкин булган.

Хәер, эшләнгәннәрнең колачына һәм тизлегенә бәя бирер өчен, технология нечкәлекләренә төшенергә тырышу кирәк тә түгел. Гади чагыштырып карау җитә. «Көнчыгыш» М-12 трассасындагы күпер – ике ел ярымда, ә шул ук Идел аша Займище бистәсе янындагы аннан өч тапкырга кыскарак корылма сигез ел төзелгән. Чулман елгасы аша Саескан Тавы янындагы күперне төзи башлау белән беренче чиратын файдалануга тапшырганчы исә бөтенләй унике ел вакыт үткән.

СУПЕРАСФАЛЬТ ҖӘЕЛГӘН ЮЛ

«Көнчыгыш» М-12 трассасында уникаль корылмалар шактый. Татарстан территориясендә төзелгәннәреннән тагын Зөя аша күперне дә әйтеп китәргә кирәк. 1,3 километр озынлыктагы корылма биеклекләре 21 метрдан 36 метрга кадәр булган җиде куәтле терәккә урнаштырылган, рельеф катлаулылыгы төзүчеләрне хикмәтле технология кулланырга мәҗбүр иткән, һәм шул рәвешле күпер-

не салу вакыты бер ярым тапкырга кыскарган. Әмма иң мөһиме менә нәрсәдә: күпер Казаннан чагыштырмача ерак урнашкан Кайбыч һәм Апас районнарын Югары Ослан белән тоташтырган, һәм хәзер алардан ТР башкаласына кадәр бик тиз килеп җитеп була.

Яңа юлдан сәгатенә 110 километр тизлек белән баручы машина йөртүче трассаның бөтен уңайлыкларын әле шәйләп бетермәскә дә мөмкин. Мәсәлән, Татарстан территориясе аша үткән 142 километрлы участокта гына да юл өстендә җиде экодук (күпер), ә астында дүрт тоннель төзелгән. Беләсегез килсә, бу зур тизлекле цивилизацияле магистральләр өчен мәҗбүри булган корылмалар, менә хәзер алар ниһаять бездә дә бар. Экодук һәм тоннельләр хайваннарның юлны имин кичүе өчен кирәк. Трасса кырыеның 270 километрын киртәләп алу да шул максаттан: хайваннар да, башсыз җәяүлеләр дә сиздермәстән генә юлга килеп чыга алмаячак, һәм һәлакәтләр булмаячак...

«Көнчыгыш» М-12 трассасы әле – камил чистарту корылмалары да ул: юлдан җыелган сулар биш тапкыр чистартыла. Шулай ук биргә биоматлар – үлән орлыклары тутырылган геотекстиль материаллар куелган: андагы үсемлекләр шытып, тамырлары белән туфракны ныгытып, аны юылудан саклаячак. Трассаның тагын бер өстенлеге – ул буеннан-буена яктыртыла. Барлык кирәкле урыннарга җәяүлеләр өчен кичүләр җайланган. Юлда чатлар бөтенләй юк. Кирәге чыкканда машина йөртүчене кисәтергә сәләтле махсус структуралы юл билгеләре хакында да әйтми булмый...

Идеаль тигез юл катламы – аерым бер җыр. Аны яңа Россия ГОСТы буенча салганнар, нигезендә Американың Superpave – Superior Performance Pavements күләмле-функциональ проектлау технологиясе ята. Ул чын супермагистраль төзү мөмкинлеген бирә. Гади ремонтка кадәр ул кимендә 12 ел, иң беренче капиталь ремонтка кадәр исә 24 ел чыдарга тиеш. Төгәллек кертик: сүз юлның нигезе хакында бара – өске катламны тузган саен алыштырырга кирәк булачак. Әмма М-12 юлындагы асфальт-бетон гадиеннән күпкә чыдамрак, шунлыктан трассада тәгәрмәч эзләре һәм чокыр-чакырлар пәйда булыр дип һич кайгырасы юк.

ҮЛСӘҢ ҮЛ, ТИК ВӘГЪДӘҢНЕ ҮТӘ!

«Көнчыгыш» М-12 трассасында тормышка ашырылган технологик һәм конструкторлык могҗизалары турында автоюлны төзүчеләр тәфсилләп һәм сәгатьләр буе сөйләргә әзер. Ә инде киеренке графикка чыдау өчен ничек тырышырга, нинди гадәти булмаган оештыру карарлары кабул итәргә туры килүе турында искә төшерергә яратмыйлар. Мәсәлән, төзелеш башланганда һава торышының хикмәтләре хакында. Декабрьдә кинәт көчле суыклар башлана ул чакта.

– Күз алдына китерәсезме, 30 градуска кадәр суытты, туң җиргә бернәрсә дә кертеп булмый башлады, – дип сөйләде ТР транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Хәнифов. – Татарстандагы бөтен төзелеш оешмаларыннан җиһазлар җыйдык, бораулаадык, әмма барыбер җиңеп чыктык!

Аннары тагын бер катлаулы бурыч пәйда була. Әзер бетонга юл билгеләре төшерү өчен, суыкта андагы бозны ничек эретергә соң? Бу юлы да аптырап калмыйлар. Объектка реактив двигательләр алып киләләр. «Двигатель полоса буйлап бара, асфальтны җылыта. Ул җылынгач, билгеләр төшерелә. Суыкта төзүчеләр менә шулай эшләде. Мин үзем дә сокландым: эшне вакытында өлгертү өчен, хезмәткәрләр шулкадәр җаваплылык тоеп эшләде! Үлсәң үл, тик вәгъдәңне үтә! Бик тырышып эшләделәр», – ди министр.

ЮЛ ТӨМӘНГӘ ИЛТӘЧӘК!

Вакытында өлгерттеләр. Мәскәүдән Казанга кадәр трассаны инде Яңа ел бәйрәме алдыннан ук меңнәрчә машина йөртүче сынады. Юлны гына да түгел, андагы күпфункцияле ял итү һәм ягулык салу зоналарын да. Кафелар, кунакханәләр, душ куелган ял итү урыннары, заманча ягулык салу станцияләре, хәтта намаз бүлмәләре – болар барысы да тиздән түләүле магистраль өчен инде күнегелгән сервиска әйләнәчәк. Бер шлагбаумы да булмаган «Свободный поток» дистанцион түләү системасы кебек үк. Ул инде «Көнчыгыш» магистраленең буеннан-буена эшли, ә менә күпфункцияле ял итү һәм ягулык салу зоналары әле бөтен җирдә дә юк. Дөрес, Татарстанда аларның әзерлеге яхшырак. Алты күпфункцияле зонаның дүртесе инде ачык, тагын икесе быел ачылачак.

Бүген иртәнге аштан соң Казансу ярында йөреп кергәч, сез идеаль бетон юл буйлап ашыкмыйча гына Түбән Новгородка барып җитә һәм андагы Покровкада төшке аш белән сыйлана, аннары инде тагын өч-дүрт сәгать барганнан соң Кремльнең рубин йолдызлары белән хозурлана аласыз. Шәп бит, ә?

Бу әле башы гына. Инде быел ук магистраль Екатеринбургка барып җитәчәк – хәзер төзелә торган Яр Чаллы һәм Түбән Каманы урап үтү юллары, Чулман аша күпер аның бер өлешенә әйләнәчәк. Ә 2025 елда «Көнчыгыш» М-12 федераль трассасы Мәскәү, Казан, Екатеринбург һәм Төмәнне тоташтырачак, аның гомуми озынлыгы 1980 километр тәшкил итәчәк. Бу «Россия» халыкара транспорт маршрутының төп участокларыннан берсе булачак. Безнең мәңгелек бәла-казаларыбызның берсеннән котылыр көнгә дә ерак калмый, күрәсең.

ВЛАДИМИР ПУТИН, РФ ПРЕЗИДЕНТЫ:

– Бүген без «Россия» халыкара, Евразия транспорт маршрутының бер өлешенә әйләнәчәк «Көнчыгыш» М-12 трассасын эшләтеп җибәрүгә таба тагын бер мөһим адым ясыйбыз. Мәгълүм булганча, әлеге магистральне без этаплап тапшырачакбыз, сентябрьдә Мәскәүдән Арзамаска илтүче юл ачылган иде. Бүген исә иң зур туристлык, мәдәният, эш үзәкләре булган Мәскәү белән Казан арасындагы заманча, югары тизлекле автострада тулысынча әзер. 800 километрдан артыграк юлны якынча алты сәгать ярымда үтеп булачак, бу элеккедән ике тапкырга диярлек тизрәк.

МАРАТ ХӨСНУЛЛИН, РФ ХӨКҮМӘТЕ РӘИСЕ УРЫНБАСАРЫ:

– Без Мәскәүдән Казанга кадәр «Көнчыгыш» М-12 федераль трассасын – идеясеннән объектны теркәүгә кадәр – нибары өч елда төзедек. Ил тарихында күрелмәгән хәл бу, дөньяда да мондый мисаллар күп түгел. Магистраль «Россия» халыкара транспорт маршрутының бер өлеше булып тора, һәм М-12, торак төзелеше, сәнәгать үсешенә куәтле этәргеч кенә булып калмыйча, башка мөһим транспорт проектлары белән дә бәйләнешне дә тәэмин итәчәк. Президентка, Хөкүмәт Рәисенә, үз командалары һәм «Автодор» дәүләт компаниясе белән бергә М-12 юлының Казанга кадәр өлешен тиз арада төзүне тәэмин иткән төбәк башлыкларына рәхмәтемне җиткерәм.



РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ, ТР РӘИСЕ:

– Трассаның республика аша сузылган озынлыгы 142 километр тәшкил итә, бу җиденче һәм сигезенче участоклар. Әлеге масштаблы проектта Татарстаннан 5 меңнән артык эшче һәм 1400 берәмлек техника катнашты. 67 ясалма корылма төзелде. Шулай ук Идел аша озынлыгы 3,3 километрлы яңа күпер дә салынды.

ВЯЧЕСЛАВ ПЕТУШЕНКО, «АВТОДОР» ДӘҮЛӘТ КОМПАНИЯСЕ ИДАРӘСЕ РӘИСЕ:

– «Көнчыгыш» М-12 магистрале – 820 километр озынлыктагы зур тизлекле юл ул. Бер генә светофор да, бер генә чат та юк. Без тагын гомуми озынлыгы 24,5 километрлы 323 ясалма корылма да төзедек. Тик бу әле техник мәгълүматлар гына бит, ә без, юл төзеп кенә калмыйча, тулы кыйммәтле инфраструктура да булдырдык. М-12 трассасында инде 18 күпфункцияле зона эшли, аларда уңайлы парковкалар, ягулык салу станцияләре, кафелар, спорт һәм балалар мәйданчыклары, йорт хайваннарын йөртү урыннары, автобуслар өчен инфраструктура, хәтта душ һәм кер юу бүлмәләре дә бар. Киләчәктә исә бу юлда барлыгы 32 күпфункцияле зона булачак.

Декабрьдә «Көнчыгыш» магистрале Мәскәүне Казан белән тоташтырды һәм «Европа – Көнбатыш Кытай» халыкара транспорт коридорына керде. Әлеге гаять күләмле проектка зур өлеш керткән компанияләрдән берсе – «Волгадорстрой» ҖЧҖ.

«ВОЛГАДОРСТРОЙ»ДАН М-12 ЮЛЫНЫҢ БИШ ИҢ МӨҺИМ КҮРСӘТКЕЧЕ

Казан юл төзүчеләре эшенең иң мөһим аспектларын аерып күрсәтү зарур:

1. Яңа түләүле автомобиль юлының Чувашия һәм Татарстан территорияләрендәге озынлыгы 41 километр тәшкил итә. М-12 трассасы республикабыздагы өч муниципалитет аша түбәндәге торак пунктлар яныннан үтә: Коргуза авылы (Югары Ослан районы), Югары Аккуҗа авылы (Апас районы), Зур Колангы бистәсе, Мөрәле, Федоровское, Кошман авыллары аша Олы Кайбычка (барысы да – Кайбыч районы) таба килә.

2. «Волгадорстрой» компаниясе төзелеш-монтажлау эшләрен билгеләнгән вакыттан алданрак төгәлләде, участокта юл хәрәкәте планлаштырылганнан 6 айга алданрак башланды. Әлеге уңышка проектның барлык этаплары белән – планлаштырудан алып гамәлгә кертүгә кадәр – дөрес идарә итү нәтиҗәсендә ирешеп булды. Компания җитәкчелеге бик кыска вакыт эчендә – 2021 елның мартыннан алып 2023 елның декабренә кадәр арада куелган бурычларны үтәр өчен барлык ресурслардан нәтиҗәле файдалануны тәэмин итте. Хезмәт ресурсларын җәлеп итү, логистика чылбырларын эшләү һәм кертү, җитештерү процессларын оптимальләштерү, махсус төзелеш техникасы сатып алу һәм файдалану, шулай ук инерт материаллар, асфальт кушылмалары, металл, бетон һәм тимер-бетон конструкцияләрне китереп җиткерү мәсьәләләре барысы да уңышлы хәл ителде.

3. «Волгадорстрой» ҖЧҖ участогында барлыгы 19 күпер һәм юлүткәргеч бар, шул исәптән Имәле елгасы аша 1 күпер һәм 4 юлүткәргеч үз көчләре белән төзелгән. Барлык ясалма корылмаларда да торыклар 17 200 кубометрдан артыграк монолит бетоннан проектланган һәм башкарылган, ә әлеге объектларда кулланылган корыч арматура, металл эшләнмәләр һәм конструкцияләр күләме 1650 тоннадан арта.

4. Төзелеш-монтажлау эшләре гаять зур күләмдә башкарылган. Аерым алганда, автоюлның буеннан-буена барлыгы: 5 287 350 кубометр җир казып алынган; 3 648 330 кубометр туфрак ташылган һәм тыгызландырылган; асфальт-бетон кушылмасыннан 914 000 кубометрдан артыграк өске катлам җәелгән; гомуми озынлыгы 118 000 метрдан артыграк металл киртәләр куелган; кисешә торган 11 автомобиль юлы өр-яңадан җайланган.

5. Компаниягә куелган бурычларны үтәргә үзенең алдынгы җитештерү базасы мөмкинлек бирә: аның 5 асфальт-бетон заводы, тимер юл инфраструктурасы, елга причаллары һәм үз елга флоты, 526 берәмлек юл-төзелеш техникасы бар. Компания яңа заманча техника сатып алуга һәм җитештерүне киңәйтүгә даими инвестицияләр кертә. Әмма юл төзелешендә заманча җиһазлар һәм технологияләр белән генә уңышка ирешеп булмый әле. «Волгадорстрой» компаниясе – ныклы белемгә һәм юл төзелешендә зур тәҗрибәгә ия профессионаллар командасы ул. Бүген коллективта 1865 хезмәткәр эшли, алар үз квалификацияләрен даими күтәрә, эшнең өр-яңа ысулларын үзләштерә һәм белемен арттыра.

«Волгадорстрой» компаниясе үз заказчылары өчен ышанычлы һәм тотрыклы партнер булып тора. Эшнең югары сыйфаты, заказларны вакытында үтәү һәм һәр клиентка шәхси якын килү нәтиҗәсендә ул күпсанлы заказчыларының ышанычын яулады һәм Россиядәге юл төзелеше базарында әйдәп баручылардан берсенә әйләнде.

«Волгадорстрой» ҖЧҖ фотосы. РЕКЛАМА

www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
Финансовая грамотность
Реклама 16+

РУДА БУЛМАГАН МАТЕРИАЛЛАР УРМАН ГАВАНЕННАН КИТӘ

Дмитрий Сивков

Руда булмаган төзелеш материаллары базарындагы четерекле хәлнең сәбәбе ни белән бәйле? Хәбәрчебезнең «Казан руда булмаган материаллар» компаниясе хуҗасы Рафис Шингәрәев белән әңгәмәсендә бу мәсьәлә дә кузгатыла.

Житәкченең эш бүлмәсендә бер якта – маркер такталары. Аларда – кулдан ясалган санлы колонкалар һәм озын уклы схемалар. Икенче якта интерактив мәгълүматлы плазма панеле урын алган. Болар барысы да төзелеш индустриясе материалларының үткәнен, бүгенгесен һәм киләчәген колачлаган әңгәмәбез темасын ап-ачык күрсәтеп тора сыман.

– Рафис Хәмитович, руда булмаган материалларга бәяләр, кайвакыт аларга кытлык быел төзелеш тармагы өчен кәефне кыра торган сюрприз булды. Моның сәбәбе нәрсәдә?

– Монда өч мөһим факторны билгеләп үтәргә кирәк. Беренчедән, соңгы өч елда республикада төзелеш күләме 20-30 процентка түгел, ә күп тапкырга артты, һәм бу, үз чиратында, руда булмаган төзелеш материаллары базарында кытлыкка китерде. Икенчедән, Идел һәм Чулмандагы суның биеклеге коточкыч дәрәҗәдә төшү дә вазгыятьне кискенләштерде. Өстәвенә, моңарчы һич күрелмәгән хәл: елгалардагы су навигация чорының уртасында ук кимеде.

Бу судноларның йөк ташу тоннажына йогынты ясады, алар йөк төяләп бетмәгән килеш йөрде, чөнки кайбер сай урыннарда утырып калырлар иде.

Ул гына да түгел, причалларга якын килү урыннары да саекты. Корабның суда утыру тирәнлеге кимету өчен, партнерларыбыз йөкнең бер өлешен ярга яки башка судноларга күчереп төяргә мәҗбүр булды. Руда булмаган материаллар елга транспорты белән нәкъ менә җәй көннәрендә аеруча зур күләмдә ташыла, бигрәк тә Идел

Фото: Александр Ефремов. РЕКЛАМА

буенда. Ә бу – руда булмаган материалларга аеруча мохтаҗ вакыт. Югарыда телгә алынганнар барысы да чимал ташуның үзкыйммәтенә тәэсир итте һәм продукциянең ахыр бәясендә чагылыш тапты.

– Ә бәяләр белән ни булды?

– Төрле товарның бәясе төрлечә артты. Мәсәлән, ел башыннан алып чуерташ хакы тоннасына 1200 сумнан 2000 сумга кадәр күтәрелде. Күбрәк тә арта ала иде, әмма без оешма эчендә бәяләрнең югары чиген билгеләдек, алар шуннан да ныграк кыйммәтләнмәде.

– Әмма бу тармак бер Иделгә генә бәйле түгел бит…

– Дөрес. Ләкин болар барысы да тимер юл белән товар ташуның кимүе фонында барды, әйтик, Уралдан гранит вак таш китерүне искә алырга мөмкин. Мәсәлән, элек тимер-бетон эшләнмәләр заводлары өчен кирәкле вак ташның 60 проценты тимер юл белән китерелгән булса, хәзер бу сан ике тапкырга азрак. Әгәр әүвәлге елларда базалардагы руда булмаган төзелеш материаллары запасы сезон кызуында һәрвакыт ай саен китеп торган күләмгә тигез яки аннан шактый күбрәк булса, быел китерелгән товарны бушатып тормыйча диярлек төяп җибәрергә туры килде. Кайвакыт базаларда 2-3 көнгә җитәрлек запас та калмый иде. Гадәттә руда булмаган материаллар тау-тау булып өелә, ә монда – буш мәйданчыклар.

Беренче чиратта, без базарда шактый күп булган алыпсатарларның түгел, ә бетон җитештерүчеләр һәм юлчыларның ихтыяҗларын канәгатьләндердек.

Нәтиҗәдә, компаниябез, планнарның бер өлешен тормышка ашырмаса да, мохтаҗлык югары булган чорда клиентларыбызны чимал белән җитәрлек күләмдә тәэмин итте һәм кышкы-язгы чорга материалларның ихтыяҗны капларлык минималь дәрәҗәдә булса да запасын туплый алды.

– Сез әлегә ике факторны гына искә алдыгыз…

– Өченчесе – Татарстандагы карьерларның ярлыланүы. Сүз эшкәртү процессында файдалы казылманың сыйфаты югалу турында бара. Чимал стандартларга туры килсен өчен, хәзер аны яхшылабрак һәм күпкә озаграк эшкәртү таләп ителә, бу да үзкыйммәтне арттыра. Шуңа күрә руда булмаган төзелеш материалларын хәзер Удмуртиядән, Башкортостаннан һәм Пермь краеннан китертергә туры килә. Бу исә ташу ераклыгын арттыра һәм үз чиратында бәяләрдә чагыла. Сезонның иң кызган чагында ягулык-майлау материалларына бәяләр бер ярым тапкырга күтәрелгәнен дә истән чыгармаска кирәк.

Моның барысына тиздән тагын бер проблема өстәләчәк: без һәм бу тармактагы хезмәттәшләребез Урман гаванендагы җитештерү мәйданнарын югалтачакбыз. Бүген ул Казанда руда булмаган төзелеш материалларын эшкәртү һәм саклау үзәге санала. Урман гаваненнан китүебез елга порты территориясен реконструкцияләүгә бәйле.

– Һәм сезгә кая күченергә тәкъдим итәләр?

– Әлегә анык тәкъдимнәр юк. Шуны аңларга кирәк: елга порты буш урында барлыкка килмәячәк, бу бик кыйммәтле уңайлык. Бүген Урман гаванендә су юлы белән китерелә торган руда булмаган материалларның якынча 90 проценты тупланган. Әлеге материаллар Казан һәм аның якын-тирәсе өчен кирәк, сүз елына 5 миллион тонна һәм аннан да күбрәк чимал турында бара. Хәзер аларны өстәмә 40–70 километр ераклыктан алып килергә туры киләчәк (руда булмаган төзелеш материалларының су транспорты белән китерү өчен мәйданчыклар, иң якын дигәндә дә, нәкъ менә шул ераклыкта урнаша ала), ә бу исә киләчәктә сатып алу бәясенә тагын 20–40 процент өстәлә дигән сүз. Бәя артудан тыш, зур йөк машиналары трафигын, юл өслегенә йөкләнешне, экологияне исәпкә алырга кирәк…

Без Яшел Үзәндә базаны үстерергә мәҗбүр, бәлки, ул безнең үсеш ноктасы булыр да.

– Әңгәмәбезне мондый төшенке рухта тәмамлыйсы килми…

– Алай тәмамламыйбыз да. Без шәһәр һәм республиканың симбиотик үсеше яклы. Киләчәккә оптимизм белән карарга кирәк. Йорт һәм урамнарның матурлыгы – үзе бер хозурлык! Шул ук вакытта бу матурлыкны төзүдә кулланыла торган материалларның сатып ала алырлык булуы хакында да онытмаска кирәк. Һәрнәрсәдә баланс булырга тиеш. Шуңа омтылырга кирәк.

– Бу яңа елга теләк кебек яңгырады…

– Шулай булсын да. Әйдәгез, оптимистлар булыйк! Алар, белгәнебезчә, вакыт сынауларында үзләре өчен яңа мөмкинлекләр күрергә сәләтле.

«КАЗАН РУДА БУЛМАГАН МАТЕРИАЛЛАР» КОМПАНИЯСЕНӘ 2002 елда нигез салына. Бүген ул ком, вак таш, чуерташ һ.б. кебек руда булмаган төзелеш материалларын җитештерү, бушату, саклау, эшкәртү һәм сату тармагында алдынгы ширкәтләрнең берсе булып тора. Хәзерге вакытта компаниянең руда булмаган төзелеш материалларын саклау һәм төяп озату өчен Казанда (Магистраль ур., 66, 3 нче Победилово ур., 1а) һәм Яшел Үзәндә (Футбол ур., 8) өч базасы бар.

КРБМ клиентлары арасында тимер-бетон эшләнмәләр заводлары, бетон измәсе узеллары, «Тататводор», «Күперләр һәм юллар» кебек юл төзелеше тармагы флагманнары һәм ай саен дистәләгән мең тонна материал куллана торган башка күп оешмалар бар. Шул ук вакытта компания бер «Газель» яки «КАМАЗ» йөге кадәр генә продукциягә мохтаҗ булган шәхси затларга да хезмәт күрсәтә.

Компаниянең иң мөһим өстенлеге – югары дәрәҗәдә хезмәт күрсәтү. Төяп җибәрелә торган продукцияне махсус QR-кодлар ярдәмендә исәпкә алуның электрон системасы кертелгән, бу исә түләнгән акчаларга, төяп җибәрүгә, китереп бирүгә бәйле мәгълүматны реаль вакыт режимында күзәтеп торырга мөмкинлек бирә.

Контрагентның шәхси кабинетына өстәмә буларак, компьютер программасы күпләргә билгеле такси агрегаторы сервисы кебек эшли: менеджер гариза тутыра, автомобиль йөртүчеләр – йөк ташучы партнерлар бу гаризаны күреп, аны башкаруга алыналар һәм продукцияне кулланучыга илтеп тапшыралар. Бөтен процесс онлайн-режимда күзәтелә ала.

Компаниянең төп өстенлекләреннән берсе – материалларны 24/7 режимында төяп җибәрү мөмкинлеге: җәй көне базалар даими нигездә тәүлек әйләнәсе эшли, ихтыяҗ түбән булган сезонда продукцияне төяп җибәрү эше эре клиентлардан мөрәҗәгать килгәндә оештырыла.

КОРЫЛЫКЛЫ ҖӘЙ САБАКЛАРЫ

Әхмәт Шакиров

Матур гына шытып килгән уҗымга зыян салган соңгы кыраулар, җәйге корылык һәм ТР территориясендә инде 3 июльдә үк игълан ителгән гадәттән тыш хәл режимы... Татарстан авыл хезмәтчәннәре өчен 2023 ел әнә шундый булды. Шуңа күрә һәр уңыш бөртегенең кадере дә зуррак кебек. Һава торышының көйсезлегенә карамастан, 3,7 миллион тонна ашлык җыеп алуны гроссмейстер нәтиҗәләре белән чагыштырып буладыр.

– Икмәк, бәрәңге, яшелчә, шикәр – боларның барысы белән аграрийлар татарстанлыларның ихтыяҗларын тулысынча тәэмин итте, – ди Премьер-министр урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы министры Марат Җәббаров. – Аерым алганда, шикәр чөгендере 1,6 миллион тонна җыелган, бу 210 мең тонна шикәр комы җитештерү өчен җитәрлек, шул ук вакытта халык ихтыяҗлары 100 мең тоннаны тәшкил итә. Бәрәңге уңышы – 880 мең тонна, яшелчә уңышы – 257 мең тонна. Терлекчелектәге уңышлар сөендерә. Җан башына исәпләгәндә, бездә ит куллану нормасыннан – 29 процентка, йомырка – 13 процентка, сөт 28 процентка күбрәк җитештерелә.

КОРЫЛЫК БУЛСА ДА

Боларга барысына да язгы һәм җәйге кыр хәбәрләре еш кына фронттан килгәннәрне хәтерләткән елда ирешелде. Искә төшерик. Май – июнь башы: кинәт булган көчле кырау (көнчыгыш районнарда температура минус 12 гә кадәр төште. – Ред. иск.) шытымнарны юк итте, 20 мең гектардан артык мәйданда культураларны яңадан чәчәргә туры килде. Июнь: яңгырлар юк диярлек, норма 60 мм булганда, яңгырлар дүрт тапкыр әзрәк яуды. Бу әле уртача алганда, бер тамчы да яңгыр төшмәгән районнар да булды. Июль: ай башыннан Татарстанның бөтен территориясендә туфрак корылыгы аркасында гадәттән тыш хәл режимы игълан ителде. Махсус режим «азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү максатыннан» кертелде.

Һава торышы көйсезлегенең йогынтысын минималь дәрәҗәгә җиткерү өчен Татарстан аграрийларының кулында нинди ысуллар бар иде соң? Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов үзенең октябрь Юлламасында шуларның иң мөһимнәрен атады. «Авыл хезмәтчәннәренә катлаулы, әмма гаять әһәмиятле хезмәтләре өчен олы рәхмәт белдереп», ул: «әлеге күрсәткечләр – авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерү һәм аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән минераль ашламалар сатып алуга субсидияләр бирү, ме-

Фото: laishevskyi.ru, agro.tatarstan.ru

Аңлашыла ки, узган аномаль җәй аграрийларны төрлечә сынады, кайдадыр, бәлки, һава шартлары уңайрак килгәндер, әмма кайдадыр, киресенчә, корылык көчлерәк булды. Шулай да эш тиешле дәрәҗәдә оештырылган, сыйфатлы технологияләр һәм орлыклар дөрес кулланылган урыннарда сөендерерлек нәтиҗәләргә ирешелде. Иң яхшы мисал – Тәтеш районы. Узган җәйдә биредә бер тапкыр – 22 июльдә генә яңгыр яуды, дип сөйли район башлыгы Рәмис Сафиуллов, ә майдан октябрьгә кадәр явым-төшем нибары 8 дән 18 мм га кадәр булган. Шуңа да карамастан, нәкъ менә тәтешлеләр, 166,8 мең тонна ашлык җыеп, гомумреспублика икмәгенә иң зур өлешне керттеләр, бер гектардан 38,0 центнер ашлык алып, Буа (29,1) һәм Арчаны (29,7 центнер) узып, районнар арасында уңдырышлылык буенча лидерлыкка ирештеләр. Нәтиҗә шаккатыргыч, бигрәк тә Ютазы, Баулы, Азнакай, Әлмәт, Чирмешән, Әгерҗе районнарында урып-җыюның тыйнак нәтиҗәләре фонында: бу районнарда бер гектардан 14,7 – 15,8 центнер икмәк җыеп алдылар.

СӨРҮСЕЗ ИГЕНЧЕЛЕККӘ ЙӨЗ ТОТУ

«Август-Агро» компаниясенең технологик казанышы аеруча игътибарга лаек, ул узган елда, 319 мең тоннадан артык ашлык (307 мең тонна – көзге һәм язгы бодай) суктырып, ТР авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләре рейтингында беренче урынны алды, уңдырышлылык – гектарыннан уртача 29,5 центнер. Агрохолдинг үз хуҗалыкларында тотрыклы уңыш алырга һәм хәтта климатның уңайсыз шартларында да авыл хуҗалыгы бизнесының рентабельлелеген сакларга мөмкинлек бирә, ресурсларны саклый торган No-Till игенчелек технологиясен куллануга басым ясады.

лиорациягә булышлык итү, сугару җирләрен булдыру, дым саклау технологияләрен куллануга кертү, техник яңарту программаларын гамәлгә ашыру буенча соңгы елларда алып барылган планлы эшнең нәтиҗәсе булып тора», – дип басым ясады.

Корылык китергән зыян белән көрәштә санап кителгән чараларның никадәр нәтиҗәле булуын, минемчә, мондый саннар иң яхшы сөйли. 2021 елда да корылык булды, ул чакта Татарстан хуҗалыклары 2,3 миллион тонна ашлык җыеп алды. Ике елдан соң, тагын да кискенрәк шартларда, яңгырлар республика күләмендә булмаганда, бер ярым тапкыр артыграк (!) уңыш җыя алдык. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы буенча бөртеклеләрнең уртача уңышы гектарыннан 24,6 центнер тәшкил итте, ә ике ел элек ул нибары 15 центнер гына иде. Нәтиҗә ясап була.

ЭКСТРЕМАЛЬ ЕЛДА – РЕКОРД

Аерым хуҗалыклар һәм районнар тәҗрибәсе туфракка кирәкле күләмдә минераль ашламалар кертү, вакытында тукландыру белән бергә прогрессив технологияләрне куллануның нинди могҗизалар тудыра алуын күрсәтә. Тәтеш районының «Колос» агрофирмасы корылыклы елда гектарыннан 60,3 центнер уңыш җыйды, «Чистай Таң Агро» (54,5 центнер) һәм Чүпрәле районыннан «Чынлы» (52,2 центнер) хуҗалыклары алардан аз гына калыша. Уңайсыз шартларга карамастан, «Нармонка» һәм «Актаныш» компанияләре дә яхшы уңыш үстерде.

ТАТАРСТАНДА 2023 ЕЛДА 1,6 МИЛЛИОН ТОННА ШИКӘР ЧӨГЕНДЕРЕ ҖЫЕП АЛЫНДЫ, БУ 210 МЕҢ ТОННА ШИКӘР КОМЫ ҖИТЕШТЕРҮ ӨЧЕН ҖИТӘ, ШУЛ УК ВАКЫТТА ХАЛЫК ИХТЫЯҖЛАРЫ 100 МЕҢ ТОННАНЫ ТӘШКИЛ ИТӘ.

Җирләрне бөтенләй сөрмәү, туфрак катламын ышыклау өчен урып-җыю калдыкларын куллану кырларның су һәм җил эрозиясеннән азрак зыян күрүенә һәм уңдырышлылыкны югалтмавына китерә. Нәтиҗәдә эшкәртелә торган культуралар дым җитмәүдән интекми. 2023 ел шартларында, вегетация чорында компаниянең көнчыгыш һәм көнбатыш зоналарындагы кырларда явым-төшем күләме уртача еллык нормадан 5–10 тапкыр түбәнрәк булганда, No-Till технологиясе тагын бер мәртәбә үзенең өстенлекләрен күрсәтте. Кайбер территорияләрдә көзге культуралар шытымнарына зыян китергән май кыраула-

ры да биредә яхшы уңыш җыярга комачауламады.

«Август-Агро» хуҗалыкларында бөртеклеләр һәм майлы культуралар буенча уңышның гомуми күләме 449 мең тонна тәшкил итте. Бодайдан тыш, 2023 елда компания агрофирмаларында язгы рапс, көнбагыш, борчак, майлы җитен һәм карабодай үстерелә. Аграрийлар ерак киләчәкне күздә тоткан фаразлар ясарга яратмыйлар, шулай да киләсе елгы уңыш өчен нигез начар түгел: белгечләр октябрь ахырында көзге бодай чәчүлекләрен тикшергәндә, үсемлекләрнең 80 проценты кышка бик яхшы һәм яхшы хәлдә керүен билгеләп үттеләр.

Сөрүсез игенчелек кырларны пар астында калдыруны күздә тотмый, шуның белән һәр гектардан максималь уңыш алуны тәэмин итә. Бу технологияне куллану вакыт узган саен туфракның уңдырышлылыгын арттырып кына калмый, No-Till ярдәмендә ел саен тотрыклы уңыш алуга өметләнергә мөмкин.

СӨТ ЕЛГАЛАРЫ. ИКЕ МИЛЛИОН – ЧИКМЕ?

Терлекчелек – традицион рәвештә Татарстанның позицияләре нык булган тармак. Бигрәк тә сөт савымы буенча – Россиядә сөтне беркем дә бездән күбрәк җитештерми. 2022 елда аграрийлар тарафыннан беренче тапкыр алынган ике миллион тоннадан артык сөт, күрәсең, чик түгел. Һәрхәлдә, тармак үсеше динамикасы оптимистик фараз ясарга мөмкинлек бирә: 2023 елның унбер ае нәтиҗәләре буенча республикада 2 млн 15 мең тонна сөт җитештерелгән, бу узган елның шул ук чорына караганда 7,6 процентка күбрәк.

Әмма борчу тудырган күренеш тә күзәтелә – эре мөгезле терлекләрнең баш саны кимүгә бара. 1 декабрьгә аның баш саны 907 мең тәшкил итте – бер ел элек ул 11,7 меңгә күбрәк иде. Бүген без шул шартларда да күбрәк сөт савып алабыз икән, бу, әлбәттә, әйбәт: терлекне карап тотуның заманча технологияләрен кертү, азык үзәкләре булдыру, цифрлаштыру үзенекен эшли. Өстәвенә, көтүне актив яңарту, кайбер токымнарны башка, нәтиҗәлерәкләренә алмаштыру да булыша.

ҖАН БАШЫНА ИСӘПЛӘГӘНДӘ, БЕЗДӘ ИТ КУЛЛАНУ НОРМАСЫННАН – 29 ПРОЦЕНТКА, ЙОМЫРКА – 13 ПРОЦЕНТКА, СӨТ 28 ПРОЦЕНТКА КҮБРӘК ҖИТЕШТЕРЕЛӘ.

Савым көтүен савыктыру-яңарту бара, бу киләчәктә дә дәвам итәчәк, дип билгеләп үттеләр ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында, әмма терлекләрнең кими бару тенденциясен туктатырга кирәк. Мантыйк аңлашыла: сөт җитештерү күләмен тагын да арттыру өчен сыйфат та, сан да мөһим. Татарстан Рәисе үзенең Юлламасында киләсе ел өчен түбәндәгеләрне аерым билгеләп үтте: баш санының кимүенә юл куймау – безнең төп бурыч.

Узган елгы корылык бу мәсьәләне хәл итүгә комачаулый аламы? Марат Җәббаров сүзләренә караганда, терлек азыгы һәм икмәк республиканың азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен җитәрлек күләмдә әзерләнгән. Министрның сентябрь аенда ук әйткән фаразлары буенча, азык белән көтелгән тәэмин ителеш 32,8 центнер азык берәмлеген тәшкил итәчәк. «Бу терлекләрне кышлату өчен җитәрлек, ләкин киләсе елга күчү запаслары калмаячак, – дип нәтиҗә ясады ул. – Шуңа бәйле рәвештә әзерләнә торган азыкның сыйфатына һәм туклыклылыгына аерым игътибар бирергә кирәк».

БЕРДӘЙ МӨМКИНЛЕКЛӘР, ӘММА ТӨРЛЕ НӘТИҖӘЛӘР

Хәер, һәр тармактагы кебек үк, биредә дә яхшы нәтиҗәләргә ирешүдә эшне дөрес оештыру төп рольне уйный. Мисалга Кукмара районын алыйк. Биредә елына 156 мең тонна сөт савыла – Чүпрәле, Яшел Үзән, Югары Ослан, Балык Бистәсе, Менделеевск, Әлмәт, Лаеш, Зәй һәм Питрәч районнарын бергә алгандагы кебек. Шул ук вакытта кукмаралыларда савым көтүе дә кимеми, терлекләрнең баш санын яңарту да, азык белән

тәэмин итү дә тәртиптә, яңа терлекчелек комплекслары да төзелә. Ә башка тугыз районда барысы да диярлек киресенчә. Аларда бер генә дә зур инвестицияле проект тормышка ашырылмый.

Мөмкинлекләр төрлеме? Юктыр. Терлекчелекне үстерү өчен республикада барлык юнәлешләр буенча ярдәм күрсәтелә: нәселле терлек сатып алудан алып югары технологияле комплекслар һәм азык үзәкләре төзүгә кадәр. Һәркем өчен ысуллар бертөрле, әмма аларны, күргәнебезчә, төрлечә кулланалар.

Бүген республика агрохолдинглары эре мөгезле терлекләрнең баш санын торгызу буенча юл карталарын эшләделәр һәм кабул иттеләр. Бу планнар актив тормышка ашырыла. Быел республикада 14,1 мең башка исәпләнгән 19 сөт комплексы файдалануга тапшырылды. Тагын 21 инвестиция проекты төрле гамәлгә ашыру стадиясендә.

Нәтиҗәләр: яңа терлекчелек фермалары һәм комплексларын файдалануга тапшыру хисабына Минзәлә районында мөгезле эре терлек саны – 6,5 мең баштан артыкка, Бөгелмә районында – 3,7 мең баштан артыкка, Кукмарада 1,4 мең баштан артыкка һәм Алабуга районында 1,8 мең баштан артыкка күбәйгән.

ЯСАЛМА ИНТЕЛЛЕКТ АКЧА ЭШЛӘРГӘ БУЛЫША

Яңа комплекслар, кагыйдә буларак, шундый ук яңа технологияләрне дә күздә тота. Җитештерүне тиешле дәрәҗәдә оештыру белән бергә алып барганда, алар искиткеч нәтиҗәләр бирә. Әтнә районын алыйк. Исемлектәге уртача сыерның көндәлек продуктлылыгы биредә 29,6 килограмм – республика күрсәткеченнән 8 килограммга югарырак!

Ә Кукмара районы «Кукмарагрохимсервис» тәҗрибәсен, мөгаен, яңа технологияләрнең ничек эшләвен күрсәтүче иң ачык мисал буларак китерергә кирәктер. Әлеге хуҗалыкта 2022 ел башыннан

2023 ЕЛНЫҢ УНБЕР АЕ НӘТИҖӘЛӘРЕ БУЕНЧА РЕСПУБЛИКАДА ИКЕ МИЛЛИОН 15 МЕҢ ТОННА СӨТ ҖИТЕШТЕРЕЛДЕ, БУ УЗГАН ЕЛНЫҢ ШУЛ УК ЧОРЫНА КАРАГАНДА, 7,6 ПРОЦЕНТКА КҮБРӘК. РЕКОРДЛЫ ЧИК – ИКЕ МИЛЛИОН 100 МЕҢ ТОННА СӨТ ҖИТЕШТЕРЕЛЕР ДИП ФАРАЗЛАНЫЛА.

2023 ЕЛНЫҢ УНБЕР АЕНДА ТАТАРСТАНДА 1 МЛРД 453 МЛН ДАНӘ ЙОМЫРКА ҖИТЕШТЕРЕЛДЕ – БУ УЗГАН ЕЛНЫҢ ӘЛЕГЕ ЧОРЫ БЕЛӘН ЧАГЫШТЫРГАНДА, 33,4 МЛН ДАНӘГӘ КҮБРӘК.

производствога кертү һәм азык белән идарә итү программасы кертелде. Хайваннарны ашату һәм үрчетү буенча беркетмә эшен, системалы исәпкә алуны оештыру биредә бер ел эчендә сөт җитештерүне – 14 процентка, сыерларның продуктлылыгын – 973 килограммга, ә уртача тәүлеклек артымны 51 граммга арттырырга мөмкинлек бирде. Нәтиҗәдә сөт сатудан алынган өстәмә керем 11,5 миллион сумны тәшкил итте.

Керемнәрнең артуы, үз чиратында, хуҗалыкка үз акчалары хисабына терлекне бәйләмичә генә тота торган сыер абзарын реконструкцияләүне, Евро Параллель саву җайланмасы урнаштырылган саву залын төзүне башларга мөмкинлек бирде. Уртача хезмәт хакы да 16 процентка артты. Ферманы яңартуны тәмамлап, сыер һәм таналарның санын 1000 башка җиткергәннән соң, хуҗалык Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгына сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен гариза бирергә ниятли.

Нәтиҗә бик яхшы күренә. Терлекчелектә автоматлаштыру процессларын, ясалма интеллект элементлары кулланылган технологияләрне кертү хезмәт җитештерүчәнлеген арттырып, хезмәт сыйдырышлылыкны киметеп кенә калмый. Җитештерүне киңәйтү һәм хезмәт хакы системасын камилләштерү мөмкинлекләрен бирә, куелган нәтиҗәләргә ирешүне хезмәт өчен түләү күләме белән турыдан-туры бәйләү форсатын тудыра.

«КОМАНДАҢ БУЛМАСА, УҢЫШКА ИРЕШӘ АЛМЫЙСЫҢ!»

Руфия Фазылова

Декабрьнең икенче яртысы булуга карамастан, Тәтеш районы кырларында гөрләп эш бара – чөгендер ташыйлар иде. Баксаң, «Колос» агрофирмасы өчен бу гадәти хәл икән, алдагы елларда да шулай эшләгәннәр. Кар, буран, утыз градус салкынмы, тәтешлеләр сер бирми, чөнки алар авырлыкларны җиңәргә өйрәнгән инде...

«ЧӨГЕНДЕР СЫЙФАТЫН ЮГАЛТА...»

«Колос» агрофирмасының җитәкчесе Римма ханым Сафиуллова һәм аның уң кулы Ранис Мәүлиханов белән кырга чыгып киттек. Жуково авылыннан чөгендер басуына кадәр сигез чакрым ара. Димәк, кар яуган саен сигез чакрым юлны кардан чистартырга кирәк. Әле бер трактор көне буе кизү тора – «КАМАЗ»лар бата калса, трактор ярдәмгә килә. (Андый хәлләр еш була икән.)

Нәрсә, нәрсә, тик менә тездән диярлек кар ерып кышын басуда йөргән юк иде әле. Урыны-урыны белән бигрәк буран тутырган.

Фото: Александр Ефремов. РЕКЛАМА

– Кары ярар, менә утыз градус суыкта эшләргә авыр булды, – диде Ранис Фәритович. – Техника бертуктамый эшләп торды, бу бит өстәмә чыгымнар да дигән сүз.

Чыгымнар турында сөйләшкәндә, шунысын әйтергә кирәк: сентябрьдә җир өстенә чыгарылган чөгендер, өч айдан бирле ятып, шактый авырлыгын югалткан. Һәм сыйфат та үзгәрә инде.

– Казыганда шикәр чөгендере гектарыннан 580 центнер чыга иде, хәзер 500 центнерга калгандыр, – дип дәвам итте сүзен Ранис Фәритович. – Ел эссе килүгә карамастан, 2023 ел безнең өчен уңышлы булды, чөгендер, иген уңышы да югары чыкты.

«Колос» агрофирмасы дәүләткә 42 мең тонна шикәр чөгендер тапшырган. Әгәр уңышны вакытында озаткан булсалар, 45-46 мең тонна чыгар иде. Тик биредә зарланып утырмыйлар, ә килеп туган проблеманы хәл итәргә тырышалар: чөгендерне Зәй шикәр заводына ташыйлар. Тәтеш белән Зәй арасы 450 чакрым! Югыйсә күршедә генә Буа шикәр заводы бар, ләкин ул бөтен көченә эшләми икән. Шуның өчен дә Зәй заводы белән сөйләшкәннәр. Дөрес, чөгендерне Буага да озаталар, тик Тәтеш районында башка хуҗалыклар да бар. Шулай булгач чират көтәсе. Ә «Колос»та эшне вакытында башкарырга күнеккәннәр.

– Чөгендер үстерергә өйрәндек, – диде Римма Сафиуллова. – Гомумән, республика буенча нәтиҗә ясап әйтәм. Элек чөгендернең уңышы болай зур булмый иде. Ә хәзер уңыш елдан-ел арта. Димәк, шикәр заводларының куәтен дә арттырырга кирәк. Кышы буе эшчеләр кырда. Әнә Зәйдән килеп чөгендер ташыйлар. Ике якка тугыз йөз чакрым бит! «КАМАЗ» йөртүчеләр төннәр буе йокламый, шуларны кызганып күзгә яшь килә. Ихлас менә...

АРБАНЫ КЫШТАН...

Агрофирманың 7 мең гектар җире бар. Сөрү җирләре – 6 мең 413 гектар, шуның 800 гектарында шикәр чөгендере утырталар. Узган ел да ул шулай булган. Хуҗалык инде бүгеннән язгы чәчүгә әзер. Декабрь башында ук 60 миллион сумга ашлама алып куйганнар. Арбаны кышын әзерлиләр биредә, ел да шулай. Аннан тыныч күңел белән кышка керәләр.

– Уңышның сере: яхшы орлыкта, ашлама кертүдә һәм иртә чәчүдә, – диде Ранис Фәритович. – Елдан-ел җирнең дымлылыгы кими бара. Язның һәр көнен түгел, һәр сәгатен исәпләп эшләргә кирәк.

Ранис Мәүлиханов белгечлеге буенча ветеринар булса да, авыл хуҗалыгының башка тармаклары турында да барысын да белә. Шактый еллар Казан дәүләт ветеринария институтында эшләгән, ветеринария фәннәре кандидаты. Берничә ел элек башкаладан гаиләсе белән Тәтешкә күченгән. Тәҗрибәле белгечнең бүген бөтен максаты – «Колос» агрофирмасын үстерү, аңа күрсәтелгән ышанычны аклау...

«Колос» дистә еллардан бирле Мәскәүдәге селекция институты – «Немчиновка» тикшеренү үзәге белән хезмәттәшлек итә. Бу элеккеге җитәкче – Рәмис Хатыйп улы Сафиуллов башлаган эш. Алар Мәскәүдән югары уңыш бирә торган орлык сатып алалар. Нәтиҗәдә, корылыклы елларда да иген уңышы яхшы була. 2023 ел да искәрмә булмаган: республикада икмәк үстерү буенча алар беренче!

«ЗАМАНЧА ТЕХНИКА БЕЛӘН ЭШЛИБЕЗ»

Техника да язгы чәчүне көтә, барысы да тәртиптә. Җирләр өлгерүгә, районда иң беренчеләрдән булып кырга чыгалар. «Колос» агрофирмасының техника паркын күреп ис китте:

– 1999 елдан бирле эшлим, – диде агрофирманың баш инженеры Юрий Николаевич Мешков. – Башта механик булдым,бер елдан соң инженер итеп куйдылар. Монда күпчелек минем кебек дистә еллар эшләүче кешеләр. Якын-тирә авылларда яшәүчеләр, нигездә, барысы да «Колос»та эшли. Мал карыйсыңмы, иген үстерәсеңме – теләге булган һәр ке-

шегә эш җитәрлек кенә түгел, ә артыгы белән хәтта! Хезмәт хакы яхшы, 40-50 мең сум, вакытында түләнелә, тагын нәрсә кирәк...

Юрий Николаевич милләте буенча мордва. Бу яктан агрофирманы үрнәк итеп куярга була. Берничә милләт: мордва, чуваш, рус, татар – барысы бергә тату эшли. Бөтен бәйрәмнәр уртак, дингә, милләткә бүленеш юк.

Юрий Николаевич белән техникаларны карап йөрибез. Парктагы комбайн, тракторларның 90 проценты заманча, чит илдән кайтартылган техника. Элек 30 трактор булса, хәзер дүрт заманча техника да җитә. Нигездә алар Германиядә җитештерелгән.

– Чит ил техникасына запас частьләр белән проблема юкмы соң? – дим.

– Әлегә юк. Ни өчен дигәндә, агрофирма җитәкчелеге техниканы өч-биш елдан алмаштырып тора. «Колос» республикада беренчеләрдән булып трейд-ин юлы белән техника ала башлады, ягъни искерәкне калдырабыз, яңаны алабыз.

Ул да түгел, паркка агрофирманың җитәкчесе Римма Гомәр кызы белән баш агроном Илнур Хәлил улы Измайлов килеп керде. Шуңа игътибар иттем: биредә нигездә яшьләр эшли икән. Җитәкче, егетләргә рәхмәт әйтеп, аларны кат-кат мактады:

– Эшчеләр әйбәт безнең. Шуның өчен эшләр дә алга бара, командаң булмаса, уңышка ирешә алмыйсың, – диде.

Римма ханым заманча техникага карап:

– Лизингка алган техника да бар, – дип дәвам итте сүзен. – Зур хуҗалыкны алып бару өчен ансыз булмый. Дөресен генә әйткәндә, евро белән эш йөртәбез. Алган кредитларны да шуның белән түлисе. Яшерен-батырын түгел, тотрыксыз заманда яшибез, бәя бүген бер төрле, иртәгә – икенче. Ләкин куркып утырсаң, алга барып булмый. Без өйрәнгән инде...

«ИСКЕДӘН ЯҢА ЯСАДЫК!»

Игенчелектән, үсемлекчелектән кала, «Колос» агрофирмасы сөтчелек буенча да лидерлар рәтендә. 1100 баш мөгезле эре терлек бар, шуның 450се – нәселле савым сыеры. (Канадада үрчетелгән Голштин, Голштин-фриз токымы). Көн саен дәүләткә 12 мең тонна сөт тапшыралар.



Биредә көтү белән идарә итү программасы гамәлдә. Ягъни мөгезле эре терлек турында бөтен мәгълүмат компьютерга – махсус базага җыела. Гади итеп әйткәндә, маллар цифрлаштырылган: һәр мөгезле эре терлекнең аерым электрон номеры бар. Ясалган вакцинадан башлап, күпме сөт савылганга кадәр – бөтен мәгълүмат шул номер буенча теркәлеп бара. (Сүз уңаеннан, әлеге базадан күренгәнчә, ел дәвамында хуҗалыкта бары тик алты бозау үлгән.)

– Бездә мөгезле эре терлек бик рәхәт яши, – дип елмайды «Колос» агрофирмасы җитәкчесенең тагын бер урынбасары Радик Хәлим улы Йосыпов. – Беренчедән, ашату бик яхшы. Балансны азык үзебездә эшләнә. Берничә төрле иген орлыгы, витаминнар кушып, көрпә ясыйбыз. Силос һәрвакыт малның алдында тора. Сыерларны яхшылап тәрбияләмәсәң, күп сөт савып булмый.

Сыерлар гына түгел, биредә бозаулар да тәрбиядә. Яңа туган бозаулар аерым үсә. Зурраклары тагын башка урында яши. Азык та яшь үзенчәлегенә карап бирелә. Колхоздан калган ферма бинала-

рын шулай төзекләндереп, заманга яраклаштырып (барысы да автоматка көйләнгән) ясаганнар.

БЕР ГАИЛӘ...

Авыл хуҗалыгы өлкәсендә җитәкче хатын-кызлар күп түгел. Бу ничектер гомер-гомергә шулай көйләнгән. Римма Сафиуллова, заманча сүз белән әйтсәк, стереотипларны җимергән кеше. Хатын-кыз бу өлкәдә дә булдыра һәм ничек кенә әле! Төп хезмәттән тыш, әле эниләрчә бөтен эшчеләрнең гаилә хәлләрен белешеп, аларның кайгы-шатлыкларын уртаклашып яши. Ә бу коллективны туплауда, бердәм итүдә бик зур ярдәм. Моннан тыш, хатын-кыз җитәкче, мәдәният, сәнгатькә дә игътибарлы. Эшләгән кеше матур итеп ял итәргә дә тиеш, дигән фикердә тора. Шуның өчен дә «Колос» агрофирмасында һәр милләт үз бәйрәмен зурлап, республика күләмендә билгеләп уза. Затлы бүләкләр тапшырып, артистлар чакырып үткәрәләр.

Тәтеш районында Римма Гомәр кызы «Ак калфак» оешмасын җитәкли. «Татар гаиләсе» фондының райондагы кураторы, актив әгъзасы. Кыскасы, Тәтеш районында яшәүче барлык татарларны берләштерүче.

– Татарларның актив яшәвен күреп, райондашлар: «Безнең дә мордва, рус хатын-кызлар оешмасы төзисе килә», – дип мөрәҗәгать иттеләр, – дип сөйләде Римма ханым. – Ә мин ничек каршы килим? Тәтеш – күпмилләтле район. Шуның өчен дә бездә мәчеткә дә, чиркәүгә дә бер дәрәҗәдә игътибар күрсәтелә. «Колос» агрофирмасына алты авыл керә, барысының да зиратларын карап торабыз. Әлеге дә баягы, кайсы дингә каравын беркайчан да бүлмибез. Һәм башкача мөмкин дә түгел...

Менә шушы фәлсәфәсе, күркәм гамәлләре өчен Римма Гомәр кызына тагын бер җаваплы эш тәкъдим иткәннәр. Ул – «Хатын-кызларның интернациональ берлеге» төбәк иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасы буенча рәсми вәкиле. Октябрь аенда Мәскәүдә узган «Өченче меңьеллык хатын-кызы» премиясен тапшыру тантанасында «Ел лидеры» номинациясендә җиңүче дип танылган. Гомумән, тынгысыз, милли җанлы Римма ханымның бүтән җиңүләре дә бихисап. Ләкин җитәкче ул турыда сүз куертырга яратмый. «Әнә, эшчеләремне күрсәтегез», – дип тора...

СОЧИДАН СӘЛАМ!

Агрофирманың үз ашханәсе, эшчеләр өчен хәтта мини-кунакханәсе дә бар. Сезон вакытында аерым эшләргә читтән дә кешеләр чакыралар. Аларга өч тапкыр ашату, яшәр өчен аерым бүлмәләр каралган.

Ашханә ел әйләнәсе эшли, биредә көн саен хуш исле ипи дә пешерәләр. Беренче, икенче ашлар – барысы да эшчеләрнең тамагы тук, кәефләре яхшы булсын өчен эшләнә.

– Чын, натураль ипи пешерәбез, – диде ашханә мөдире Светлана Потапова. – Су, он, тоз, шикәр комы, сыек май – махсус машинада унбиш-егерме минут әйләндерәбез дә, камырны җылы урынга куябыз. Кабарып менгәч, мичтә кырык биш минут пешерәбез. Яңа пешкән ипинең исе генә дә ни тора бит! И, эшчеләр яратып, мактап ашыйлар. Сезон вакытында ашханәдә өч кеше эшлибез, әлегә икәү дә өлгерәбез.

Агрофирмада бер матур гадәт яши – хезмәткәрләр шифаханәләрдә бушлай ял итә. Биредә эшләүчеләр кайда гына булмаган: Татарстандагы, күрше төбәкләрдәге ял үзәкләре, Сочи, хәтта чит илләр.

Тагын шунысына игътибар иттек: монда бөтен җир төзек, пөхтә. Кыскасы, хуҗа барлыгы күренә.

...Керем турында гына уйламыйча, халык, эшчеләр мәнфәгатен дә кайгырту – «Колос» агрофирмасының төп үзенчәлеге. Хуҗалыкның республикада беренчеләр рәтендә булуы нәкъ менә шуның нәтиҗәсе түгелме икән?.. Т

«Агролизинг» Сәүдә йорты» ҖЧҖ – чагыштырмача яшь предприятие. Җиде ел эшләү дәверендә ул Татарстанда һәм аннан читтә дә танылуга иреште.

МУЛ УҢЫШ НИГЕЗЕ

АНЫ «АГРОЛИЗИНГ»ТАН АЛЫНГАН СЫЙФАТЛЫ ОРЛЫК ҺӘМ АШЛАМАЛАР ТӘЭМИН ИТӘЧӘК

Рөстәм Гайнуллин, «Агролизинг» Сәүдә йорты» ҖЧҖ директоры, авыл хуҗалыгы фәннәре докторы

«Агролизинг» үзен түбәндәге товарлар белән ышанычлы тәэмин итүче буларак танытты:

- «Уралхим» Берләштерелгән химия компаниясе» АҖ җитештергән **минераль ашламалар**;
- «Кукуруз Бөтенроссия фәнни тикшеренү институты» ФДБФУ селекцияләгән **кукуруз гибридлары** (Пятигорск ш.);
- «Майлы культуралар БФТИ Федераль фән үзәге» ФДБФУ селекцияләгән **рапс, горчица, майлы җитен, шепкән һәм көнбагыш орлыклары**;
- «П. П. Лукьяненко исем. бөртекләләр үзәге» ФДБФУ селекцияләгән **уҗым бодае орлыклары**;
- «БашИнком» Фәнни-гамәлгә кертү предприятиесе» ҖЧҖ (Уфа ш.) **җитештергән ашлама, микроашлама һәм биопрепаратлар**;
- быел **традицион ашламалар** – аммиак селитрасына, карбамидка, катлаулы ашламаларга (диаммофоска, нитроаммофоска) ихтыяҗ зур булды. Аммиак сульфатына һәм калий ашламаларына, шулай ук катлаулы ашламаларның NPK 27:6:6:2, 20:11:12 кебек яңа төрләренә ихтыяҗ артты. Традицион NPK 16:16:16 формуласына ия ашлама һәм уртача бәя (тоннасына – 35000 сум) белән чагыштырганда, әлеге ашламалар бер үк агрономик нәтиҗәлелек бирә, бәяләре күпкә арзанрак (тоннасына – 26000 сум). Бу хакта, аерым алганда, Әхмәтов И.П ШЭ. (Алексеевск районы Юеш Көрнәле авылы) тәҗрибәсе яхшы сөйли. Составында күкерт булган NPKS 15:15:15:11 яңа маркага ихтыяҗ зур.

Кукуруз гибридларыннан иң күп сатылганнары: 150-250 ФАО лы, ашлыкка һәм силоска. Бу – Нур (ФАО 150), Биләр 160 (ФАО 160), Машук 171 (ФАО 170), Байкал (ФАО 170), Ньютон (ФАО 200), Машук 250 СВ (ФАО 250). Бу гибридлар салкынга чыдам. Нур, Машук 171, Ньютон гибридларын иртә язгы культуралар белән бергә чәчәргә мөмкин. Иртә гибридларның сентябрь башында сөт-балавыз һәм балавыз өлгерү фазасына җитүе аларны бөртеккә һәм силоска көзге яңгырлар һәм кыраулар җиткәнче җыеп алырга мөмкинлек бирә, ягъни 50 гә 50% нисбәтендә чәкән һәм яшел массалы сыйфатлы азык әзерләп калдырырга. Бу исә силоста крахмалның югары булуын тәэмин итә һәм сөт савымын арттыра. Кукуруз БФТИ гибридларын «Кызыл Шәрык Агро», «Агросила», «Союз-Агро», "Звениговский" һ.б. холдинглар сатып ала.

Быел майлы культура орлыкларыннан рапска ихтыяҗ күзәтелде. Корылык шартларына карамастан, яңа Прометей сорты (Хәмитов Р.М. КФХ, ТРның Алексеевск районы Биләр авылы; «Комбайн» АХПК, Чувашиянең Яльчик районы Избахтино авылы; «Искра» АХП, Мари Элнең Куженерск районы Юледур авылы) үзен яхшы яктан күрсәтте. Аграрийлар рапсның «евролайтинг» технологиясе буенча эшләнгән югары продуктлы Форпост сорты белән кызыксыналар. Көнбагышка килгәндә, «экспресс» технологиясе буенча эшләнгән яңа Сурус гибридын тәкъдим итәбез. Кызганычка, эшкәртүчеләр тарафыннан майлы чималга (рапс, көнбагыш) бәяләр түбән. Шулай ук әле күптән түгел генә иң зур маржа бирә торган ак һәм кара горчицаның экспорт бәяләре дә сөендерми, Әмма майлы җитеннең бәясе килограммына ел башындагы 22 сумнан хәзерге вакытка 32 сумга кадәр артты. Иң зур

Фотолар «Агролизинг» СЙ» ҖЧҖнән алынды. РЕКЛАМА

ихтыяҗ белән алтынсу (ак) җитен файдалана. Бу безнең Исток сорты. Шулай ук шепкәнгә игътибар итәргә киңәш итәбез: «Содружество» КТ тарафыннан даими ихтыяҗ бар, сатып алу бәясе – килосына 35 сум. Бу максатлар өчен Барон сортлы көзге шепкән яхшы туры килә. Товарлыклы сояны сатып алу бәясе яхшы – составында протеин күләменә бәйле рәвештә килосына 40–48 сум. Шуңа бәйле рәвештә, безнең иртә өлгерә торган Чера-1 сортын тәкъдим итәбез, ул безнең шартларда һичшиксез өлгереп җитәчәк.

Көзге бодай орлыкларына килгәндә, яңа Еланчык, Собербаш сортларын тәкъдим итәбез, алар киң таралган Скипетр сортына караганда күпкә яхшырак. Үзенчәлекләрдән – чәчүнең түбән нормасы (гектарына – 180–200 кг, тәбәнәк, аумый). Буа районы Түбән Наратбаш авылыннан Ф.Ф. Кадыйров КФХ, Тәтеш районы Урюм авылыннан И.С. Казаков КФХ югары уңышлары белән канәгать калдылар.

«Башинком» Фәнни-гамәлгә кертү предприятиесе» ҖЧҖ ассортиментыннан «БиоАзФК» инновацияле микробиологик ашлама тәкъдим итәбез. БиоАзФК үсемлекләрнең туфрактан һәм элек кертелгән ашламалардан туклану элементларын алу коэффициентын арттыра. Туфракның нитрогеназ активлыгын (һавадан азотны фиксацияләү сәләтен), абориген микрофлораның азотны фиксацияләве белән чагыштырганда, 5 тапкырга арттыра, туфрактан фосфор һәм калий суыру процессын активлаштыра. БиоАзФК кертү дозасында исәпләгәндә гектарына 15 кг га кадәр – азотлы ашлама һәм кертү дозасында исәпләгәндә гектарына 20 кг га кадәр фосфор-калийлы ашлама кертүне алыштыра. Әлеге препарат түбәндәге микроорганизмнар консорциумын үз эченә ала: Azotobacter chroococcum азот фиксацияләүче бактерияләр (титр 1x107 КОЕ/мл дан ким түгел); Bacillus megaterium фосфор мобилизацияләүче бактерияләр (титр 1x108 КОЕ/мл дан ким түгел); Bacillus mucilaginosus фосфор һәм калий мобилизацияләүче бактерияләр (титр 1x108 КОЕ/мл дан ким түгел); табигый полисахаридлар, фитогормон һәм витаминнар. Орлыкларны чәчүгә кадәр әлеге препарат белән эшкәрткәндә, бактерия споралары орлык аша туфракка эләгә, активлаша, ризосфераны (тамыр системасын) биләп ала. Bacillus megaterium һәм Bacillus mucilaginosus бактерияләре үсү процессында ферментлар бүлеп чыгара, алар әчтәрәк урнашкан силикатлы минералларны эретә, фосфор һәм калий этеп чыгара, алар үсемлекләр тарафыннан җиңел үзләштерелә. Azotobacter chroococcum бактерияләре, атмосферадан азот суырып, аны үсемлекләр ала алырлык формага күчерә.

Шулай ук «5:6:9 маркалы Богатый» ашламасы белән яфрак аша тукландыру да бик популяр. Чагыштырмача түбән бәядән – литрын 200 сумнан алып, 1 гектарга 1 литр исәбеннән керткәндә, ул үсемлекләрнең уңышына зур йогынты ясый, йогынтыны гектарына 8-10 кг карбамид та өстәп көчәйтергә була. Мондый кушылма республикабызның көньяк-көнчыгышындагы иң яхшы фермерларның берсе – Әлмәт районы Кәләй авылындагы Рафыйков Н. Ш. КФХна бик ошады. Соңгы 3 елда, хәтта корылык шартларында да, монда югары уңыш алдылар.

Эш һәм продукция сату күләмнәре ел саен арта, бу безнең товарларга авыл хуҗалыгы оешмалары тарафыннан ихтыяҗ булуын күрсәтә. Хәзерге вакытта «Агролизинг» Сәүдә йорты» ҖЧҖ Татарстан Республикасындагы, шулай ук Чуваш Республикасында, Пенза, Ульяновск өлкәләрендә, Мари Эл Республикасындагы төрле милек формасындагы 120дән артык эре һәм кече авыл хуҗалыгы оешмасына хезмәт күрсәтә. Мәсәлән, бу – «Агросила» АҖ, «Звениговский» АХҖҖК, Түбән Кама районының «Орсис-Агро» ҖЧҖ, Әлмәт районының Н.Е. Токарликов исемендәге АҖ һәм «Союз-Агро» ҖЧҖ, Кукмара районының «Урал» ҖЧҖ һәм «Вахит» ҖЧҖ, Алексеевск районының «Родина» колхозы, Гомәров КХ, Гатин С.С. КФХ, Чувашиянең Комсомол районы «Слава картофелю» агрофирмасы» ҖЧҖ. Шулай ук бу – Буа районының шикәр чөгендере игү буенча иң эре фермеры Кадыйров Фәнил Фәһим улы КФХ һәм «Магнит» кибете тәэминатчысы – Тукай районының атаклы яшелчә һәм бәрәңге үстерүчесе Дәүләтов Насим Галимҗан улы КФХ, Алексеевск районыннан Гомәров КХ, Баулы районыннан Исламгалиев КФХ һәм башкалар.

Компетентлылык, намуслылык һәм килешүдә каралган бурычларны вакытында үтәү, сатып алучының мәнфәгатьләрен исәпкә алып эшләү, заявкаларны кыска вакыт эчендә башкару, кичектереп түләү мөмкинлеге, югары сыйфатлы орлыкларга, ашлама һәм агрохимикатларга бәяләрнең кулай булуы «Агролизинг» Сәүдә йорты» ҖЧҖ эшенең төп күрсәткечләре булып тора. «Агролизинг» Сәүдә йорты» ҖЧҖ киләчәккә зур өмет белән карый. Ⓣ

НӘТИҖӘ КҮЗ АЛДЫНДА!

«Пробиотик плюс» – «ОЛИН» пробиотигын җитештерүче

«ОЛИН» – эре мөгезле терлекләр, дуңгызлар, атлар һәм кош-корт өчен микосорбентлы иң нәтиҗәле пробиотик!

Бозауның дөньяга килүенең беренче көннәреннән үк 3 г дозада «ОЛИН» куллану:

- ашказаны-эчәк тракты үсешенә уңай тәэсир итә;
- патоген микроблар – клостридия, сальмонеллалар, эчәк таякчыгы, протеялар һ. б. ны өстенлекле көндәшлектә кысрыклап чыгара;
- эч китүне булдырмый;
- артымнарны күбәйтә.

Хезмәттәшлеккә чакырабыз

Шайбель Алексей Яковлевич
8-965-136-13-36

Саттаров Рәсүл Фәрит улы
8-987-488-80-50

bbb.moscow

ProBiotic®
www.probiotic-plus.ru

РЕКЛАМА

Ак-зәңгәр Бельгия токымы үгезләренең орлыгын тәкъдим итәбез

Сөт юнәлешендәге сыерларны Бельгия токымы белән орлыкландыру мускул массасы югары үскән бозаулар алу мөмкинлеге бирә. Туганда ук аларның авырлыгы 3037 кг га җитә. 18 айлык чагында мондый таналар һәм үгезләр ит токымлы башка үгезләргә караганда (сөт токымлылар белән чагыштырганда бигрәк тә) күбрәк артым бирә һәм тере авырлыклары 680-720 кг га җитә. Суелган малдан 380–420 кг ит алына. Терлекләр көчле салкыннарны бик җиңел кичерәләр.

3 көннән 25 көнгә кадәрге бозауларны сатып алабыз.

1 кг тере авырлык өчен 300сум

Хезмәттәшлеккә чакырабыз

Зарипов Ришат Өлфәт улы
8-987-297-80-62

Саттаров Рәсүл Фәрит улы
8-987-488-80-50

bbb.moscow

МИРОВЕТ

BBG

РЕКЛАМА

Авыл хуҗалыгы продукциясен сату белән шөгыльләнә торган Татарстан компаниясе 2023 елның иң яхшы экспортёрлары исемлегенә керде, Идел буе федераль округында өченче тапкыр «Ел экспортёры» премиясе лауреаты исемен яулады.

«АГРО-РОСТ ЭКСПОРТ»: БЕРЕНЧЕ БИШЬЕЛЛЫККА – БИШЛЕ

– Безнең товар җибәрү географиясе шактый киң: Польша, Германия, Нидерландлар, Италия, Молдова, Венгрия, Чехия, Австрия, Монголия. БДБ илләреннән Беларусь, Казахстан, Кыргызстан һәм Үзбәкстан. Шулай да продукциянең төп өлеше Европа базарына китә, – дип таныштыра эшләрнең торышы белән фирмага нигез салучы һәм аның директоры Илдар Сәлахов.

– Һәм бу халыкара вазгыятьнең катлаулы булуына һәм санкцияләргә дә карамастанмы?

– Безнең товарлар санкцияләр исемлегенә керми, шулай да сатып алучылар саны өчтән бер өлешкә кимеде. Европага экспортлаучылар да азайды анысы. Үзләрен куркыныч астына куярга теләмиләр. Мәсәлән, бездән продукция алучыларның 70-80 проценты товарны илтеп тапшыргач кына түли. Кемдер түләүдән баш тартырга мөмкин, шул очракта проблеманы чишү авыр булачак. Ләкин алдан түләтүгә күчсәң, бүгенге сатып алучыларның 20 проценты гына калачак.

– Әгәр экспорт белән шөгыльләнә башлаган 2019 елда нинди авырлыклар белән очрашачагыгызны белсәгез, барыбер бу адымга барыр идегезме?

– Барыбер тотынган булыр идем, дип уйлыйм. Сүз уңаеннан, авыл хуҗалыгы продукциясен сатуга бәйле эшебез – гаилә бизнесы ул. Әти һәм абый белән бергә компаниянебезне 2015 елда ачтык. 4 ел эчендә бу өлкәдә ныгыдык, һәм яңа территорияләрне яулар вакыт җитте. Беренче машинаны экспортка 2 ай буе җибәрдек, хәзер бер айга 40ка якын йөк машинасы озатабыз. 2020 елда төяп озатылган товар күләме – егерме тапкырга, 2021 елда ике тапкырга артты. Хәзер тотрыклылыкка ирештек. Елына якынча 7 мең тонна экспорт продукциясе яки аена якынча 500–700 тонна товар төяп озатабыз. Мондый товар әйләнеше күләме безгә икенче ел рәттән Идел буе федераль округында «Ел экспортёры» премиясендә 1 урын алырга мөмкинлек бирә.

– Күп тармаклар хәзер Азия базарына, аерым алганда, Кытайга йөз тота. Мондый үзгәреш сезгә дә кагылдымы?

– Хәзерге вакытта без Кытай базары белән эшләү өчен кирәкле бик катлаулы аккредитация процедурасын узабыз. Азиядә Таиланд, Һиндстан, Малайзия, Якын Көнчыгышта Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Согуд Гарәбстаны, Мисыр да кызыксындыра. Ләкин Европа өстенлекле юнәлеш булып кала, без анда ихтыяҗ булган культураларны сатарга өйрәндек, ул гына да түгел, бездәге хуҗалыкларны шул культураларга үстерүгә җәлеп иттек. Мәсәлән, Азиядә ак горчица кирәкми, аны төп кулланучылар – Көнбатышта, аерым алганда, Германия. Нәкъ менә безнең тәкъдим белән Татарстанда бу культураны күпләп үстерә башладылар. Сүз уңаеннан, ул бөртеклеләргә караганда күпкә керемлерәк.

– Димәк, сез дистрибьютор гына булып калмыйча, авыл хуҗалыгы продукциясе базарын формалаштыруга да йогынты ясыйсыз?

– Әйе. Хәзер инде хуҗалыклар бездән: «Нәрсә чәчик?» – дип сорый башладылар. Без бит аграрийларга кредит ярдәме дә күрсәтәбез: аларга орлык бирәбез, алмашка, алар үстергән уңышны алып, аны тиешле стандартларга җиткерәбез – чистартабыз, киптерәбез һәм кулланучыларга озатабыз.

Гомумән, компаниябез продукциясенең яртысы эчке базарга китә. Эчке базарга без бөртекле, кузаклы, майлы, техник культуралар, берьеллык һәм күпьеллык үлән орлыклары тәкъдим итәбез. Шулай ук терлек азыгы әзерләү материалларын да сатабыз.

– Яңа сатып алучыларны каян табасыз?

– Бер-берсеннән ишетелгән хәбәрләр зур роль уйный: безне күпләр белә һәм хезмәттәшләренә киңәш итә. Өстәвенә, без Россия һәм чит ил сәүдә порталларында эш алып барабыз. Күргәзмәләрдә катнашу да әһәмиятле роль уйный. Әйтик, 29–31 гыйнвар көннәрендә без Казанда узачак «ТатАгроЭкспо»да үз стендыбызны тәкъдим итәчәкбез. 20 февраль тирәсендә Дубайга Gulfood-2024 халыкара күргәзмәсенә барырга ниятлибез. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы министрлыгы безгә үз продукциябезне республиканың коллектив стендында тәкъдим итәргә мөмкинлек тудырды. Гомумән, Татарстанда экспортёрларга ярдәм итү өчен бик күп эш башкарыла, шуңа күрә киләчәккә оптимизм белән карыйбыз. «Агро-Рост Экспорт» компаниясе эшчәнлегенең беренче биш еллыгын бәяләсәк, һичшиксез, бишле куярга мөмкин.

Фото «Агро-Рост Экспорт» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА
ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ
ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ
ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ
Реклама 16+
WWW.PROTATARSTAN.RU

«ЭМИЗ» ҺӘМ «BAZR»: ВИНОГРАД ТЫЛСЫМЫ

Наилә Хәйретдинова

Сәламәт ризык – хәзер модалы тренд кына түгел, бәлки поликлиникага йөрмичә һәм дарулар эчмичә генә сәламәт яшәүгә гарантия дә ул. Әмма бу, әлбәттә инде, ризык һәм эчемлекләр чыннан да файдалы булган очракта гына мөмкин. Мәсәлән, «ЭМИЗ» («Сәламәтлек һәм яшьлек эликсиры») компанияләр төркеме продукциясе кебек – ул үзенең 100 процентка табигый, файдалы, сихәтле булуын күптән дәлилләде инде.

Уникаль брендның эчемлек һәм лимонадлары Татарстанда җитештерелүе исә икеләтә куаныч – импортны алыштыру программасын уңышлы гамәлгә ашырырга булышып, алар «кола», «фанта» кебек эчемлекләргә лаеклы алмаш булып тора.

ТӘЛГӘШ СИХӘТЕ

«ЭМИЗ» бренды белән эчемлекләр чыгару 2018 елда виноградтан эликсирлар һәм витаминлы комплекслар җитештерүдән башланган иде. Моның өчен бары тик Кырым һәм Дагыстанның, Краснодар краеның экологик чиста районнарында үстерелгән кара виноград сортлары – «каберне-совиньон», «мерло», «пино-нуар», «саперави» гына файдаланыла. Күптән дәлилләнгән инде: виноградның төсе карасурак булган саен, анда антоцианнар да күбрәк була. Экспертлар бу матдәләр организмга комплекслы сәламәтләндерү тәэсире күрсәтә ала дип раслый.

Эликсир рецептын эшләгәндә, «ЭМИЗ» компанияләр төркеме технологлары борынгы рецептны нигез итеп алган һәм нәтиҗәдә Россиядә дә, дөньяда да тиңдәше булмаган эчемлек килеп чыккан. Рецептура нигезендә виноград төше генә түгел. Туңдырылган виноград бик вак кисәкчекләргә таркатыла, аның бөтен өлешләрен тулаем файдаланганга, төше, тышчасы, йомшагы һәм тәлгәшендәге барлык файдалы матдәләр виноград согына суыртылып чыгарыла. Ә ул, мәгълүм булганча, кеше организмы тарафыннан бик шәп үзләштерелә. Шул ук вакытта эчемлек тулысынча табигый – аңарда шикәр дә, консервантлар да юк. Эчемлек бөтенләй алкогольсез дә – аны әзерләгәндә кулланылган пастеризация процессында ачыту китереп чыгарырга сәләтле бөтен бактерияләр юк ителә.

«ЭМИЗ» компаниясе фотолары. РЕКЛАМА

СӘЛАМӘТЛЕККӘ БУЛЫШУ

«ЭМИЗ» эликсирлары баштан ук организмны сәламәтләндерү максатын күздә тотып булдырыла. «ЭМИЗ» компанияләр төркеменең хуҗасы һәм рухландыручысы Раил Фазылҗанов әйтүенчә, аларның миссиясе – миллионлаган кешегә сәламәт булырга булышу.

Даими кулланылганда «ЭМИЗ» эликсиры организмга файдалы йогынты ясый ала.

Виноград җимешенең тышчасы һәм төшендәге файдалы матдәләр күзәнәкләрнең тиз арада яңаруына булыша, бу исә организмны яңарту һәм яшәртү процессын эшләтеп җибәрә. Әле алай гына да түгел, виноградтагы антиоксидантлар яман шеш күзәнәкләре үсешен туктатырга да сәләтле, кандагы шикәр микъдарын киметә һәм бөтен организмны энергия белән тәэмин итә.

«ЭМИЗ» иммунитет өчен мөһим булган күптөрле витаминнарга бай. Мәсәлән, эчемлектәге В төркеме витаминнары нерв системасына һәм баш мие эшчәнлегенә уңай тәэсир итә. Андагы С витамины исә стресстан, депрессия һәм талчыгудан саклый, йогышлы чирләргә бирешмәүчәнлекне арттыра һәм кан синтезы процессын көйли. Өстәвенә, эликсир канны сыегайта һәм микротромблар барлыкка килүне кисәтә. Соңгы продуктлардан берсе – «Диабетик ЭМИЗ» – бөтенләй диярлек углеводларсыз, ул кандагы шикәр микъдарын киметми дә, арттырмый да, димәк, үз организмындагы әлеге күрсәткечләрне гел күзәтеп тору мөһим булган кешеләр өчен аеруча файдалы.

ШИКӘРСЕЗ һӘМ БУЯГЫЧСЫЗ ЛИМОНАД

«ЭМИЗ» компаниясенең сәламәт туклану тарафдарлары булган кулланучылары сафына биш елдан соң Татарстан эликсирларының тиңдәшсез тәмен аеруча үз итүчеләр дә килеп кушылган. 2022 елда яңа продукт – BAZR лимонадлары линейкасы эшләтеп җибәрелгән. Асылда, бу – составында хәтта бер грамм да шикәр, консервант, хуш исләндергеч һәм буягыч булмаган табигый продуктлар җитештерүне планлы киңәйтү. Инде дүрт төрле кызыклы тәм – виноград, җир җиләге, виноград һәм киви – сатуда бар. Якын киләчәктә исә дистәгә якын төрле тәм пәйда булачак.

– Әгәр элегрәк без «ЭМИЗ» эликсирларын күбрәк сатсак, 2024 елда лимонадларыбызга ихтыяҗ зур булыр, дип уйлыйбыз, – дип сөйли Раил Фазылҗанов. – Аларны җитештерү бик күпкә артты. «Виноград» һәм «Груша» лимонадлары «2023 елда Россиянең иң яхшы 100 товары» конкурсы җиңүчеләре арасына керде һәм шул рәвешле продукциянең искиткеч үзлекләре һәм югары сыйфаты расланды.

«ЭМИЗ» компанияләр төркеме продукциясе Казахстан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Согуд Гарәбстанына сатыла. Таҗикстан, Төркия, Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендәге партнерлар белән сөйләшүләр алып барыла. Мөселман илләренең Татарстан эчемлекләре белән кызыксынуы аларның хәләл сертификатына ия булуына да бәйле, алар тулысынча алкогольсез, ачыту процессы файдаланылмаган пастеризация технологиясе буенча җитештерелә.

Россия сатып алучылары инде хәзер үк BAZR лимонадларын һәм «ЭМИЗ» эликсирларын Ozon һәм Wildberries маркетплейслары аша алдыра, ә 2024 елда исә аларны Россиянең барлык челтәрләрендә дә диярлек («Самокат», «ВкусВилл», «X5 Group» һ.б.) сатып алып һәм өйгә китертеп булачак.

«ЭМИЗ» компанияләр төркеме офисында көн саен сөргән креатив рух нәтиҗәсендә Раил Фазылҗанов җитәкчелегендәге иҗат командасы яңа проектлар буенча актив эшли, продуктлар уйлап таба. Аларның нинди булуы әлегә сер. Әмма бер нәрсә үзгәрешсез калачак: алар барысы да табигый, файдалы һәм тәмле булачак.

ВЛАДИСЛАВ ФЕДОРОВ: «БЕЗНЕҢ СОҢГЫ МАКСАТ – ГАДЕЛ БӘЯДӘН ТӘМЛЕ СЫР»

Евгения Чеснокова

2023 ел нәтиҗәләре буенча «Арча» ҖЧҖнең Арча сөт комбинатында сөт эшкәртү – 24 процентка, сыр җитештерү – 22 процентка, май җитештерү – 19 процентка, коры эремчек суы җитештерү өчтән бер өлешкә диярлек арткан. Җитештерү күләмен арттырырга предприятиегә нинди чаралар ярдәм иткән соң? Бу хакта без «Вамин» КТ «Арча» ҖЧҖнең Арча сөт комбинаты вәкиллеге директоры Владислав Федоров белән сөйләштек.

–2022 елда безнең предприятиедә яңартып кору эшләре башкарылды, – дип сөйләде безгә Владислав Анатольевич. – Чит илдән кайтартылган яңа җитештерү линиясе урнаштырылды. 2023 елда без проект куәтенә чыктык. Аппарат цехы, май һәм сыр цехлары яңадан җиһазландырылды. Максатыбыз – тәүлегенә 420 тонна сөт эшкәртү күләменә чыгу.

Узган елда гамәлгә ашырылган зур проектларның берсе ике мең тонна әзер продукциягә исәпләнгән сыр саклау урыны төзү булды, анда сырны өлгертү, саклау, арадаш складлау камералары, май саклау өчен түбән температуралы камера, төяп озату һәм кабул итү зоналары, санитар үткәрү урыны бар. Бу күп көч, вакыт һәм акча салынган бик зур проект булды.

– Аны сафка бастыру предприятие эшенә нинди йогынты ясады?

– Без күбрәк сөт эшкәртә башладык һәм, димәк, сырны да артыграк җитештерәбез. Шул ук вакытта өлгерү процессында сырларның сыйфатын җентекләбрәк контрольдә тоту мөмкинлегенә ия булдык.

– Сезнең сырларны хәзер Европаныкыннан бер дә ким түгел дип әйтә алабызмы?

– Чагыштыру монда бигүк дөрес булмастыр: башка климат, башка сөт... Өстәвенә, Европада күбрәк сырларның каты сортларына өстенлек бирелә. Без классик сырлар җитештерәбез, бу Россия һәм голланд төркемнәре. Россиядәге башка җитештерүчеләр белән чагыштырганда, без көндәшлеккә сәләтле, бездә бәя-сыйфат нисбәте дөрес, шуңа күрә Россия сәүдә челтәрләрендә аудитлар узабыз, бөтен ил буенча да, экспорт өчен дә эшлибез, әйтик, Беларусь, Казахстан, Азәрбайҗан, Таҗикстан, Кыргызстан белән...

– «Вамин» маркалы иң яраткан сырыгыз кайсы булуы белән дә кызыксынийк әле...

– Мин майлылыгы илле процент булган Россия сырын яратам. Бу классик продукт, сыр тәме килеп тора, бераз әчелеге дә бар, тишекләре шактый эре. Гомумән, төп биш позициябезгә Россия, голланд, гауда, эдем, тильзитер сырлары керә.

– Ассортиментны киңәйтергә уйлыйсызмы?

– Яңа сырлар булдыру юнәлешендә даими эшлибез. 2024 елда базар өчен берничә яңа позиция игълан итәргә уйлыйбыз, хәзер технологлар һәм ачыткы тәэминатчылары белән эшлибез. Безнең линейкада премиум сырлар да бар. Андый сырларны талымлы, ашауда нәзберек кешеләр үз итәр дип уйлыйбыз, әмма шул ук вакытта уртача бәя сегментындагы продукцияне дә арттырабыз. Ә 2023 елда эконом-сегментта шактый кызыклы Archeese сыр пәйда булды (исеме дә кызык – Арча һәм cheese – «сыр» сүзләреннән ясалган). Ул «өй яны» форматындагы кибетләр өчен, сатып алучылар өчен бу бюджет продукты. Тагын бер кызык ягы шул: пакетының дизайнын һәм бренд логотибын нейрон челтәр ярдәмендә ясадык.

Шунысын да билгеләп үтәсем килә: бездә сыр турау цехы бар. Ул 2022 елда эшли башлады, һәм бер елдан соң аның җитештерүчәнлеге ике тапкырга артты. Сырны ике йөз, өч йөз грамм авырлыкта бүләбез, шакмаклап, озынчалап турыйбыз. Үлчәп сатыла торган сырның стандарт булмаган төрләре бар-ике килограмм ярымлысы, биш килограммлысы... Быел бу цехның җитештерүчәнлеген тагын ике тапкырга арттырырга уйлыйбыз.

– 2023 елда сезнең предприятиедә тагын нинди зур проектлар гамәлгә ашырылды?

– Мәсәлән, җитештерүдә кулланусуын әзерләү. Сөт эшкәртүдә суның сыйфаты зур роль уйный. Без андый суны йомшарту һәм чистарту проектын башлап җибәрдек. Бу продуктның сыйфатына уңай тәэсир итте.

Тагын бер проект турында әйтәсем килә. Сөт җитештерүендә суыту максатларында боз кебек салкын су кулланыла. Хәзер без аммиаклы суыту җайланмаларыннан файдаланабыз. Аларны карап тору һәм яңарту шактый кыйммәткә төшә, шуңа күрә фреон белән суытуны сайларга булдык. Узган ел чит ил җиһазлары сатып алдык, хәзер аларны тәүлегенә 420 тонна сөт эшкәртү куәтенә чыгарлык итеп монтажлыйбыз.

Моннан тыш, 2023 елда ярдәмче материаллар (аларга җитештерүдә кулланыла торган бар нәрсә дә керә: фермент һәм ачыткылардан алып, скотч һәм юу матдәләренә кадәр) склады яңартылды. Ярдәмче материалларны дөрес саклау – федераль челтәрләр аудиты, продукцияне экспортка җибәрү вакытында таләп ителгән мөһим тикшерү пунктларының берсе. Без иске склад бинасын тулысынча ремонтладык: сыек һәм коры материалларны аерым секцияләрдә саклыйбыз, вентиляция системаларын, электриканы яңарттык. Хәзер безнең склад тәртиптә. Һәм продукциягә карата берәр дәгъва булган очракта ярдәмче материалның кайсы партиягә каравын, кайсы тәэминатчыдан алынганын бик тиз ачыкларга мөмкин.

– Сырдан тыш, сез тагын май да җитештерәсез...

– Әйе, кондитерлар, туңдырма җитештерүчеләр, консерва, башка төр азык җитештерүчеләр сатып ала торган коры сыр сывороткасы (эремчек суы) да бар... 2023 елда яңа май формалаштыручы сатып алдык, хәзер җитештерүчәнлегебез артты. Эремчек суы ясауны да арттырырга планлаштырабыз, хәзер нанофильтрацияле җиһазлар урнаштырабыз, киптерү җайланмаларын реконструкцияләү проектын башлап җибәрдек.

– Бүген күп кенә предприятиеләр экологиягә карашны үзгәртә, табигатькә зарар китерә торган йогынтыны киметергә омтыла. Сез дә бу юнәлештә эшлисезме?

– Әлбәттә. Җитештерү күләме арту белән, агынтылар күбәя бара. Узган ел үзебезнең чистарту корылмаларын төзү турында карар кабул иттек. Хәзер чистарту өчен яңа җиһазлар көтәбез. Бу, һичшиксез, экологияне яхшыртачак.

Гомумән, бөтен модернизация бер максатка юнәлтелгән: җитештерү сыйфатлырак, экологик яктан файдалырак, нәтиҗәлерәк булсын, кулланучы өстәленә сыйфатлы продукт гадел бәядән китсен дип эшлибез.

– Сез сатып алучылардан нинди дер кире элемтә аласызмы?

– Әлбәттә, һәм бик тиз. Мәсәлән, 2023 ел ахырында складта товар бөтенләй диярлек калмады. Димәк, безнең продукцияне яраталар, һәм ул бик тиз сатыла.

Фотолар «Вамин Татарстан» ЖЧҖнән алынды. РЕКЛАМА

Кукмара районы

КИЕЗ ИТЕК ЯСАЛМА ИНТЕЛЛЕКТКА КОМАЧАУЛАМЫЙ

Татьяна Вафина

«Татарстан – илдә сөт җитештерү буенча иң алдынгы төбәк», – дигән иде үзенең еллык Юлламасында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов. Һәм бигрәк тә Кукмара районын мактады – анда елына 140 мең тонна сөт җитештерелә!

«Татарстан» киез итекләре һәм металл савыт-сабасы белән генә түгел, сөтчелек буенча да данлыклы районга юл тотты. Тикмәгә генә Кукмара да, аның башлыгы да «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләнмәгән бит!

«ГОЛШТИН СЫЕРЫ»

Кукмара үзәгендә безне... бик матур бер сын – скульптор В. Н. Кулешовның «Голштин сыеры» каршы алды, аны район халкына Самара өлкәсендәге хезмәттәшләре «тәүлегенә тулаем 400 тонна сөт сауган өчен» бүләк иткән. Сыер хакимият бинасына төбәлеп карап тора, анда исә инде безне район башлыгы – яшь һәм амбицияле Сергей Димитриев зарыгып көтә.

ТАРИХ БЕЛӘН ЯҢАЛЫК ЯНӘШӘ

– Авыл хуҗалыгы районы булсак та, бездә сәнәгать тә зур үсештә, – дип башлый үзенең сүзен Сергей Димитриевич. Һәм Кукмара районын дөньяга таныткан һәм брендка әйләндергән барлык җитештерүләрне горурланып санап китә. – Бездә Россиядәге иң зур киез җитештерү – киез итек басу фабрикасы булуын бөтен Татарстан белә, ул 155 еллык данлыклы тарихка ия. Металл савыт-саба заводыбыз да Россиядә иң зур һәм иң мәгълүм җитештерүләрдән берсе. Тау чаңгысы костюмнары һәм балалар киемнәре тегү фабрикабыз да зур. Идел буенда иң зур таш эшкәртү комбинаты да бездә. Барлык бу җитештерүләр район үсешенә уңай йогынты ясый. 36 гектарлы Кукмара сәнәгать паркында бүген инде 11 резидент теркәлгән, һәр җир кишәрлегенең хуҗасы бар, ел саен яңа җитештерүләр пәйда була... 2024 елда анда куәтле элеватор төзелә башлаячак, ул май культураларын да, ярмалар да эшкәртәчәк, тирәнтен эшкәртү дә булачак. Республика Рәисе яңа мәйданчыкны да хуплады: сөт комбинаты 98 гектарлы җирнең беренче резиденты булачак. Ул беренче этапта – 500 тонна, соңрак 1000 тонна сөт эшкәртүгә исәпләнгән. Сөт комбинатыннан тыш, әлеге яңа мәйданчыкта тагын ике резидент бар инде. Берсе – кыяр, помидор һәм башка яшелчәләр үстереләчәк теплица хуҗалыгы. Күрше республикадан бер эшкуар исә төрле җиһазлар җитештерү заводы төзергә планлаштыра. Әлегә сөйләшүләр бара. Без бизнесның барлык төрләренә дә булышырга тырышабыз. Квартал саен эшкуарлар белән киңәшмәләр үткәрәбез, аларны дәүләт ярдәме турындагы мәгълүмат белән танышты-

Фото: Александр Гайнетдинов

рабыз. Һәм нәтиҗәсе дә күренә – динамика ел саен арта бара.

РАЙОН ҮСЕШЕ ДРАЙВЕРЫ

– Ягъни район үсеше драйверлары барыбер сәнәгать җитештерүләре булып чыгамы инде?

– Барыннан да бигрәк, бу барыбер авыл хуҗалыгы. Безнең максат – чәчү һәм уңышны җыеп алу гына түгел. Бөтен үстергән уңышны без терлекчелек белән бәйлибез. Авылларда халык елына 365 көн буе мәшгуль булсын, дип тырышабыз. Сөт терлекчелегенең мөмкинлекләре гаять зур, ул халыкны эш урыннары һәм лаеклы хезмәт хакы белән тәэмин итә. Мәсәлән, сыер савучыларның сменалы эшен оештырабыз. Хәзер беркемнең дә ялсыз эшлисе килми, моны аңларга кирәк. Шунлыктан без үзебезгә әлеге курсны сайладык – сөт терлекчелеген үстерү. Уңга-сулга тайпылмыйбыз. Биредә барысы да яхшы икән, димәк, булышуны, акча кертүне дәвам итәбез. Минемчә, сөт тармагыннан башка районның үсеше мөмкин түгел. Моның өчен без ел саен савым сыерларының да, тулаем терлекләрнең дә баш санын арттыра барабыз. Мәсәлән, бүген безнең авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә 45 мең баштан артыграк, шәхси ярдәмче хуҗалыкларда 15 мең баштан артыграк терлек бар. Үз алдыбызга шундый амбицияле бурыч куябыз – авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә генә дә терлекләрнең баш санын 60 меңгә җиткерергә һәм шул рәвешле 2024 елда 500 мең тонна сөт савып алырга. Республика Рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнеханов безгә шундый бурыч куйды, һәм без 2024 елда моңа ирешергә ниятлибез.

АЗЫК ҮЗӘКЛӘРЕ

– Әлеге амбицияле бурычны үтәү өчен районда терлек азыгы җитәрме соң?

– Районның барлык авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә азык үзәкләре бар. Алар үз терлекләрен дә шуннан ашата, шәхси ярдәмче хуҗалыкларга, шулай ук башка фермерларга һәм предприятиеләргә дә сата. Бездә җирсез инвесторлар бар, алар терлекчелек комплекслары төзи. Аларны җир участоклары, азык үзәкләре булган башка авыл хуҗалыгы предприятиеләре ашата. Бизнес өчен мондый юл шактый файдалы. Шунлыктан без инвесторларга мондый механизм тәкъдим итәбез – үз җире булмаган килеш комплекслар төзегән инвесторлар белән килешү имзалыйбыз, ә районның авыл хуҗалыгы предприятиеләре аларның терлекләрен ашатырга тиеш була. Инвесторларны авыр хәлдә калдырмас өчен, авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә тупас сусыл терлек азыгының ике еллык запасын тотабыз. Шунлыктан үз көчебезгә ышанабыз. Безнең районга инвестицияләр салучыларны уңайсыз хәлгә куярга хакыбыз юк.

Бу – авыл хуҗалыгы предприятиеләре өчен яхшы бизнес. Без хәзер ашлык сатмыйбыз диярлек. Барысы да терлек ашатуга китеп бара. Төрле азыкны кушабыз, капчыкларга тутырабыз һәм сатабыз, шул исәптән башка районнар, башка төбәкләргә дә. Әлеге юнәлештә без эшли башладык кына әле. Тагын 2–3 елдан халык моңа күнегер, дип уйлыйм. Хәтерләсәгез, элегрәк беркем дә кибеттән пилмән сатып алмый иде, янәсе, үзләре ясый. Хәзер исә өйдә беркем дә ясамый диярлек, барысы да сатып ала. Пакетны ачасың да пешерәсең, азапланып торасы да юк. Биредә дә шулай ук. Төрелгән азык тәкъдим итәбез. Нинди кирәк, сайлап ал гына: симертү өченме, савым сыерларынамы, 25 литрлымы, 30 йә 35 литрлымы – теләгәнеңне рәхәтләнеп сатып алырга була. Бүген моның белән Үзбәкстан бик кызыксына, бездән терлек азыгы сатып алырга тели. Әмма безнең дә җирләребез күп түгел, үзебезнең проектлардан артканны гына сата алабыз. Алданрак әйткәнемчә, 2400, 4800 башка исәпләнгән комплекслар төзеләчәк. Әлеге авыл хуҗалыгы предприятиеләрен җитәрлек азык белән без үзебез тәэмин итәргә тиеш булабыз. Шунлыктан бик зур күләмдә читкә сата алмаячакбыз. Әлеге зур проектлар төгәлләнгәч кенә нәтиҗә ясап булачак. Һәрвакыт ике еллык запас булырлык итеп эшләрбез, дип уйлыйм. Сатуны киметеп, үз районыбызны – шәхси ярдәмче хуҗалыкларны да, сөт-терлекчелек комплексларын да тулысынча тәэмин итәрлек күләмдә генә җитештерербез, дип уйлыйм.

ТЫРЫШКАН ТАБАР

– Сезнең хакта, мөмкин булмаганны да эшләргә сәләтле, дип сөйлиләр. Һәм бу сөт җитештерүгә генә түгел (гәрчә сездә сигез районда савылган кадәр сөт җитештерелсә дә), башка бик күп юнәлешләргә дә кагыла. Анда да сез теләсә нинди шартларда беренчелеккә омтыласыз.

– Мин үзем сигез ел буе авыл хуҗалыгы предприятиесе директоры булып эшләдем, шунлыктан нинди юнәлештә һәм ничек эш итәргә кирәклекне яхшы беләм. Соңгы 7-8 елда авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә продукция җитештерү 5 тапкырга артты. Ә икътисад тулаем өч тапкырга үсте. 2030 елга 50 миллиард сум керем алырга ниятлибез! Ходай кушып, мин алдарак сөйләгән предприятиеләрнең барысы да яхшы гына эшләп китсә, районыбызда 50 миллиард сум керем һичшиксез

1 НЧЕ АМБИЦИЯЛЕ БУРЫЧ

ҮЗ АЛДЫБЫЗГА ШУНДЫЙ АМБИЦИЯЛЕ БУРЫЧ КУЯБЫЗ – АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ПРЕДПРИЯТИЕЛӘРЕНДӘ ГЕНӘ ДӘ ТЕРЛЕКЛӘРНЕҢ БАШ САНЫН 60 МЕҢГӘ ҖИТКЕРЕРГӘ ҺӘМ ШУЛ РӘВЕШЛЕ 2024 ЕЛДА 500 МЕҢ ТОННА СӨТ САВЫП АЛЫРГА. РЕСПУБЛИКА РӘИСЕ РӨСТӘМ НУРГАЛИ УЛЫ МИҢНЕХАНОВ БЕЗГӘ ШУНДЫЙ БУРЫЧ КУЙДЫ, ҺӘМ БЕЗ 2024 ЕЛДА МОҢА ИРЕШЕРГӘ НИЯТЛИБЕЗ.

булачак. Бу, билгеле инде, бик амбицияле бурыч. Әмма мин, эшли башлагач ук, Кукмарада 200 тонна сөт җитештерәчәкбез, дигән идем. Барысы да көлде, ышанмады, мөмкин түгел, дип санады... Бик мөмкин! Бары тик структураны, системаны үзгәрттек, башкачарак эшли башладык. Башта 200 тонна, аннары – 300, аннан соң инде 400 тонна сөт җитештердек. Иманым камил, 500 тоннасына да ирешәчәкбез! Башта команда ышанмады. Әмма мөмкин булмаган нәрсә юк ул. Хәзер исә 50 миллиард сум алачагыбызга бөтенесе диярлек ышана. Бу сөт заводы, сөт комплекслары, элеватор, шулай ук безгә ит комбинаты да кирәк, чөнки аена 3000 баштан артыграк терлек чалабыз. Бездә ит комбинаты бар. Әмма ул кечкенә, аена 300–500 баш кына эшкәртә ала. Зур, заманча ит комбинаты кирәк! Менә планлаштырабыз. Мәйданчык таптык. Инвестор бар, банклар белән сөйләшәбез, кредит ресурслары кирәк. Планда трактор заводы, төрек тракторларын җыю да бар. Декабрьдә без төрек компаниясе белән килешү төзедек. Әлегә алар бу тракторларны дилер сыйфатында сатачак, аннары исә Кукмарада җыя башлаячакбыз.

КАДРЛАР КЫТЛЫГЫ

– Бар нәрсә үсештә, район гөрләп алга бара... Димәк, проблемалар юк?

– Бөтен җирдәгечә, бездә дә хезмәт ресурслары белән проблемалар бар. Кадрлар җитешми. Башка төбәкләрдән белгечләр чакырабыз, яшьләр белән очрашулар оештырабыз. Моңа карамастан, кадрлар кытлыгы төп проблема булып кала бирә. Яшьләр зур шәһәрләргә омтыла. Кызганыч ки, алар һаман шуны аңламый: кечкенә калаларда да зур шәһәрләрдә булган бөтен нәрсә бар бит. Спорт та, мәдәният тә, тулы канлы тормыш белән яшәү өчен кирәкле бөтен нәрсә дә. Билгеле инде, университетлар юк, Казандагы кебек сәүдә үзәкләре һәм күңел ачу урыннары да төзи алмыйбыз.

Шунлыктан белгечләрнең 50 проценты югары уку йортын тәмамлаганнан соң туган районына кайтмый. Шуңа кадрлар җитми. Менә Кытай белән килешүләр имзаланган. Әмма әлегә эшне башлап булмый. Бер инвестор килгән иде, акча бирергә әзер. Тик бу җитештерү өчен 500 кеше кирәк. Ә алар юк!

КЕШЕ ХЕЗМӘТЕН КИМЕТҮ

– Нишләргә соң? Гомумән дә, менә конкрет Кукмарада да?

– Кул кушырып утырмыйбыз. Районда ресурс үзәге бар, анда 500ләп кеше укый. Нигездә, алар барысы да районда кала. Бу эшкуарларга яңа җитештерүләр булдырырга ярдәм итә.

Һәм, әлбәттә инде, яңа технологияләргә мөрәҗәгать итәбез. Инде өченче ел районда яңа технологияләрне үзебез эшлибез, үзебез гамәлгә ашырабыз, максималь компьютерлаштыру бара. Безнең бурыч – кеше хезмәтен куллануны мөмкин кадәр киметү, чөнки эш хакы фонды арта, кеше ресурслары җитешми. Авыл хуҗалыгы тармагында ул тагын да азрак. Энергиягә туендырылган техника, ясалма интеллектлы технологияләр сатып алабыз, пилотсыз технологияләр кертәбез. Әгәр шул юнәлештә бармасак, тиздән эшләргә кеше калмаячак. Менә хәзер безнең райондагы мөһим бурыч – саву залын 100 процентка җиһазландыру, азык үзәге исә энергиягә туендырылган техника белән 100 процентка җиһазландырылган инде. Бу продукциянең үзкыйммәтен киметәчәк, рентабельлелеген арттырачак.

КАДРЛАР КЫТЛЫГЫ ҺӘМ ЯСАЛМА ИНТЕЛЛЕКТ

– Ясалма интеллекттан файдаланганыгыз юкмы?

– Хәзер күп җирдә ясалма интеллекттан файдаланалар, бу күпмедер дәрәҗәдә хәлне барыбер җиңеләйтәчәк. Кайдадыр кеше хезмәте кирәкми башлагач, аларны башка эшкә урнаштырып булачак. Без бу юнәлештә эшлибез инде. 15 декабрьдә ИТ-парк ачтык, аны җиһазландырдык. ИТ-тармагында эшләү белән кызыксынучылар, үз продуктларын булдырып, Кукмарадагы ИТ-парк аша Казанга сатачак. Казан белән килешү имзаладык инде. Заманча җиһазлар сатып алдык. Уңайлы шартлар тудырдык. Программалар да, мультфильмнар да бар. Безнең Кукмарада туган кызыклы егетләр бар. Алар инде 5–7 ел Казанда эшли, компанияләрендә 500-700 кеше, алар бездә теркәлгән. Үз продукцияләрен саталар, онлайн система аша безнең егетләргә дә булышачаклар һәм акча эшләячәкләр. Бөтен кешенең дә өендә куәтле компьютерлар юк бит, ә без бирегә шундыйларны алып куйдык. Мин, бу киләчәктә үз җимешләрен бирер, дип уйлыйм. Мәскәүнең бер компаниясе бездә теркәлә. Алар ясалма интеллектка өйрәтү белән шөгыльләнә. Без башкарма комитет хезмәткәрләренең барысын да ясалма интеллектка өйрәтүне планлаштырабыз. Әлеге технологияне районыбыз предприятиеләрендә дә кертәчәкбез.

– Сергей Димитриевич, йөз еллык киез итек басуны да онытмыйча, бер үк вакытта ясалма интеллектка да ни рәвешле өйрәнеп була?

– Без заманадан артка калмаска тиеш. Ниндидер яңалык барлыкка килүгә, аны кертү зарур. Шулай эшләргә тырышабыз да.

2 НЧЕ АМБИЦИЯЛЕ БУРЫЧ

2030 ЕЛГА 50 МИЛЛИАРД СУМ КЕРЕМ АЛЫРГА НИЯТЛИБЕЗ! БУ, БИЛГЕЛЕ ИНДЕ, БИК АМБИЦИЯЛЕ БУРЫЧ. ӘММА МИН, ЭШЛИ БАШЛАГАЧ УК, КУКМАРАДА 200 ТОННА СӨТ ҖИТЕШТЕРӘЧӘКБЕЗ, ДИГӘН ИДЕМ. БАРЫСЫ ДА КӨЛДЕ, ЫШАНМАДЫ, МӨМКИН ТҮГЕЛ, ДИП САНАДЫ... БИК МӨМКИН! МИН МОҢА ЫШАНАМ! БАРЫСЫ ДА ХӘЛДӘН КИЛӘЧӘК. БАРЫ ТИК ЭШЛӘРГӘ, ДӨРЕС ЮНӘЛЕШТӘ АЛГА БАРЫРГА ГЫНА КИРӘК.

САННАР ГЫНА:

6402 млн сум – 2023 елның 10 аенда авыл хуҗалыгы тулаем продукциясе шулкадәрне тәшкил иткән (2022 елның шул чорындагына караганда 91%).

43090 баш мөгезле эре терлек (узган елның шул чорындагына караганда 104%). Шул исәптән **16243 баш сыер** (2022 елның шул чорындагына караганда 1062 башка артыграк).

2023 елның 11 аенда **142790 тонна сөт** җитештерелгән (2022 елның шул чорындагына караганда 112% артыграк).

Бер сыердан савылган сөт **8978 кг** тәшкил иткән (2022 елга карата 102%).

Мөгезле эре терлекнең тәүлеклек артымы **1017 грамм** тәшкил иткән (2022 елда 1013 грамм булган).

УҢЫШ БӨРТЕГЕ

Наилә Хәйретдинова

Гүзәлия Әнсар кызы Гыйззәтуллина – «Кукморзерноторг» ҖЧҖ генераль директоры. Аның Кукмарадагы зур хуҗалыгы, ашлыкны туплап, аны бөтен Россия төбәкләренә һәм чит ил сатып алучыларына җибәрелгәнче саклый торган бердәнбер элеватордан гыйбарәт. Ашлык сату белән шөгыльләнү өчен, аналитик фикер йөртү сәләте, логистикадагы барлык чылбырларны, куркынычларны күзаллый белү, базарны җентекләп өйрәнү һәм башка бик күп нәрсәләр кирәк. Яшь, матур хатын шундый җитди бизнеста уңышлы эшмәкәр булып ничек үсеп китә алган соң? Бу сорауга барысыннан да яхшырак итеп Гүзәлия ханым үзе җавап бирер, дип уйлыйбыз.

Фотолар «Кукморзерноторг» ҖЧҖ тарафыннан бирелде. РЕКЛАМА

ЭЛЕВАТОРГА АЛЫП КИЛГӘН ЮЛ

Мәктәптә укыган вакытта ук, мин республика районнары буйлап күп йөрдем. Әти банкта авыл хуҗалыгы предприятиеләренә кредит бирү бүлеге җитәкчесе иде һәм мине үзе белән һәркайда, һәр командировкасына алып йөрде. Хуҗалыкларның ничек эшләвен, нәрсәгә мохтаҗ булганын, нинди кыенлыклар кичергәнен күрдем. Аннары дөньякүләм икътисад белгечлеге буенча Татар-Америка төбәк институтын тәмамладым, Россия дәүләт икмәк инспекциясенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә баш бухгалтер булып эшләдем.

Ләкин ниндидер оешмага барып, акча санап утыру холкыма туры килми. Бездә лаборатория мөдире булып бер гаҗәеп ханым эшләде. Ул, бөртекле ашлыкны татып карап, аның бөтен органолептикасын билгели иде, ә икмәкне ашап карап, аңа ничә процент шикәр, ничә процент чүпрә салынганын, нәрсә һәм күпме җитмәгәнен төгәл әйтеп тә бирә иде. Аны сынап карау өчен, без кызлар белән тестлар да үткәрдек. Төрле анализлар ясап, аның саннары белән чагыштыра идек. Һәм алар тәңгәл килә иде! Ул ханымга карап, мин кешенең үз эшен шулкадәр яхшы белүенә соклана идем. Мин дә үз өлкәмдә һәрнәрсәгә энәсеннән җебенә кадәр төшенгән белгеч булырга теләдем.

Тагын күпмедер вакыт мин Россия авыл хуҗалыгы күзәтчелеге хезмәтенең Татарстан Республикасындагы Референт үзәге директоры урынбасары һәм Ашлык сыйфатын бәяләү үзәгендә баш бухгалтер булып эшләдем, әмма ахыр чиктә бюджет өлкәсендә эшнең үзем өчен түгеллеген аңладым. Миңа һәрвакыт ниндидер яңа нәрсә чыгарырга, иҗат итәргә, уйлап табарга кирәк, ә бу «сигездән бишкә кадәр» эш кысасы белән берничек тә ярашмый. Шуңа күрә ярма җитештерү-ваклау заводыннан гыйбарәт шәхси предприятиегә директор итеп чакыргач, шундук ризалаштым. Айга 300 тоннага кадәр ярма җитештерүне шактый тиз җайга салып җибәрдек. Асылда, без Татарстанда үсә торган барлык бөртеклеләрнең ярмаларын саттык: бодай, арпа, вакланган арпа ярмалары, борчак һәм ярдырылган борчак... Аларны Санкт-Петербургка да, Мәскәүгә дә, Түбән Новгородка да, әлбәттә, Казанга да җибәреп тордык.

Ләкин эш җайланган рельсларга кереп утыру белән, тагын берәр яңа нәрсә эшләү теләге туды. Күңелдә хыял йөри, һәм ул бүген дә яши. Бу хыял – ашлыкны басудан кибет киштәсенә китереп җиткерә торган предприятие булдыру. Максат – чылбыр буыннары санын кыскарту һәм продуктның үзкыйммәтен киметү. Хуҗаларга: «Әйдәгез, элеватор алыйк, аннан соң хуҗалык һәм фермерлардан да ашлыкны үзебез сатып алырбыз», – дип тәкъдим иттем.

Мин элеватор сатучыларны эзли башладым. Бу хәл 2018 елда булды, ул вакытта республикада ике элеватор сатыла иде. Казанда һәм Кукмарада. Казан элеваторын шунда ук исемлектән сызып ташларга туры килде, чөнки мин аңлый идем: кайчандыр ул башкала читендә булган, ә хәзер бу элеватор шәһәр эчендә калган. Димәк, җирнең аренда хакы кыйммәт, киләчәктә бу җирне тартып та алырга мөмкиннәр.

Шулай итеп, Кукмара гына калды.

ЗАМАНЧА БИЗНЕС ДӨНЬЯСЫНДА

Әмма элеваторны сатып алырга килгәч, кемнеңдер бездән өлгеррәк булуы ачыкланды. Ул кешеләрне таптым, элеваторны арендага алырга сөйләштем. Кул биреп килештек тә, мин эшкә керештем. Элеватор иске, бик нык җимерелгән хәлдә иде, аңа килгән тимер юл инде ун ел кулланылмаган. Хезмәткәрләр тупладым, килү-китү юлларын рәтләдек һәм бөртекле ашлыкны кабул итү, саклау һәм эшкәртү белән шөгыльләнә башладык.

Әкренләп без аякка бастык, үсә-күтәрелә башладык. Мин элеваторга килгәндә, иң күбе 5000 тонна бөртекле

сидияләр бирә, шуңа күрә Россиянең иң ерак төбәкләре өчен дә безнең ашлыкны сатып алу отышлы.

Эре трейдерлар, кагыйдә буларак, ашлыкны зур партияләр белән сатып ала. Августка, сатып алу чоры башланган вакытка, мин инде аларга заказны, ягъни ашлыкны алдан әйтеп куелган күләмдә әзерлим. Менә, әйтик, мин аларга 3000 тонна бодай җыеп бирәм, дип килешәбез. Әмма берьюлы 3000 тонна ашлык сата алырлык эре хуҗалыклар бездә алай күп түгел. Шуңа күрә мин ашлыкны вак-вак партияләр белән җыям һәм шулардан заказга кирәк кадәр туплыйм. Бу ашлыкларын яхшы бәягә сатып җибәргән фермерларга да, ул ашлыкны безнең элеватордан туп-туры эчке базарга (кошчылык, терлекчелек комбинатларына) яки экспортка җибәрә торган трейдерларга да отышлы. Бездән арыш һәм бодайны он тарту комбинатлары, мәсәлән, Санкт-Петербургтан берничә предприятие ала.

Хәзер без үсешнең шундый ноктасына килеп җиттек ки, ашлык саклау мәйданнарын арттыру таләп ителә. Ашлыкны сатып алырга теләүчеләр бар, ашлык та бар, ә аны саклау урыннары җитми.

Шуңа күрә, беренчедән, хәзерге элеваторны үзгәртеп корырга, икенчедән, янәшәдә тагын берне – яңасын төзергә карар кылынды. Аның өчен җир бар, яңа элеватор төзү проекты килештерү стадиясендә. Хәзерге вакытта без берьюлы 37000 тонна ашлык саклый алсак, иске элеваторны яңартып, яңасын төзеп куйганнан соң, берьюлы саклана торган ашлыкның гомуми күләме 160 000 тонна тәшкил итәчәк.

ашлык саклап була иде. Беренче елда ук мин бу санны 20000 тоннага җиткердем, ә икенче елдан инде гомуми әйләнеш хисабына 100 процент куәтенә эшләтүгә ирештем. Хәзер безнең элеваторның номиналь саклау күләме – 37000 тонна. Сезон дәвамында без бу санны 110 проценттан 170 процентка кадәр күтәрергә өлгерәбез. 70 000 тонна ашлык саклаган вакыт та булды.

Без төбәктәге барлык хуҗалыклар, шулай ук чиктәш Киров өлкәсе белән эшлибез. Әлбәттә, көндәшлек юк түгел, чөнки элеваторлар Татарстанның һәр районында бар, әмма без цивилизацияле бизнес дөньясы кануннары кысаларында үзара килешеп эшли алабыз. Әлбәттә, яңа хуҗалыкларны җәлеп итү өчен, күп очрашулар үткәрергә, шалтыратырга, өстенлекләребез турында сөйләргә туры килә, әмма хәзер безне инде беләләр һәм еш кына үзләре элемтәгә чыгалар.

Безнең ашлыкны илнең күп шәһәрләрендә сатып алалар, хәтта экспортка да җибәрәбез. Мәсәлән, Иран, Литва, Латвиягә. Шунысын да искә алып үтим: ике яктан да кызыксыну булганда, берниндиe санкцияләр дә комачауламый. Ә андый кызыксыну бар. Литва быел безнең Казан арышын алды.

Россиянең эре трейдер ширкәтләреннән безнең белән хезмәттәшлек итүчеләр исемлегендә «ПРОДИНВЕСТ» компаниясе (Барнаул), «Каравай» ҖЧҖ (Мәскәү), «ЭФКО» компанияләр төркеме һәм башкалар бар. Россия тимер юллары ерак арага товар ташуга суб-

МӘСЬӘЛӘСЕ БАР ИКӘН, ДИМӘК, ЧИШЕЛЕШЕ ДӘ ТАБЫЛАЧАК

Безнең штатта 80 хезмәткәр. Хәзер беркем дә элекке кебек административ ялга китми, чөнки бездә сезонлы эш юк. Элеваторда эш тәүлек буе бара. Димәк, яхшы кадрларга һәрвакыт ихтыяҗ бар. Элеваторга эшкә кешеләрне урамнан алып кереп булмый. Ашлык киптерүчеләр бөртекледәр белән нәрсәне ничек эшләргә, лаборантлар ашлыкка гамәлдәге закон нормалары нигезендә ничек анализ ясарга, аны ничек тикшерергә икәнен, тракторчылар техника серләрен яхшы белергә тиеш. Кеше табу бик кыен. Штатымда хезмәткәрләрнең шактые өлкән яшьтә. Яшьләрне җәлеп итү җиңел түгел. Мәсәлән, тракторчыкомбайнчы һөнәренә кайда укытуларын

белешәбез, ул уку йортларын тәмамлаучыларны үзебезгә чакырабыз. Бездән китмәсеннәр өчен, лаеклы хезмәт хакы түләргә тырышабыз. Лаборант белгечлеге белән хәл катлаулырак. Хәзер бер яшь кызны алдык, аны үзебезнең тәҗрибәле хезмәткәрләр өйрәтә. Вакыт-вакыт кешеләрне ашлык сыйфатын бәяләү үзәгенә курсларга җибәрәбез. Кадрлар мәсьәләсен һәрвакыт контрольдә тотам.

Әгәр законнарны төгәл үтәсәгез, нинди лицензияләр кирәк икәнен белсәгез, күзәтчелек итү, тикшерү органнарының барлык күрсәтмәләрен башкарсагыз, беркем дә сезгә гадел бизнес алып барырга комачауламаячак. Теләсә нинди эшне башлаганда, аның эчке ягын белергә кирәк. Чөнки, мәсәлән, килдең дә ашлык сата башладың түгел. Ашлыкның сыйфатына, әзерлегенә, аны эшкәртүгә бәйле нечкәлекләр бихисап. Бу процессны барысы да дөрес булырлык, дәүләт стандартына туры килерлек итеп җайга салып җибәрү өчен төгәл белемнәр кирәк.

Безнең элеватор торак пунктның үзәгендә диярлек урнашкан. Халык тузанга һәм ашлык киптерү җайланмаларының тавышына зарланмасын өчен, чистарту җайланмаларын камилләштерергә, тавыш йоту корылмалары ясарга туры килә. Синең белән бер территориядә яшәүче һәм эшләүчеләрнең сүзенә колак салу мөһим.

Әле Кукмарада эшли генә башлаган вакытта ук, хакимият башлыгы белән таныштым. Миңа аның районда шәхси бизнесны үстерүгә мөнәсәбәте бик ошады. Шул көннән бирле без аның белән уртак мәнфәгать нокталарын табып, даими бәйләнештә торабыз. Кукмара терлекчелек районы буларак билгеле. Шәхси хуҗалыкларга ярдәм итү йөзеннән район башлыгы Сергей Димитриевич Димитриев мондый системаны тәкъдим итте: май аенда без шәхси хуҗалыклардан фураж оны өчен бик түбән бәядән аванс җыябыз. Көз көне исә, бәя бер ярым тапкыр арткач, без аларга мал азыгын шул иске хактан бирәбез. Җирле хакимият белән тормышка ашырыла торган әлеге уртак программабыз үзенең бик нәтиҗәле булуын раслады инде.

Мин кыенлыклардан курыкмыйм һәм аларны җиңәргә гадәтләндем. Асылым белән мин – лидер һәм, мөгаен, спорт ярдәмендәдер, үз теләгемә ирешергә күнектем. 6 яшьтән 16 яшькә кадәр йөзү белән профессиональ рәвештә шөгыльләндем, спорт мастеры дәрәҗәсен алдым. Профессиональ спорт үткәндә калса да, физик хәрәкәтне үзем өчен көн саен мәҗбүри шөгыльгә әйләндердем. Иртән, һава торышы һәм кәефем нинди булуга карамастан, кроссовка киям дә 10 километр йөгереп кайтам.

Өйдә утырып, аш-бәлеш пешерү – минем өчен түгел. Ә менә ерак дистанцияләрне узып җиңүгә ирешү, катлаулы бизнес мәсьәләләрен хәл итү – мавыктыргыч шөгыль. Тагын шуны да истә тотарга кирәк: әгәр ниндидер мәсьәлә килеп чыккан икән, димәк, аның чишелеше дә табылачак.

ДӨРЕС ТУКЛАНДЫРУ – ҮСЕШ НИГЕЗЕ

2020 ЕЛДАН «ЛИДЕР» ҖЧҖ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҺӘМ РОССИЯ ХУҖАЛЫКЛАРЫ ӨЧЕН 28 АЗЫК МИКСЕРЫ ЯСАДЫ ҺӘМ МОНТАЖЛАДЫ. ПРЕДПРИЯТИЕ ШУЛАЙ УК «КАМАЗ» МАШИНАСЫНА КӨЙЛӘНГӘН АЗЫК ӨЛӘШҮ, ВАКУУМЛЫ ТӨРГӘКЛӘҮ ҖАЙЛАНМАЛАРЫ ДА ЭШЛӘП ЧЫГАРА.

Кукмараның «Лидер» җәмгыяте белгечләре җитештерә торган стационар азык миксерларына, «КАМАЗ» машинасына көйләнгән эремә ясау узеллары һәм азык өләшү җайланмаларына Татарстанда гына түгел, аннан читтә дә ихтыяҗ бар.

Болар барысы да техниканың сыйфаты, аның универсальлеге, теләсә кайсы хуҗалыкта куллану мөмкинлеге белән бәйләп аңлатыла ала. Тагын бер мөһим өстенлек – бәяләрнең югары булмавы.

– Без «Росагролизинг» компаниясендә аккредитация уздык, бу исә безнең партнерларыбыз – авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә өч процентлы кредит алырга мөмкинлек бирә, – ди предприятие җитәкчесе Азат Нәбиев. – Моннан тыш, күп хуҗалыклар җиһазларны республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган 70/30 программасы нигезендә ала. Әлеге программа авыл хуҗалыгы техникасын сатып алуда ярдәм күрсәтүне күздә тота: дәүләт оешмаларга субсидия бирә. Безнең җиһазларга 12 айлык яки 700 мото-сәгатьлек гарантия каралган. Ел дәвамында без аңа техник хезмәт күрсәтәбез, ватылган очракта ремонтлыйбыз.

Терлекчелек өчен кирәкле җиһазлар ясап чыгара торган предприятие 2020 елда эшли башлый. Аның нәкъ менә Кукмарада оешуын очраклы хәл дип әйтеп булмый. Районның үсешен сөтчелек тармагыннан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Монда савым сыерларының баш саны ел саен арта бара. Бүген районның авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләре үз алдына колачлы бурыч куя – 2024 елда савым күләмен 500 мең тоннага кадәр җиткерү.

Сөтнең продуктлылыгын арттыру күп факторларга бәйле. Боларның иң мөһимнәреннән берсе – терлекләрнең дөрес рационы.

Чит илләрдә ясалган азык миксерларын эксплуатацияләү үзенчәлекләрен өйрәнеп, «Лидер» белгечләре безнең җиһазлар конструктив яктан кайбер урыннарда аерылып торырга тиеш, дигән нәтиҗәгә килә. Бу, нигездә, климат үзенчәлекләре белән бәйле. Әйтик, гидравликаны механик конструкциягә алыштырырга дигән карарга киләләр, ә миксер казанының оптималь күләме 30 кубометр булырга тиеш, дип билгелиләр. Шул ук вакытта монда Россиянең азык-төлек җитештерү өчен яраклы, ашалуга чыдам металларының иң яхшы маркалары кулланыла.

– Без ясый торган азык миксерының шнек системасы азык катнашмасындагы төрле ингредиентларның җентекләп ваклануын һәм болгатылуын тәэмин итә, – дип аңлата Азат Нәбиев. – Бу исә сөтнең продуктлылыгын арттырырга булыша торган азык әзерләү мөмкинлеген бирә. Безнең миксерларны кулланып, күп хуҗалыклар, хәтта рационны да үзгәртмичә, бер сыердан тәүлеклек савым күләмен 4–5 литрга арттырды.

«Лидер» ҖЧҖ җитештерә торган җиһазларны кулланучылар аларның нәтиҗәлелегенә үзләре дә инана алды. Моны саннар да раслый: хуҗалыкларда 1200 баш савым сыеры булса, азык миксеры үз бәясен (9,2 миллион сум) бер ай эчендә аклый. Өстәвенә, Кукмара миксерлары авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре өчен бик кирәкле сыйфат – кулланылышта гадилеге һәм чыдамлылыгы белән аерылып тора.

Сүз уңаеннан, миксерлар куллану кеше факторына бәйле куркынычны тулысынча диярлек юкка чыгара. Кул көче белән ашаткан очракта, бер сыерга – печән генә, икенчесенә он гына эләгергә мөмкин. Программалаштырылган миксер исә азыкның начар болгатылуына юл куймый. Димәк, азык яхшырак ашала һәм нәтиҗәдә савым күләме дә югарырак була. Һәм, әлбәттә, акча да янга кала дигән сүз. Әйтик, кайбер хуҗалыклар тәүлеккә 130 тонна азык тоткан булса, азык миксеры урнаштырганнан соң, 90 тонна да җитә.

SMART
+7 (965) 581-09-02 lider_kuk@mail.ru
kukmaragro.ru

Александр Ефремов фотолары, «Лидер» ҖЧҖ тарафыннан бирелде. РЕКЛАМА

КУКМАРА АГРАР КӨЛЛИЯТЕ: ХАЛЫКАРА СТАНДАРТЛАР БУЕНЧА, ЭШ БИРҮЧЕЛӘР БЕЛӘН ЭЛЕМТӘДӘ

Авыл хуҗалыгы өчен грамоталы белгечләр әзерләү – илебез мәгариф системасы каршында торган иң өстенлекле бурычларның берсе. Икътисадның структурасы ничек кенә үзгәрсә дә, авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәреннән башка IT-белгечләр дә, табиблар да, хәрбиләр дә булмаячак.

Хәзерге заман авыл хуҗалыгы – икътисадның югары технологияле катлаулы тармагы, аның өчен профессионаллар әзерли торган уку йорты иң югары стандартларга туры килергә тиеш. Татарстанда мондый уку йортлары бар. Шуларның берсе – Кукмара аграр көллияте.

Рәсми рәвештә көллияткә (ул вакытта – һөнәр училищесы) 1962 елда нигез салына, әмма аның тарихы тагын да әүвәлрәк башлана: 1936 елда Кукмарадан ерак булмаган Янил авылында МТС төзелә, ул якын-тирә хуҗалыкларга техника белән хезмәт күрсәтә, кадрлар мәсьәләсендә ярдәм итә. Шул МТС нигезендә соңрак училище барлыкка килә, анда киң профильле тракторчы-машинистлар әзерли башлыйлар. 2000 елда ул һөнәри лицей итеп үзгәртеп корыла, ә 2009 елда аграр көллияткә әйләнә.

– Озак еллар эшләү дәверендә безнең уку йорты күп профильле урта һөнәри белем бирә торган укыту-тәрбия үзәгенә әверелде, – ди көллият директоры Азат Гатин. – Соңгы вакытта бездә матди-техник база шактый яңартылды, белем бирүдә иң яңа технологияләр дә кулланыла.

2018 елда Кукмара аграр көллияте һөнәри белем бирүнең ресурс үзәге статусын алды. Бу статус учреждениенең халыкара стандартларга җавап бирүен һәм эш бирүчеләрнең таләпләренә туры килгән программалар нигезендә эшләвен белдерә.

Сүз уңаеннан, көллият эш бирүчеләр белән даими элемтәдә тора, чөнки бүген чын белгечләрне башкача әзерләү дә мөмкин түгел. Мондый партнерлар исемлегендә төрле авыл хуҗалыгы техникасы җитештерүче компанияләр (Ростсельмаш, Гомсельмаш, КАМАЗ) һәм аларның дилерлык үзәкләре, шулай ук районның авыл хуҗалыгы предприятиеләре (мәсәлән, Вахитов исемендәге авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы, «Урал», «Восток», «Әсәнбаш-Агро» ҖЧҖ) бар.

Көллиятнең үз хуҗалыгы, 180 гектар җире дә бар, анда студентлар берничә төр культуралы үсемлек, яшелчә үстерәләр, авыл хуҗалыгының алдынгы ысулларын өйрәнәләр.

Бүген көллияттә 500 дән артык студент белем ала, алар арасында Татарстан районнарыннан гына түгел, Киров өлкәсеннән дә яшьләр бар. Бирелә агрономнар, авыл хуҗалыгы техникасын эксплуатацияләү һәм ремонтлау, газ белән тәэмин итү җиһазларын һәм системаларын монтажлау һәм эксплуатацияләү, автомобильләр ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү белгечләре, авыл хуҗалыгы җитештерүе предприятиеләре өчен мастерлар, шулай ук аш-су осталары һәм кондитерлар әзерлиләр. Көллият икътисадта мохтаҗлык булган әзерлек юнәлешләренә ел саен мониторинг үткәрә һәм республика икътисады ихтыяҗларын исәпкә алып эш йөртә.

2021 елдан уку йорты «Россиянең иң яхшы көллиятләре» илкүләм конкурсы лауреаты булып тора. Моннан тыш, көллият даими рәвештә төрле федераль грантлар конкурсларында катнаша һәм 2020 елда «Мәгариф» федераль илкүләм проекты кысаларында грант ота. Грант акчалары ярдәмендә «Агрономия», «Сәнәгый бакчачылык», «Сити-фермерлык», «Авыл хуҗалыгы машиналарын эксплуатацияләү» компетенцияләре өчен заманча җиһазландырылган остаханәләр булдырыла.

2022 елда көллият «Профессионалитет» федераль проекты кысаларында белем бирү-җитештерү кластерларын оештыруга тагын бер федераль грант ота. Нәтиҗәдә заманча остаханәләр булдырыла, аларда «цифрлы игенчелек», «машина-трактор паркын эксплуатацияләү», «электрон ягулык системаларын (югары басымлы ягулык насосларын, эчке янулы двигательләрне, форсункаларны) диагностикалау һәм ремонтлау», «автомат тизлек күчерү тартмаларын диагностикалау һәм ремонтлау» юнәлешләре буенча белем бирелә.

– Бүген аграр көллиятләр барлык инновацияләрне туплап эш йөртергә тиеш, – ди Азат Гатин. – Шул очракта гына без авыл хуҗалыгы өчен тотрыклы киләчәгебезне тәэмин итә алырлык кадрлар үстерә алабыз.

Фото Кукмара аграр көллиятеннән алынды. РЕКЛАМА

Евгения Чеснокова

«Росстат» мәгълүматлары буенча, Россиядә эшсезлекнең тарихи минимумы теркәлгән – 3,5 процент чамасы. Татарстанда әлеге күрсәткеч тагын да кимрәк – якынча 2,5 процент. Бу күренешнең капма-каршы ягы – кадрлар кытлыгы. Безнең югары һәм урта махсус уку йортлары тиешле күләмдә профессионаллар укытып чыгарырга әзерме? Эшкә алучылар белем бирү оешмалары белән актив хезмәттәшлек итәргә телиме? Хезмәт базары ихтыяҗлары белән югары уку йортлары, көллиятләрдәге әзерлек юнәлешләре арасында тигезлек сакланамы?

Боларның барысы турында да Татарстан мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары Андрей Поминов белән әңгәмә кордык.

ИНЖЕНЕР, IT-БЕЛГЕЧ, УКЫТУЧЫ... РЕСПУБЛИКА ИКЪТИСАДЫНА НИНДИ КАДРЛАР ҖИТМИ?

– Андрей Иванович, безнең югары һәм урта һөнәри уку йортларында кадрлар әзерләү структурасы икътисадның реаль секторы ихтыяҗларына ни дәрәҗәдә туры килә?

– Билгеле, без икътисадның кадрларга булган ихтыяҗларын мөмкин кадәр канәгатьләндерергә тырышабыз. Ихтыяҗның гел үзгәреп торуын исәпкә алып, махсус урта уку йортларында укыту планнарын ел саен яңартабыз. Югары уку йортларына кабул ителүчеләрнең контроль санын үзгәртәбез. Әмма эшкә алучыларның ихтыяҗлары бик тиз үзгәрә, һәм алар һәрвакытта да бөтен белем бирү циклы (техникум яки бакалавриатның дүрт елы) тәгәлләнгәнче көтәргә әзер түгел. Аларга белгечләр бүген үк кирәк бит.

Студентларны тулы булмаган эш көненә, кичке сменага хезмәткә урнаштыру хисабына проблема өлешчә хәл ителә... Моннан тыш, без кыска программалар буенча әзерлек тәкъдим итә алабыз – берничә айлык яки ярты еллык курсларда укытабыз. Бүген безнең һөнәри урта белем бирү учреждениеләре базасында 600дән артыграк шундый программа бар, алар югары уку йортларының яки предприятиеләрнең үзләренең базаларында да эшли. Мондый курсларны эш бирүчеләр дә, укучылар үзләре дә финанслый. Кайбер өстенлекле юнәлешләрдә исә мондый программалар буенча укытуга республика бюджетыннан түләнә.

– Эш бирүчеләр белән мәгариф системасын үзара якынайтуда тагын нинди чаралар булыша?

– Һөнәри урта белем бирү системасында без инде 2014 елдан бирле техникум һәм көллиятләр базасында ресурс үзәкләре булдырабыз. Бу узган ел федераль дәрәҗәдә эшли башлаган «Профессионалитет» программасының прообразы булып тора. Аның төп идеясе – махсус урта уку йортларында кадрлар әзерләүгә төп эш бирүчеләрнең үзләрен җәлеп итү. Конкрет предприятиеләр ихтыяҗларын канәгатьләндерерлек укыту мәйданчыклары булдыру, укыту планнарын аларга яраклаштырып үзгәртү, укытуга реаль сектор хезмәткәрләрен җәлеп итү, уку вакытын кыскарту яки аны практик дәресләр файдасына арттыру күздә тотыла. Гадәти программалар буенча мондый эш мөмкин түгел, ә бу очракта студентлар беренче курстан ук предприятиеләрдә практика үтәчәк һәм гарантияле эшкә урнашу мөмкинлеген алачак. Әле алай гына да түгел, укыту планнары тиешенчә төзелсә, уку вакытын да шактый кыскартып булачак. Кайбер очракларда хәтта бер елга да кыскаруы ихтимал.

Бездә инде шул рәвешле эшләүчеләр дә бар: Алабуга политехника көллияте – «Алабуга» МИЗ белән, Чаллы техникумнары – КАМАЗ белән. Беренче этапта «Профессионалитет» программасында Татарстан безнең мәгариф оешмалары базасындагы ундүрт кластер белән катнашачак. Бездә барлыгы 88 дәүләт махсус урта уку йорты бар, һәм менә аларның ундүртесе инде – программада.

Фото: tatar-inform.ru

Федераль дәрәҗәдә исә илдәге барлык техникум һәм көллиятләрнең якынча өчтән бере 2027 елга кадәр әлеге программага керер, дип фаразлана.

– Югары уку йортлары турында да сөйләшик. Сез, республикада бюджетка кабул итү саннарына ел саен төгәллек кертелә, дидегез. Бу федераль дәрәҗәдә хәл ителмимени?

– Башта төбәкләр белән килештерелә. Югары уку йортлары үзләренең мөмкинлекләре белән таныштыра, без үзебезнең ихтыяҗны тикшерәбез, республика өчен кирәкле белгечләр тәгаенләнә, болар барысы да Мәскәүгә җибәрелә. Анда кабул итүнең контроль саннары билгеләнә, һәм без әзерлекнең теге яки бу юнәлеше буенча билгеле бер санда бюджет урыннарына ия булабыз.

Биредә дә эш бирүчеләр белән мөнәсәбәтләрне җайлауның яңа чаралары бар. Мәсәлән, алдынгы инженерлык мәктәпләре ачу. Хәзер бездә шундый өч мәктәп эшли – КАМАЗ химаясендә Казан федераль университеты базасында, КИТУ-КХТИ базасында (анысы СИБУР, Татнефть кебек партнерлар химаясендә), Иннополис университеты базасында (IT-сектордан берничә партнер компания булышлыгында). Илдә шундый утыз мәктәп бар инде, тагын унны ачу ниятләнә. Шул рәвешле конкрет эш бирүчеләрнең конкрет мәнфәгатьләре кайгыртыла.

– Шулай да безнең югары белем бирү системасында тәкъдим һәм ихтыяҗ мәсьәләсендә кыенлыклар бармы? Бервакыт бездә юрист һәм икътисадчыларның артык күп булуы хакында актив сөйләнелә иде...

– Әйе, шундый фикер йөри шул. Аларны чынлап та күп әзерлиләр. Әмма бюджет хисабына – бик аз санда гына. Моннан берничә ел элек әлеге юнәлешләрдә бюджет урыннары сизелерлек киметелде. Дәүләт үз өстенлекләрен билгеләгәч, соңгы елларда бездә икътисадның реаль секторы өчен кадрлар – инженерлар, IT-белгечләр, педагогларны бюджетка кабул итүнең контроль саннары арттырылды. Әмма кешене беркем дә акча түләп юристлыкка яки икътисадчыга укудан тыймый. Сүз уңаеннан, бүген без инде кайбер даирәләрдә квалификацияле юрист һәм икътисадчылар җитешмәвен тоябыз.

– Элегрәк мәктәпне тәмамлаучыларның барысы да диярлек югары уку йортына керергә омтыла иде. Бүген исә техникум һәм көллиятләрнең популярлыгы көннәнкөн арта бара кебек...

– Бу чыннан да шулай, бүген безнең тугызынчы сыйныфны тәмамлаучыларның яртысыннан артыгы һөнәри урта белем бирү системасына бара. Әлеге җәһәттән Казан мәгълүмати технологияләр һәм элемтә техникумын, Казан педагогика көллиятен, төзелеш көллиятләрен мисалга китерергә була.

Бу трендның берничә сәбәбе бар. Беренчедән, соңгы елларда һөнәри урта белем бирү системасы үзе үзгәрде. Анда әзерлек юнәлешләре исемлеге зурая, матди-техник базалар яңара. Икенчедән, мәктәп балаларының күбесе башта база һөнәрен алырга, аннары инде югары уку йортына керергә һәм, ихтимал, шул ук вакытта эшләргә дә тели. Әйтик, педкөллияттән соң күп кеше балалар бакчасына тәрбияче булып яки башлангыч сыйныфларны укытырга мәктәпкә эшкә урнаша, читтән торып исә югары уку йортына керә.

– Бүген күп кенә зур предприятиеләр үзләренең корпоратив университетларын ача. Мондый уку йортлары традицион югары уку йортларына көндәш була аламы?

– Юктыр, дип уйлыйм. Бу бик зур чыгымнар сорый торган эш, аны бик зур корпорацияләр генә башкарып чыга ала. Бездә, мәсәлән, бу – КАМАЗ, Яшел Үзәндәге суднолар төзү заводы базасында да шундый үзәк бар. Әмма анда бит «озын» программалар буенча әзерлек алып барылмый, нигездә бу квалификацияне күтәрү яки кабат укыту системасы гына. Шунлыктан мәгариф системасы ягыннан кадрларга ихтыяҗ барыбер кимеми. Йомгаклап әйткәндә, болар бер-берсен тулыландыра торган нәрсәләр.

ТАТАРСТАН ҺӨНӘРИ УРТА БЕЛЕМ БИРҮ СИСТЕМАСЫНА БҮГЕН 100 ОЕШМА КЕРӘ, ШУЛАРДАН 88Е – ДӘҮЛӘТНЕКЕ. КӨЛЛИЯТ ҺӘМ ТЕХНИКУМНАРДА 74 МЕҢГӘ ЯКЫН КЕШЕ УКЫЙ, АЛАРНЫ ЕЛ САЕН 17 МЕҢНӘН АРТЫГРАК СТУДЕНТ ТӘМАМЛЫЙ. РЕСПУБЛИКАДА 46 ЮГАРЫ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАСЫ БАР (25 ТӨП УКУ ЙОРТЫ ҺӘМ 21 ФИЛИАЛ). БИРЕДӘ 147 МЕҢ СТУДЕНТ УКЫЙ, БЫЕЛ 49 МЕҢ КЕШЕ ТӘМАМЛАДЫ.

– Бүген икътисадның реаль секторында нинди белгечлекләр аеруча кирәк?

– Инженерлар, IT-тармак, төзелеш комплексы, аграр сектор, нефть химиясе һәм нефть эшкәртү тармаклары белгечләренә зарурлык бар. Педагоглар кирәк – безгә математика, физика, рус теле укытучылары җитми. Мәктәпкәчә белем бирү педагоглары һәм башлангыч сыйныф укытучыларына кытлык зур.

– Әйткәнебезчә, хезмәт базары ихтыяҗлары бик тиз үзгәреп тора. Әмма асылы буенча консерватив булган мәгариф, нинди генә нәтиҗәле чаралар күрелсә дә, барыбер тиз арада гына үзгәрә алмый. Сезнеңчә, кайчан да булса без әлеге каршылыкны җиңә алырбызмы икән?

– Әлбәттә, билгеле бер дисбаланс һәрвакытта да булыр, дип уйлыйм. Бигрәк тә хәзер, ил икътисады тектоник үзгәртеп корылганда, бу әзерлек юнәлешләрендә җитди үзгәрешләр таләп итәчәктер. Әмма безнең югары һәм урта махсус уку йортлары моңа тиз арада җавап кайтарырга тырыша, һәм бу күп очракта уңышлы булып чыга. Шунлыктан, әлеге даирәдә тәкъдим һәм ихтыяҗ арасындагы аерма калса да, ул бик кечкенә булыр, дип өметләнәбез.

ВЗВОД КОМАНДИРЫ



Всеволод Черенков балачактан ук очучы булырга хыяллана. Күз алдында гел озын буйлы, зәңгәр күзле, аксыл чәчле әтисе тора. Ул рейска һәрвакыт йә иртә таңнан, йә төн уртасында китә. Һәм ничектер җиңел генә саубуллашып юлга кузгала: «Мин бүген Гарәп Әмирлекләренә юл тотам. Бер атнадан гына кайтам. Мин бүген Истанбулга китәм. Төнлә генә кайтам. Кичке ашны минсез генә ашагыз, көтмәгез, йокларга ята торыгыз...»

Сева әтисен һәрвакыт көтеп җиткерә торган була. Аңа әтисеннән кыш көне кояш, җәй көне кар, көз көне диңгез исе килеп торуы ошый. Үскәч очучы булырга карар кыла ул. Хәрби очучы!

Николай Крушинин

ЯШЬ ДЕСАНТЧЫ

Хезмәт юлын ул Тәтеш кадет училищесыннан башларга була. Яхшы укый, җәйге каникулларда «Яшь десантчы» лагеренда парашюттан сикерә. Беренче сикерүдән соң ук ул үзендә күккә тартылу тоя һәм хыялына тагын да ныграк омтыла башлый. Сева парашюттан сикерергә дә, укырга да ярата. Барысы да бик уңышлы бара, хыялына көннән-көн якыная, киләчәккә планнар берничә ел алдан язып куела: хәрби очу училищесы, төштә генә түгел, ә өндә дә күк гизү...

Әмма, ни кызганыч, Севаны хәрби училищега кабул итмиләр: хәрби табиблар комиссиясе үткәрми. Ә самолетлар турында хәтта хыялланмаска да кушалар, мондый буең белән кабинага сыймыйсың, янәсе!

АЛМАШ ЭЗЛӘРГӘ КИРӘК

Каршымда озын буйлы, матур егет утыра. Чыпчын блондин. Фильмнарда очучылар нәкъ шундый. Ул елмая гына:

– Буласы булган инде, – дип, иңбашын сикертеп куя. – Укырга кертмәделәр дип үлеп ятыйммыни?

– Хыялың челпәрәмә килгәч, бер дә газапланмадыңмыни?

– Бераз күңелсезләнеп, борчылып йөрдем инде. Ике көн, – дип көлә Сева. – Ә аннары Лаеш техника-икътисад техникумында пилотсыз аппаратлар ясарга өйрәтүләре турында ишеттем дә шунда киттем. Миңа гадәти очучы булырга язмаган икән – тышкы пилот килеп чыгачак. Бу бит тагын да шәбрәк!

Гомумән, башка юл-юнәлеш тапканмын икән, үткәнгә кайгырып утырудан мәгънә күрмим. Әгәр синнән генә тормаган сәбәпләр аркасында теләгәнеңә ирешә алмыйсың икән, икенче, алмаш юл эзләргә кирәк. Менә шул!

«АРХИПЕЛАГ-2023»

Узган җәйдә Лаешның яшь «тышкы пилотлар»ын Новосибирскига «Архипелаг-2023» – пилотсыз авиация ярышларына җибәрәләр.

– Без анда ЦРПК (Һөнәри компетенцияләрне үстерү үзәге. - Ред.иск.) һәм үзебезнең Лаеш техника-икътисад техникумы ярдәме белән бардык, – дип сөйли Сева. – Безгә ярышлар өчен бөтен кирәк-яракны бирделәр, юл чыгымнарын кайгырттылар. Шәп булды! Безнең курстан биш кеше пилотсыз очкычлар белән ныклап шөгыльләнә. Бишесе дә Татарстан командасы составына керде. Безнең җыелма командада Казан авиация техникумы һәм КАИ каршындагы лицей егетләре дә бар иде. Бу бик кәттә ярышлар булды, мондый бәйгеләрдә без үз исемебезне таныту өчен эшлибез. Аннары исем безнең файдага эшләячәк. Шулай булыр дип өметләнәм.

Сәфәрдән соң без Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән очраштык. Пилотсыз аппаратлар, Татарстанда бу тармакны үстерү турында, очышлар тыелу шартларында тренировкаларны ничек һәм кайда уздырырга мөмкинлеге турында сөйләштек. Рөстәм Нургали улы бу өлкәне бик яхшы белә.

Фото: Алсу Шакирова, tatarstan.ru

ТЫШКЫ ПИЛОТ ФИКЕРЕ:

– Үзеңне кызыксындырган өлкәне тап һәм шуңа таба бар. Хәзер теләсә нинди хоббины һөнәргә әйләндереп, акча эшләп була. Кемдер чигәргә ярата һәм заказ буенча рәсемнәр яки киемнәр чигә. Менә минем белгечлекне карыйк. Асылда, бу – техник белгечлек. Әмма ул шулкадәр кызыклы ки, дәрестән тыш вакытта без пилотсыз очкычлар ангарында калып, дроннар белән мәш киләбез, аларны сүтәбез, җыябыз, очырабыз. Дәресләрдә әле искә дә алынмаган нәрсәләрне өйрәнәбез. Чөнки күпме генә укысаң да, һәрвакыт ниндидер өйрәнеп бетермәгән урыннар кала.

ПИЛОТСЫЗ АППАРАТЛАР БУЕНЧА ОТЛИЧНИК

– Сине нәрсәгә өйрәтәләр һәм тагын күпме укыйсың калды?

– Мин хәзер икенче курста, тагын өч ел бар әле. Безгә очкычларны эксплуатацияләү һәм аларга техник хезмәт күрсәтү серләрен өйрәтәләр. Төрле очкычларны өйрәнәбез, аларда «очышлар» ясыйбыз, пилотсыз аппаратларның иң кечкенәләреннән алып бик зурларына кадәр сынап карыйбыз.

– Белгечлегең ничек атала? Син аны кайда кулланырга җыенасың?

– Бу өлкә әле үсештә генә. Ул «Пилотсыз авиация системаларын эксплуатацияләү» дип атала. Мин пилотсыз авиация системалары операторы булачакмын. Росавиация һөнәремнең «Тышкы пилот» дип аталуы яклы.

Һәрхәлдә, бу белгечлекне үзләштергәч, хәрби һәм гражданлык геодезиясе, мәсәлән, картография белән шөгыльләнергә мөмкин. Түбән Новгородка барганда, без нәкъ менә дроннар ярдәмендә күзәтеп торылган юлларны күрдек. Өч елдан шундый операторлар барлыкка килергә тиеш. Хәзер андый геодезистлар, картографлар гадәттән тыш хәлләр министрлыгында гына бар, соңыннан бу белгечлекләргә ихтыяҗ зуррак булачак.

– Син боларның барысын да шулкадәр әйбәт беләсеңме? Мөгаен, бик яхшы билгеләргә генә укыйсыңдыр?

– Пилотсыз очу аппаратлары буенча мин отличник! Һәммәсе дә шундый мавыктыргыч икән, ничек инде отличник булмыйсың, ди. Хәзер, мәсәлән, дрон-рейсинг, безнең тел белән әйткәндә, дрон узышлары популярлашып бара. FPV-дрон дип йөртелгән, ягъни беренче зат белән идарә ителә торган аппаратлар бар. Аны очырту өчен дрон, пульт һәм виар-күзлек (виртуаль чынбарлык күзлеге) генә кирәк. Ярышта махсус каршылык-киртәләр ясалган трассаны үтәсе, моның өчен төрле маневрлар ясый белү таләп ителә, бу шундый мавыктыргыч. Ул дроннар сәгатенә 130-150 км тизлек белән оча ала, андый тизлектә канда адреналин «уйный» башлый. Бик күп уңай эмоцияләр барлыкка килә.

Тирә-якны, очышны күзләр, виар-күзлекләр аша гына кабул итәсең, ә вестибуляр аппарат еш кына чынлыкта нинди торышта булганыңны аңламый, шуңа күрә аны, чын пилотларныкы кебек, күнектерергә, өйрәтергә кирәк.

ВЗВОД! КОМАНДИРОВКАГА – МАРШ!

Бүген икенче курс студенты Всеволод Черенков – взвод командиры. Чөнки ул укый торган белгечлек ярым хәрби белгечлек санала. Техникумда взвод дип утыз кешедән гыйбарәт уку төркеме атала. Техникум укучылары үз белемнәрен практикада да кулланалар. Мәсәлән, декабрьдә алар Краснодарга командировкага барганнар, анда квадрокоптер өчен җиһазларны көйләү белән шөгыльләнгәннәр. Эшне төгәлләп кайткач, укуларын дәвам иткәннәр.

ОЧЫШ ЛӘЗЗӘТЕ

– Кайчандыр син күккә күтәрелү турында хыяллангансың. Хәзер хыялың нинди?

– Укып бетереп, белгечлегем буенча кызыклы эш урыны табарга хыялланам. Пилотсыз аппаратлар белән эшләү уенга охшаган, ул болай да очыш ләззәтен кичерергә мөмкинлек бирә, хәтта җирдә басып торсаң да.

– Ун елдан соң үзеңне кем итеп күрәсең?

– Пилотсыз аппаратлар җитештерү фирмасына нигез салучы буласым килә.

P.S. ЗӘҢГӘР КҮЗЛЕ ОЧУЧЫ ЕГЕТ

Күптән түгел генә «Татарстан» журналы телеграм-каналында (t.me/protatarstan) **#НаОбложкуТатарстана** конкурсы оештырылды.

Үзләренең иң матур, иң оригиналь фотосурәтләрен конкурска юллап, 40 кеше «Татарстан» журналы тышлыгына чыгу өчен ярышты. Алар арасыннан редакция 10 финалистны сайлап алды.

Алга таба тавыш бирү процессына телеграм-каналыбызны укучылар һәм конкурста катнашучыларның җанатарлары төркемнәре кушылды. 27 мең кеше үз кандидатлары өчен иртә-кич, көн-төн тавыш бирде! Нәтиҗәдә «Лаеш техника-икътисад техникумы» ДАҺБУ студенты **Всеволод Черенков** беренче урынга чыкты – аның өчен 14 мең кеше тавыш бирде, бу тавыш бирүчеләрнең 51 %ы дигән сүз.

Һәм ул бүген «Татарстан» журналының беренче тышлыгында!

Татарстанда яшисең – «Татарстан»ны укы!

Аның белән бергә булганда, иң кыю хыяллар тормышка аша!

1 – Сәфәрдән соң без Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән очраштык, – дип сөйләде Всеволод Черенков.

ТАНЫШ БУЛЫГЫЗ: КИЛӘЧӘК ҺӨНӘРЛӘРЕ

«Лаеш техника-икътисад техникумы» дәүләт автономияле һөнәри белем бирү учреждениесе бүген республикада иң яхшылардан санала. Үзенең Авиация уку-укыту үзәге булган Татарстандагы бердәнбер уку йорты ул. Алар Россиядә нибары сигез генә.

ПИЛОТСЫЗ ОЧЫШТА

Экрандагы дрон өскә ыргыла, вираж ясый, түбәнәя һәм искиткеч тизлектә капка аша очып чыга. Карап торышка – гади компьютер уены инде менә.

– Чынлыкта исә мин хәзер дрон симуляторында очарга өйрәнәм. Узыш трассасын үтәм, – дип сөйли студент, киләчәктә пилотсыз очу аппаратлары операторы булачак Андрей Савельев. – Симуляторлар хәзер һаман чынбарлыкка якынрак була бара. Әлбәттә, алар беркайчан да чын очышны алыштырмаячак, әмма идарә күнекмәләрен үзләштерергә булыша. Көн белән төннең теләсә кайсы вакытында, теләсә нинди һава шартларында очарга өйрәнәбез. Һәм иң мөһиме, чын аппаратны ватмыйча, Россия узышларына әзерләнәбез. Бу юлы инде чын узышка.

– Безнең студентлар җәй буе ярышлардан кайтып кермәде. «Профессионаллар»да (халыкара WorldSkills чемпионатының аналогы – ред.иск.) катнаштылар, «Архипелаг-2023» проектлар-белем бирү интенсивында «Пилотсыз авиация» номинациясендә җиде студентыбыз җиңү яулады. «Армия-2023» Халыкара хәрби-техника форумында яшь армиячеләр арасында дрон-рейсинг ярышларын уздырдылар, – ди техникумның техник фәннәр укытучысы Дания Гайнуллина. – Россия узышларында команда белән дә, шәхси ярышларда да без һәрвакыт диярлек призлы урыннар яулыйбыз. Егетләрнең укытучысы Билолетдин Худойдодов үзе дә безнең техникумны тәмамлаган, «Яшь профессионаллар-2022» илкүләм чемпионатының «Пилотсыз суднолар белән тышкы идарә итү һәм алардан файдалану» компетенциясендәге көмеш призеры. Ул ничек уңышка ирешеп булуны үз мисалында күрсәтә һәм укучыларына алган күнекмәләрен ныгытырга булышып тора.

Пилотсыз очу аппаратларының фән-техника, шулай ук халык хуҗалыгының бүгенгесе дә, киләчәге дә булуында хәзер инде шик юк. Бүген Лаеш техника-икътисад техникумы – пилотсыз авиация системалары операторларын әзерли торган Татарстандагы бердәнбер урта махсус уку йорты ул.

ҮЗ «АЭРОПОРТЛАРЫ» БАР

Техникумның Авиация уку-укыту үзәгендә шулай ук самолет һәм вертолет тибындагы авиация техникасына хезмәт күрсәтү белгечләрен дә әзерлиләр. Биредә Росавиация раслаган 25 программа гамәлгә ашырыла. Моннан тыш, үзәктә республиканың барлык профиль компанияләренең диярлек авиация персоналы һөнәри белемнәрен яңарту һәм квалификацияләрен күтәрү курслары үтә.

Моның өчен кирәкле контрольдә тоту, багажны теркәү һәм тапшыру, очышка кадәр тикшерү һәм көтү зонасы – гомумән, бөтен кирәкле нәрсәләр белән җиһазландырылган мини-терминал мәйданчыгы бар.

ДӘҮЛӘТ ЭЧЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ

Биредә «Хокук саклау эшчәнлеге» белгечлеген шулай атыйлар. Моның белән килешми булмый. Үз герблары, намус кодексы, сәгать ярым саен алышына торган каравылда тору...

– Ут! – командасы яңгырый динамиктан, һәм курсант ата башлый.

Компьютер экранында гомуми нәтиҗә күренә – 50 дән 45.

– Хәтта полициядәге ату күнекмәләрен бәяләү буенча да мондый нәтиҗә бик шәп санала, – ди подполковник, махсус фәннәр укытучысы Марат Низамов, курсантының шулай ата белүенә куанып. – Башта биредә без курсантларны бернинди дә куркынычы булмаган электрон корал белән дөрес атарга өйрәтәбез. Россиядә уйлап табылган программа мәргәнне теләсә нинди шартларга «урнаштырырга» мөмкинлек бирә. Курсант бөтен нәрсәгә яхшылап төшенгәч кенә, без аны ядрәсез коралдан аттырабыз. Ату көче чын мылтыктагыча, хәтта дары исе дә бар...

ҺӨНӘРИ ЮНӘЛЕШ БИРҮ

Студентларның «Мәгариф» илкүләм программасындагы «Яшь профессионаллар» проектында җиңүе нәтиҗәсендә техникумда федераль бюджеттан ике остаханә җиһазландырылган – «Пилотсыз суднолар белән тышкы идарә итү һәм алардан файдалану» һәм «Авиация техникасына хезмәт күрсәтү». Студентларны өйрәтү базасы өч пилотсыз очу аппараты, шулай ук фотометрияле программалы заманча ноутбуклар белән баетылган. Замана техникы яки операторына мәгълүмати технологияләрне белмичә һич ярамый.

Илнең технологияләрдәге суверенитетын тәэмин итеп, Лаеш техникумы мөгаллимнәре студентларны якын киләчәктә үзләре эшкә урнашу ихтималы булган предприятие эшчәнлегенә укыганда ук җәлеп итүне популярлаштыра.

АТЭТ
422610, Лаеш ш.
Маяковский ур., 14
+7 (843)-782-80-85
Ltet-tatarstan@mail.ru

Фото: Алсу Шакирова. РЕКЛАМА

акыллы гамәлләр

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Академик **ни өчен** гел эшләргә тиеш

Мацуев уйнаган рояльне **ничек** төзәтергә

«Борынгы» «Запорожец»ка элеккеге данын **ничек** кайтарырга



РҮЗӘЛ ЮСУПОВ: «АКАДЕМИК ГЕЛ ЭШЛӘРГӘ ТИЕШ»

Руфия Фазылова

Картаймый торган кешеләр була, алар гел сафта. Рүзәл Юсупов әнә шундыйлардан. Татарның әлеге милли җанлы академигын белмәгән кеше юктыр. Казан дәүләт педагогика институтында 17 ел ректор булып эшләү дәверендә педагогика юнәлешенә никадәр яңалык керткән кеше ул! Рүзәл Габдуллаҗан улы журналистлар өчен дә чын остаз: тел галиме буларак, матбугаттагы кимчелек һәм хаталарны гел безгә җиткереп-өйрәтеп тора. Яңа елның беренче эш атнасында редакциябезгә килеп, бик кызыклы фикерләре белән уртаклашты ул.

– Рүзәл Габдуллаҗанович, телефоннан сөйләшкәндә: «Эшләп утырам әле», – дидегез. Әллә академиклар бер дә ял итмиме?

– Бер сәгать тә тик утырганым юк, вакытны бушка уздырмыйм. Елга өч китап чыгарам, иллеләп мәкалә бастырам. Эшләгәч, күңел күтәрелә, булдырам, дисең.

Академик исемен йөртү зур дәрәҗә. Мин җиде кеше арасыннан сайландым. Әлеге ышанычны гел аклап торырга, даими эшләргә кирәк. Фәннәр академиясендә язган мәкаләләр, китаплар, чыгыш ясаган конференцияләр буенча һәр ел ахырында язмача хисап тотабыз. Анда буш кәгазь китереп куя алмыйсың. Дәүләт сине укыткан, кеше

Фото: Александр Ефремов

иткән икән, ул белемеңне халык белән дә уртаклашырга тиешсең. Академик гел эшләргә тиеш. Без маршаллар кебек – пенсиягә китмибез. Академик гомере буе яза...

– Сез Казан дәүләт университетында бишкә генә укып, тарих-филология факультетын яшьтәшләрегезгә караганда бер ел алдан тәмамлагансыз. Бу бит гаҗәп хәл. Ул чорда мондый тәҗрибә ничек еш кулланыла иде?

– Андый тәҗрибә беренче булды, дип беләм. Сүзне шуннан башлыйм: туган ягым – Арча районы Кышкар авылыннан ундүрт яшь тулмас борын чыгып китеп, Казан кооперация техникумына укырга кердем. Өч ел эчендә товар белгече һөнәрен үзләштердем. Унҗиде яшь тә тулмаган килеш юллама белән Курган өлкәсенә эшкә җибәрделәр. Ел ярымнан соң хәрби хезмәткә алдылар, анда өч ел гомерем узды. Кыскасы, Казан дәүләт университетына укырга кергәндә, минем инде шактый зур багаж җыелган иде. Тагын шунысын әйтим: техникумда татарча укымаганга күрә, университетның керү имтиханнарына бик ныклап әзерләнергә туры килде. Югыйсә, кулда диплом бар, эшлә рәхәтләнеп. Ә мин армиядә чакта ук үземә максат куйдым: нәкъ менә татар филологиясе өлкәсендә үсәргә. Университетта бер урынга биш кеше иде. Равил Фәйзуллин, Фарсил Зыятдинов, Әнвәр Шәрипов, Фирдәвес Гарипова, Флера Баязитова, Шамил Маннапов – без көчле төркем булдык. Әлеге дә баягы, тәҗрибә булгангадыр инде, икенче курстан ук бөтен факультетка комсомол секретаре итеп куйдылар. Анда бит тарих факультеты, рус бүлеге бар, бик әзерлекле, белемле яшьләр укый иде. Шулар арасыннан мине сайладылар. Бу ышаныч та, дәрәҗә дә булгандыр. Университетта бишле билгеләренә генә укыдым. Ленин стипендиаты идем. Төркемебездәге аерым студентларга төрле юнәлешне сайлау мөмкинлеге тудырылды, миңа исә тәрҗемә теориясе якын тоелды. Шуның өчен ныклап торып шушы юнәлештә эшли башладым.

Ә сезнең сорауга килгәндә, дүртенче курста безнең төркемне авылларга укытырга җибәрделәр. Безне, шәхси план буенча укыган берничә студентны, авылга җибәрмәделәр, ә үзлегебездән укып, имтихан-зачетларны тапшырырга тәкъдим иттеләр. Без шулай эшләдек тә. Алай гына да түгел, бишенче курслар белән бергә дәресләргә йөреп, алар белән дә зачет-имтиханнар тапшырдык. Нәтиҗәдә, бер елда ике курсны уңышлы гына укып чыктык. Университет тарихында менә шундый кызыклы тәҗрибә булды ул.

– Сезне, Мәскәүдә СССР Фәннәр академиясенең Рус теле институтында докторлык диссертациясен яклап кайтканнан соң, 1986 елда педагогика институтының ректоры итеп билгеләгәннәр. Эшне нәрсәдән башладыгыз? Беренче вакытта нинди авырлыклар белән очраштыгыз?

– Ректорлык вазыйфасына килү үзе бер тарих. Шуны гына әйтәм: ул чагында мондый җаваплы вазыйфага зур сынаулар узып, берничә комиссия тикшергәннән соң гына куялар иде. Әле кандидатураңны Мәскәү дә якларга тиеш.

Казан педагогика институтында ул чорда реформа булды дип әйтә алам. Иң зур казанышым дип саныйм – бөтен фәннәрне дә татарча укыта ала торган студентлар әзерләдек. Татар мәктәбен тәмамлаган һәр бала кабул итү имтиханнарын рәхәтләнеп ана телендә бирә алды.

Рейтингтагы йөз педагогика вузының беренче унлыгына кереп, Россия һәм Татарстанның әйдәп баручы югары уку йортларының берсенә әйләндек. Инде конкрет эшләргә килсәк. Табигатем белән хуҗалык кешесе мин. Ректор булып килгәч тә, үземә принцип итеп алдым: уку-укыту, эшләү урыннары төзек, матур, җылы булырга тиеш. Казан педагогика институты, сугыш вакытында бик яхшы биналарын Суворов училищесына калдырып, үзе иске-москы, ярым-йорты биналарда тупланергә мәҗбүр булган. Вуз шәһәрнең төрле җирләрендәге унлап иске бинага урнашкан иде. Ярый әле, элеккеге ректор Рәис Кыям улы Беляевның турыдан-туры ярдәме белән ике тулай торак төзелеп калган. Кыскасы, мин ректорлык эшенә керешкәндә, биналарны ремонтлау

Рүзәл Габдуллаҗан улы Юсупов – академик, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе. 75 китап, 700ләп мәкалә авторы. Аның тарафыннан 400гә якын фәнни хезмәт, шул исәптән 13 монография язылган.

Гаиләнең түгәрәк чагы.

һәм тәртиптә тоту проблемасы бик зур иде. Без аларны эшләп чыктык.

Студентларның тәртибенә игътибар бермә-бер артты. «Сез булачак укытучылар, димәк, әдәпле, белемле, күркәм булырга тиешсез», – дип, гел җыелышлар уздырдык. Студентларның тулай торакларына барып, кирәк дип тапканда хәтта бәдрәфләренә кадәр кереп йөреп, аларның яшәү шартларын якыннан белеп тордым.

Миңа кадәр Казан педагогика институтында традицион рәвештә инглиз, немец, француз телләре белгечләре әзерләнеп килгән. Ә без, шулар белән бергә, илебезнең көнчыгыш дәүләтләре белән бәйләнеше киңәя баруны исәпкә алып, гарәп, төрек, фарсы, һинд, кытай, япон телен дә белә торган белгечләр әзерли башладык. Соңрак Халыкара бүлек оештырдык, күп кенә илләрнең университетлары белән нәтиҗәле элемтәләр урнаштырдык.

Саный китсәк, эшләр бик күп булды: берничә белгечлек буенча докторантура ачтык. Фәнни дәрәҗәле укытучыларга ия булу өчен, вузның үзендә докторлык һәм кандидатлык диссертация советлары булу кирәк. Шуны истә тотып, өч докторлык советы ачтык. Тагын дистәләгән, хәтта йөзләгән башка эшләрне мисалга китерергә була. Иң аянычлысы – шундый педагогика университеты бүген юк ителде! Россиядә Казан кебек зур шәһәрләрдә генә түгел, кечерәк калаларда да педагогика уку йортлары булуы очраклы хәл түгел. Иң гаҗәбе: Казаннан кала башка бер генә шәһәрдә дә мөгаллимнәр әзерли торган югары уку йорты юк ителмәде. Ә бездә шундый тарихи, дәрәҗәле вуз бетерелде.

– Рүзәл ага, сез гомерегез буе татар телен саклау һәм үстерү өчен тырышасыз. Ана телебезнең бүгенге хәле сезне борчыймы? Күпме хезмәтем юкка чыга дигән күңелсез уйлар килмиме?

«Кызыбыз Диләфрүз белән».

– Борчый гына түгел, бәгырьгә тия. Язган һәр ике мәкаләмнең берсендә тел проблемасын кузгатам. Белем бирүнең дәүләт стандартларыннан милли компонентларны төшереп калдыру, туган тел һәм әдәбиятны мәктәпләрдә 10 нчы сыйныфка кадәр генә, атнасына икешәр, берәр сәгать кенә һәм факультатив рәвештә укыту, милли мәктәпләрдә чыгарылыш имтиханнарын русча тапшыруны мәҗбүри итеп кую үз эшен эшләде. Моңа өстәп эле туган тел һәм милли әдәбият дәреслекләрне бастырудагы авырлыклар... Утыз елда эшләнгән эшләр бер-ике ел эчендә юкка чыкты. Моңа белем үзәгенең җитәкчелеге, шул исәптән хәтта кайбер татар директорлары да «ярдәм итә»: үзләренең эшен җиңеләйтү өчен, татар мәктәпләрендә дә русча укытуга күчә бара. Иң гарьләндергәне – балаларга туган телләрен укытуга татар ата-аналарының каршы килүе турында хәбәрләр көннән-көн ешая. Инде болай да хәтта Татарстанның үзендә яшәүче татарларның яртысыннан күбрәге туган телендә аралашмый. Бу проблема телгә генә түгел, мәдәнияткә, гореф-гадәтләргә, яшәешебезгә яный торган зур куркыныч. Әгәр дә ашыгыч рәвештә хәлиткеч чаралар күрелмәсә, бу милләтебез өчен төзәтә алмаслык бәлаказага әверелергә мөмкин, дип уйлыйм.

– Ә сезнеңчә нинди чаралар булырга тиеш ул, Рүзәл Габдуллаҗанович?

– Беренчедән, телебезнең дәрәҗәсен күтәрергә кирәк. Аны республика җитәкчелеге халык белән бердәм булып эшләргә тиеш. Икенчедән, татар мәгарифен саклау мөһим: татар телен, әдәбиятын укытуны җайга салырга кирәк. Монысы бүгенге көндә иң әһәмиятлесе. Бу мәсьәләдә проблемалар җитәрлек. Белемле кешеләрне җәлеп итеп, татар мәктәпләренең эшен һәм рус мәктәпләрендә татар телен укытуның торышын тикшерү зарур дип саныйм. Моңа барысы да керә: татар телен укыту методикасын, укучыларның туган телләрен өйрәнү дәрәҗәсен, уку әсбаплары белән тәэмин ителешен, мәктәп җитәкчеләренең татар телен укытуга мөнәсәбәтен һәм башка мөһим мәсьәләләрне җентекләп тикшереп, объектив бәя бирелсен иде.

Хәзерге шартларда татар теленең дәрәҗәсен күтәрү өчен иң кирәкле гамәл – милләттәшләребезгә, бигрәк тә ата-аналарга туган телнең әһәмиятен аңлату, идеология эшен алып бару да ул, дип уйлыйм.

– Сез Мирфатыйх Зәкиевнең укучысы. Белгәнебезчә, Мирфатыйх ага соңгы көннәренә кадәр диярлек актив тормыш алып барды. Йөрү, йога белән дә шөгыльләнде. Ул яктан сез дә укытучыгыз кебек активмы?

– Йога гына гомерне озынайта, сәламәтлекне яхшырта аламы икән? Бу мәсьәләдә мин белгеч түгел, бәхәсләшә алмый. Әйе, Мирфатыйх ага күп еллар йога белән шөгыльләнде, тик аның озын гомерле булуы нәселдәнлек, дип уйлыйм.

Үземә килгәндә, таш яуса да, көнгә бер сәгать җәяү йөрим. Утырып эшләгәч, көн уртасында да бер урам әйләнеп кайтам. Җәен бакчада эшләргә яратам, шуның өчен дә җәйне көтеп алам. Лаеш районы Сокуры авылында сигез сутыйдан артык бакчабыз бар. Көзгә кадәр гел шунда мин. Акыл эше дә гел тонуста тота: узган ел алтмыш мәкаләм чыкты. Физик хезмәт белән акыл хезмәте дә кирәк, дип саныйм.

– Рүзәл Габдуллаҗанович, гаиләгез турында да сөйләшсәк иде. Бала югалту фаҗигасен дә кичергәнсез икән... Бу йөрәк ярасы аз булса да төзәлдеме?

– Хатыным Диләрәне гел мактап сөйлим. Мин гел эштә булганлыктан, балалар тәрбияләү күбрәк аның өстендә булды. Күп еллар Северный бистәсендә үзебезнең йорт белән яшәдек. Ә хуҗалыкта эш беркайчан бетми. Бу бер. Икенчедән, кандидатлык, докторлык эшемдә дә Диләрәнең өлеше зур булды. Ул мин язганнарны машинкада басты. Хәзер исә мин язганнарны компьютерда җыя. Әлбәттә, тормыш иткәндә төрле чак була, тик хатыныма карата хөрмәтем бик зур. Мин аңардан тугыз яшькә олырак, шулай булгач, гомер буе яшь хатын белән яшәдем. (Көлә.)

Олы улыбыз Фәнис утыз яшендә бакыйлыкка күчте. Дистә еллар узса да, йөрәк ярасы һаман төзәлми. Бик акыллы, чибәр егет иде. Ир-атның бәхете хатын-кыздан дип юкка әйтмиләр, улыбыз ул яктан бәхетсез булды. Әнә шул бәхетсезлеге аркасында китеп тә барды... Шуңа күрә гаилә корганда нәселгә карарга кирәк. Ата-бабаларыбыз юкка гына шулай эшләмәгән. Хәзер инде күп сулар акты, бернәрсәне дә кире кайтарып булмый. Кайбер көннәрдә йокламыйча улымны уйлап ятам. Олыгайган саен авыррак икән. Вакытында юлына берәр яхшы кыз очраса, бу хәлләр булмас иде, дим...

Аллаһка шөкер, кызыбыз Диләфрүзнең тормышы әйбәт, кияү белән ике ул үстерделәр. Олы оныгыбыз Ислам җәй көннәре Англиягә барып, инглиз телен өйрәнде. Аннары Германиядә Халыкара университетта белем алды, флотлар төзүгә караган белгечлек алды. Хәзер Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә яши, Америка оешмасында эшли. Студент вакытыннан ук шул эшендә. Инде бер татар егете белән үз эшен дә булдырган. Бик сәләтле егет. Икенче оныгыбыз Кәрим дә абыйсы янына Гарәп Әмирлекләренә китте. Инглиз мәктәбендә укый, гарәп телен дә яхшы белә. Исән-сау булсыннар, шулар өчен сөенеп яшибез.



– Академик гел эшләргә тиеш, – ди Рүзәл Юсупов.

– Сез татар матбугаты белән даими танышып баручы кеше. Бүгенге татар матбугатына нәрсә җитми, ничек уйлыйсыз? Кайсы басмаларны аеруча яратып укыйсыз?

– Дүрт-биш газетага язылам. Шуларның берничәсенә үзем дә даими язып торам. Аерым журналлар белән танышып барам. Яшермим, газеталарда хаталар ешрак очрый. Бер газетада кимендә ун-унбиш хата табам. Ни кызганыч, бүген журналистларда төбенә төшеп язу бик юк, өстән-өстән генә. Хәер, мин аның сәбәбен аңлыйм да – хезмәт хаклары аз, алар берничә җирдә эшләргә мәҗбүр. Ләкин телне камил белү – журналистның төп бурычы. Гомумән, гуманитар өлкәгә соңгы елларда булган мөнәсәбәтне күреп йөрәк әрни. Заман технологияләре дип, бу өлкәгә бөтенләй игътибар кимеде. Ә бит гуманитар тармак әдәп-әхлак өчен җавап бирә. Аны берничек тә икенче урынга куярга ярамый!

– Яңа елдан ниләр өмет итәсез? Бүген нинди уй-максатлар белән яшисез?

– Әлбәттә, беренче чиратта саулык, сәламәтлек, иминлек телим. Ә инде тагын бер зур теләк – телебез, мәдәниятебез бетмәсен, татарның рухы сүнмәсен иде. Безнең гасырлардан килгән әдәбиятыбыз, мәдәниятебез, гореф-гадәтләребез бар. Һәркем кулыннан килгәнчә милләтне саклау өчен тырышсын иде. Юкса киләчәк буыннар безне гафу итмәячәк! Т

Фото: Дмитрий Сивков

«Татарстан» журналының махсус проекты

ЗАРЛАНМЫЙЧА ЭШЛӘГӘН БУЫН

Авыр вакытларга, кырыс заманнарга, кайчак түзеп булмаслык тормыш шартларына да карамастан, зарланмый-сукранмый, үз юлларында очраган бөтен кыенлыкны җиңеп алга атлаучы, дөньяны ямьлерәк, уңайлырак итәргә омтылучы кешеләр бар. Алар юллар сала, күперләр төзи. Балаларны, аларның укытучыларын өйрәтә. Арабызда искегә җан өрүче алтын куллы, сирәк һөнәрләргә ия фидакарь затлар да бар.

«Татарстан» үз укучыларын шундый якташларыбыз, аларның могҗизага тиң эшчәнлекләре белән таныштыруны дәвам итә.

Элеккеге тарихларны «Татарстан» журналында укыгыз: 2022 елның 10–12 нче саннары, 2023 елның 1–2, 6 нчы саннары.

15 нче тарих
Василий Яворскийның ничек итеп Мацуев уйнаган рояльне төзәткәне турында



16 нчы тарих
Илья Малышевның ничек итеп иске «Запорожец» машинасын яңартуы турында

15 НЧЕ ТАРИХ

УЕН КОРАЛЛАРЫ ТАБИБЫ

Дмитрий Сивков

Аның дәвалау практикасында очраган иң катлаулы очракмы? Мөгаен, Мацуев репетиция ясаган инструментны... көйләү, юк, асылда, аңа яңадан җан өрүдер... Юк, Василий Яворский, сез уйлаганча, табиб түгел, ул – рояльләрне көйләүче.

– Мацуевны «стейнвейларны* ватучы» дип атыйлар, – дип искә ала Василий. – Ул уйнаганнан соң рояльләрне көйләргә түгел, ремонтларга туры килә. Миңа да ул репетиция ясаган рояльне рәтләргә туры килде. Беләсезме, әлеге музыка инструменты – көйләнгән катлаулы система ул, ә менә Мацуевтан соң ул бөтенләй җимерелә. Кайдадыр нәрсәнедер бөтенләй алыштырырга, кайсын ябыштырырга туры килә. Ул үзе дә дәү гәүдәле, башкару алымы да гаять экспрессив, шуңа күрә инструментка төшкән басым да шактый зур була...

ВОЛЕЙБОЛ БЕЛӘН МУЗЫКА АРСЫНДА

Яворский алты ел Зур концерт залында көйләүче булып эшләгән, шуңа күрә барлык танылган музыкантлар белән дә диярлек очрашкан. Михаил Плетнев, Николай Петров, Денис Мацуев... Аңлашыла ки, «стейнвей» табибының һөнәри әзерлеге дә тиешле дәрәҗәдә. Безнең күз алдына шунда ук олы яшьтәге, какча гәүдәле оста килеп баса. Әмма чынбарлык бөтенләй башка. Казан

Автор фотолары

* *Steinway & Sons (инглизчәдән – «Стэйнвей һәм Уллары») – фортепиано җитештерүче Америка компаниясе. 1853 елда нигез салынган. Steinway & Sons рояльләре XX гасыр уртасыннан чынлыкта музыка индустриясендә стандартка әверелә.*

консерваториясенең фортепиано факультеты бинасында мине озын буйлы, таза гына ир-ат каршы ала. Энергиясе ташып тора, гәүдәсе спортчыны хәтерләтә.

– Кайсы спорт төре белән шөгыльләндегез? – дим мин, тема буенча сораудан читкәрәк китеп.

– Волейбол, тагын әле йөзү... Гомумән, әти-әнием музыкантлар түгел: әни – химик, әти – волейбол буенча тренер, шуңа күрә минем алда бервакыт шундый сайлау да торды: волейбол кырымы, әллә музыка сыйныфымы. Фортепианоны сайладым.

– Әтиең моны ничек кабул итте?

– Ул үзе дә бала чагында музыкаль сәләтен үстерә алмаган, гәрчә һәрвакыт музыкага тартылса да, мөмкинлекләре булмаган. Шуңа каршы килмәде.

Василий үзе сөйли, шул ук вакытта үзе махсус ачкычлар белән Рахманинов портреты астында торган мәһабәт «стейнвей»ның кылларын тарттыра, клавишаларын шакылдата.

КАРАВЫЛЧЫДАН – РОЯЛЬЛӘР КӨЙЛӘҮЧЕГӘ

Василий Яворскийның язмыш әлеге һөнәренә очраклы рәвештә китергән. Консерваториянең беренче курсында ул балалар бакчасына төнге каравылчы булып эшкә урнаша. Беренчедән, студентка акча гел җитми, икенчедән, шөгыльләнергә форсат бар – инструмент гел кул астында. Ләкин пианино нык кына таушалган, уйнар өчен көйләргә кирәк. Үзенә тырышырга – инструментны көйләргә туры килә. Булдырып чыга. Моны күреп, аны башка бакчаларга да чакыра башлыйлар. II курстан Казанның 1 нче музыка мәктәбендә көйләүче булып эшли башлый. Тәҗрибәсе елдан-ел арта бара. Диплом алганда, ул инде консерваториянең клавишалар остаханәсендә эшли, Россия фортепиано осталары ассоциациясе әгъзасы була.

Бүген көйләү өчен берничә минут җитте. Мин мондый тизлеккә гаҗәпләнеп куйдым.

– Бу рояльдә еш уйныйлар, шуңа күрә мин аны көнгә ике тапкыр карыйм – иртән һәм кичен, – дип аңлата оста. – Гомумән, инструментны даими кайгыртып-карап торырга кирәк, күпләр моны аңламый. Машинаны караган кебек: ватылуын теләмисең икән, ешрак автосервиска керәсең. «Стейнвей»га аерым мөнәсәбәт, махсус кайгырту таләп ителә. Бар кеше дә моны белеп бетерми. Кайвакыт адрес буенча барасың, өйләрендә бик яхшы борынгы инструмент тора. Ләкин аңа еллар буе беркем дә якын килмәгән. Ул чакта берни эшләп булмый, борылып чыгып китәсең. Фортепиано инде музыка инструменты түгел, җиһазга әйләнгән.

ОСТАЛАРГА КЫТЛЫК

Санкцияләр инструмент көйләүчеләрнең тормышын да катлауландырган булып чыга. Шул ук «стейнвей»ны Германиядә чыгаралар, шуңа күрә комплектлаучы детальләр белән зур проблемалар бар икән, алар кыйммәт. Мәсәлән, хәзер 1 килограмм кыл (алар шулай авырлыкта сатыла!) 8-9 мең сум тора, санкцияләргә кадәр өч дүрт тапкыр арзанрак булган.

Әмма останы иң борчыганы – әлеге һөнәргә яшьләрнең килмәве, эшне дәвам итүчеләр юк. Казан буенча дистәгә якын белгеч җыеладыр, ди ул. Ә ихтыяҗ зур, әңгәмәдәшем генә дә йөздән артык инструментка хезмәт күрсәтә, шул исәптән фортепианоларга да.

– Бервакыт клавишалар остаханәсенә интернетта инструмент көйләүче хезмәтен тәкъдим итүчеләрне эшкә чакырып карарга уйладык, – ди Василий. – Без үз һөнәребезне яратабыз, ә яңа килүчеләрнең осталык дәрәҗәсе шулкадәр түбән, аның каравы үз-үзләренә ышанганлыклары шулкадәр зур ки, һөнәребез өчен чыннан да куркыныч булып китте. Көйләүче булу өчен, интернеттан бераз укып, берничә эш коралы сатып алу да җитә дип уйлыйлар. Шул рәвешле зур акчалар эшләргә хыялланалар. Без һөнәргә башка юлдан килдек: музыкаль белем плюс остазлардан өйрәнү. Мин әле бөек осталар – Павел Иванович Сигачев белән Николай Николаевич Титовны да күреп калдым. Сәйдәш Мөбарәк улы Рәхимовка аерым рәхмәт, аның белән әлегә кадәр янәшә эшлибез. 1976 ел – ул консерваториягә килгәндә, мин әле туган гына булган...

– Һөнәрегез югалып барамы? Дөньяда көйләү таләп ителмәгән электрон инструментлар саны арта бара бит.

– Ихтыяҗга карагалда, бу хакта сөйләргә иртәрәк. Кадрлар кытлыгы күз алдында. Моның белән нәрсәдер эшләргә кирәк. Ә электрон фортепианоларга килгәндә исә, алар чын инструментны алыштыра алмый. Моны сезгә теләсә кайсы музыкант, хәтта яңа гына эшли башлаганы да әйтәчәк.

РАРИТЕТНЫ КИРЕ КАЙТАРУ

Ульяна Макарчикова

Казан урамнарында мондый иске «бөкре» машинаның пәйда булуы күпләрне гаҗәпләндергәндер. Советлар Союзы заманыннан ук калган «Запорожец» машинасын күрү теләсә кайсы автомобиль йөртүче өчен үткәннәр кайтавазы, күңелдә сагыну катыш сөенеч уята торган хистер...

Раритет саналган «ЗАЗ-965А» хуҗасы Илья Малышев үз хыялына ирешү өчен дистә елга якын вакытын сарыф итә. «Ни өчен «Запорожец»мы? Минем Киров өлкәсе Свеча бистәсендә яшәүче бабамның нәкъ менә шундый машинасы, чын «эш аты» бар иде. Бабам үлгәч, машинаны бик аз бәягә генә сатып җибәрделәр». Ә Илья машинаны онытa алмый. Бабасының авылда төрле техникасы күп була, ләкин иң зәһәр салкыннарда бары тик «Запорожец»ы гына кабына.

«ЗАПОРОЖЕЦ» – ЧЫН ХАЛЫК МАШИНАСЫ

Үсә төшкәч, Илья бабасы истәлеге итеп шундый машина сатып алу турында хыяллана. Берәүләрдә таба, ләкин хуҗасы сатарга теләми. Гаилә ядкаре белән алар ун елдан соң гына аерылышырга ризалашалар.

– Асылда, «Запорожец» Советлар Союзында гади гражданнар сатып ала алырлык тәүге машиналарның берсе булган, – ди Илья Малышев. – «Победа» һәм «Волга» машиналары, «Запорожец»тан аермалы буларак, шактый кыйбат, гади кеше сатып алырлык түгел. Минем аның никадәр дөрес җыелганына исем-акылым китте. Төзелеше энәсеннән-җебенә кадәр җентекләп тасвирланган эксплуатация китабы да бар. Нинди дер сервиска бармыйча гына, үз гаражында ремонтлап чыгарга була: ике-өч ачкычың белән чүкечең генә булсын. «Запорожец» чыннан да халык өчен ясалган ышанычлы автомобиль була.

Яшьрәк чагында Илья иске машинага текә заманча тюнинг ясарга хыялланган булса, инде машинага ия булып алгач, аның зәвыгы үзгәрә. Ул машинаны мөмкин кадәр беренчел халәтендә калдырырга тырыша. Буявы, хром, кыршала төшкән салоны – барысы да үзенеке, 1964 елгы. Ләкин, аңлашыла ки, боларны үз халәтендә саклап калу бик кыен.

Агрегатларны яңадан җыеп чыгу өчен генә дә Илья Малышев өч ел вакытын сарыф итә. Мотор, подвеска, тормозлар – барысы да тузган. Аларны яңарткач, машина йөри башлый.

Автор фотолары

Ләкин мәшәкатьләр моның белән генә бетми. Һәр көз хуҗа машинаны сүтә. Кышын ремонтлый. Язын җыя. Җәй көне йөри. Илья һөнәре буенча инженер-конструктор, авиация тармагында эшли. Шуңа күрә техник яктан белемле, техниканы биш бармагы кебек белә.

– Мин шушы «Запорожец» дип яшим, машина белән эвәрә килү минем өчен ял итүгә тиң, – ди Илья.

ИСЛӘРЕНӘ КАДӘР СССРНЫ ХӘТЕРЛӘТӘ

Башта Илья машинаны кеше күбрәк йөри торган урынга куярга тели – халык раритет автомобиль фонында фотога төшә алсын өчен. Ләкин бервакыт әтисе машинага утырып әйләнеп кайта, сәяхәттән бик канәгать кала. Яшьлегенә кайткандай була.

– Аңлыйсыздыр инде, бу машинаның хәтта исе дә башка, – дип горурланып сөйли Илья. – Кытай исе түгел инде, авылдагы әби өен хәтерләтә. Бик рәхәт халәт, лампалы чакларны искә төшерә дип әйтимме... Машиналардан хәзер андый ис килми. Көн дәвамында салон җилләтелә, ләкин төнлә ис кабат кайта. Мин моны салонда әлегә кадәр совет материаллары калганлыгы белән бәйлим.

Һәм менә бервакыт Илья һәм аның хатыны Татьянаның башына бер идея килә. Мондый раритет – сирәк очрый торган автомобиль экскурсияләр үткәрү өчен идеаль урын дигән фикергә килә алар. Казанның танылган истәлекле урыннары буенча түгел, ә Советлар Союзы чорын хәтерләткән иске урам һәм почмакларны эзли алар. Бәхеткә, мондый урыннар әлегә сакланып калган. Әлеге идея, машина хуҗасы сүзләренә караганда, уңышлы килеп чыга: клиентлар өзелеп тормый.

– Шәһәр тарихына тирәнрәк чумган саен, ул сине шулкадәр күчлерәк били бара, – дип сөйли Малышев. – Экскурсияләр үткәргәндә, мәсәлән, фашистлар «төнге убырлар» дип йөрткән хатын-кыз очучыларның берсе Казанда яшәгәнлеге турында сөйлибез. Һәм Бөек Ватан сугышы чорында немецларның котын алып торган хатын-кызлар авиация полкы тарихы белән таныштырабыз. Шул ук

вакытта алар очкан бомбардировщикларның Казанда җыелуын да аңлатабыз. Ә елга техникумы янындагы постаментта торган «Метеор»-ның совет чорында Татарстанда җитештерелүен дә әйтергә онытмыйбыз. Һәм, әлбәттә, немец самолетына утырып, әсирлектән качкан легендар шәхес – Михаил Девятаевның тәүге «Метеор»ларның берсендә капитан булып эшләгәнлеге турында сөйлибез. Һәм менә шулай, әлеге тарихлар бер-берсе белән бәйләнеп, бик матур экскурсия килеп чыга.

ЯҢА ТАБЫШ

Автомобиль хуҗасы сүзләренчә, юл хәрәкәтендә катнашучылар аның иске машинасына хәерхаһлы мөнәсәбәттә. Шунысы да кызык: машина дәрәҗәлерәк булган саен, «бабайга» карата хөрмәт тә зуррак – тизлекләрен киметәләр, үткәреп җибәрәләр, сигнал биреп сәламлиләр.

Ә ретро-машина белән идарә итү җиңел түгел, монда аерым осталык таләп ителә. Һәр маневрны алдан планлаштырырга туры килә, шоферның игътибары тулысынча юлга юнәлтелгән, телефонга карау юк. Тизлекне арттыру да, киметү дә катлаулырак. Гел башыңны боргалап утырырга кирәк, чөнки «Запорожец»ның ян-ягында көзгеләре юк.

Сүз уңаеннан, күптән түгел Илья үзенең тагын бер хыялын тормышка ашыра – сирәк модификацияле «Победа» машинасын сатып ала. Хәзер ул тагын гаражда ретро-автомобилен камилләштереп бетерү белән мәшгуль.

– Мин чыннан да иске машинаны яңартканда ял итәм, – дип тәмамлый сүзен Илья Малышев. – Ретро-машина – узган гасыр уртасында аны проектлаган кешеләрнең чагылышы. Ул хәзер генә барлык процессларны гадиләштерүче технологияләр бар, ә ул вакытта барысы да сынап караулар һәм ялгышлар аша туган. Хәзер эретмәләр дә, буяулар да башка. Миңа күп нәрсәгә өйрәнергә туры килә. Ләкин бу үзем сайлаган язмыш.

КУРЧАКЛАР ДӨНЬЯСЫ ТЫЛСЫМЧЫСЫ

Евгения Чеснокова

Бервакыт авиация институты студенты Мария Златоустова «Һиндстан тарихы – курчакларда» күргәзмәсен карый. Анда һинд тарихының Махабхаратадан алып Индира Гандига кадәр бөтен сюжетлары һәм персонажлары була. «Миңа яшен суккандай булды, – дип искә ала ул. – Абсолют тетрәнү! Менә бит ничек тә була ала икән!»

Шул рәвешле, аның «курчаклы» язмышына шәрык хатын-кызы шактый зур йогынты ясый...

...Менә алар, аның шәрык чибәрләре, Казанның Идел буе районы Мәктәптән тыш эшләр үзәгендәге кечкенә генә кабинет киштәләрендә утыра. Ишегенә «Милли курчаклар музее» дип язылган. Хыялый Сөембикә – әле ханбикә түгел, Нугай бәгенең үсмер кызы гына: тезендә – китап, янәшәсендә – саз, чәйле чынаяк куелган бәләкәй өстәл... Болар барысы да кулдан ясалган, материаллары төрле – фанердан алып ефәккә кадәр. Полимер балчыктан әвәләнгән йөзенә бик нечкә кара каләм белән бизәкләр төшерелгән, күзләре хыялый елмая.

Янәшәдәге курчаклар – өч баласы белән Нурсолтан ханбикә. Әлеге кырыс карашлы, мәһабәт ханым Казан һәм Кырым ханнарының хатыны һәм бик зирәк хатын-кыз булган.

– Аның турында Сөембикәгә караганда азрак беләләр, шунысы кызганыч та. Ул ханбикә булганда, бер генә сугыш та булмаган! – дип сөйли миңа Мария Златоустова.

Ул курчакларын беркайчан да уйланмыйча гына ясамый. Тарихсыз курчакның беркемгә дә кирәге юк, дип саный. Һәр эше артында – тулы бер сюжет. Мария Сергеевна әйтүенчә, тарих мәктәптә аның иң яраткан фәне булган.

– Тарихтан да кызыклырак нәрсә була аламыни?! – дип соклануын белдерә ул. – Үзегездән алданрак килгән буыннар белән бәйләнешегезне сизмичә, сез үзегезне аңлый алмаячаксыз. Сезнең арада – иксез-чиксез хәтер җебе. Син үзеңне беркайчан да ялгыз итеп тоймыйсың.

УКАЛАП ЧИГЕЛГӘН...

Музейдагы Казан ханбикәләре каршында рус милли киемендәге курчаклар урнашкан. Болары инде Златоустованың шәкертләре эше. Курчакларда – алтын ука белән чигелгән ефәк костюмнар, төрле ялтыравык ташлар белән бизәлгән баш киемнәре... Йөзләре шулай ук нечкә кылкаләм белән ясалган.

– Бу курчакларны минем шәкерт кызларым ел буена ясады, – дип сөйли Мария Сергеевна. – Алар Явыз Иван чорындагы чын рус костюмнары кигән. Аннары чуалышлар чоры башланган, аннан соң инде Петр патша бөтен нәрсәне, шул исәптән киемнәрне дә, европалаштырган...

Фото: Алсу Шакирова

Янәшәдә – үзендә яшәүче бөтен хайваннары белән теремкәй. Бераз арырак – киемнәре ясалма куннән тегелгән борынгы Казан яугирләре... Болар барысы да Мәктәптән тыш эшләр үзәгенә йөрүчеләр эше. Мария Сергеевна биредә инде күп еллар буе «Жар-птица» студиясен җитәкли. Остазның детальләрдәге тарихи төгәллеккә омтылуы шәкертләренә дә күчә. Һәм алар чын сәнгать җәүһәрләре тудыра – әлеге әсәрләр шәһәрдә үткәрелгән һәм халыкара конкурс-фестивальләрдә төп премияләргә лаек була.

ИНЖЕНЕРЛАР ҺӘМ ПЕДАГОГЛАР ТУРЫНДА

– Мин аны Бәбрик дип атармын! – ди миңа, горурланып, җиде яшьлек Макар.

Аның яңа дусты Бәбрик – йомшак уенчык, кечкенә аю баласы ул, Макар аны «Жар-птица» студиясендә сәгать ярым эчендә гомерендә беренче тапкыр үз кулы белән ясаган. Бәбрик идеаль түгел, әмма Макарның түбәсе күккә тигән. Мария Сергеевна аю баласының әле җилемгә яхшылап ябышып та бетмәгән фетр аягын бераз төзәтеп куя һәм уенчыкның муенына кызыл тасмадан бант бәйли.

Макарның яшьтәшләре булган тагын дистәгә якын бала, үз аюларының аякларын һәм колакларын ябыштырып бетергәч, бер-бер артлы сыйныф бүлмәсеннән чыга – һәммәсенең дә йөзендә үзе ясаган беренче уенчык белән горурлану хисе балкый.

– Ә иң кызыгы менә шулдыр – мин балачагымда курчаклар белән бөтенләй уйнамаганмын! – дип елмая Мария Златоустова. Периметры буенча ясалган киштәләре һәм тәрәзә төпләре (тагын әле Мәктәптән тыш эшләр үзәгенең коридорлары һәм башка бүлмәләре) аның гаҗәеп матур курчаклары белән тулган кабинетта әлеге сүзләрне ишетү, әлбәттә инде, бераз сәеррәк тоела.

– Мине балалар бакчасына йөртмәделәр, шунлыктан еш кына өйдә ялгыз кала идем, – дип, хатирәләрен барлауны дәвам итә Мария Сергеевна. – Шул вакытта рәсем ясый башладым да инде. Нәрсә дә булса әмәлләргә бик ярата идем. Бервакыт уенчыклар бүлмәсен бизәү өчен идәндәге чын келәмнең бер кисәген кисеп алдым. Әнидән курыктым билгеле, тик ул башта күрмәде, аннары инде орышырга соң иде.

Аннары ул сәнгать мәктәбен тәмамлый. Аннан соң... КАИга укырга керә. Аның эшләрен карагач, Казан сәнгать училищесында: «Син үзең инде барысын да беләсең, сиңа бездә укырга кирәкми дә», – диләр. Мария үзе укырга теләгән Мухина исемендәге Ленинград сәнгать-сәнәгать училищесына исә әнисе җибәрми, сәламәтлеге мактанырлык булмаган кызына дымлы һава торышы килешмәс, дип курка. Шәһәрдәге югары уку йортларының берсен сайларга туры килә. Математика бик җиңел бирелгәнгә, КАИны сайлый. Рәссам – гел акчасызлык, эшсезлек ул, бер дә җитди һөнәр түгел, ә менә инженер шәп эш булачак, дип саный әнисе.

Әмма кайвакыт әниләр дә ялгыша шул. Болгавыр 90 нчы елларда Мария әнисенең сүзләрен еш искә төшерә, ачуланып түгел, әлбәттә. Ул чакта инженерларның кирәге калмый. Инде дүрт баласы булган хатынны беркем дә эшкә алырга теләми. Һәм шулчакта сәнгатькә сәләте аны педагогикага алып килә. Киләчәктә Татарстанның атказанган укытучысы исеменә лаек булачак Мария сәнгатьтәге эшчәнлеген балалар бакчасында түгәрәк алып барудан башлый. Ул күп еллардан бирле Мәктәптән тыш эшләр үзәгендә эшли, һәм бүген искиткеч педагог алып барган секциягә язылыр өчен ата-аналар чират тора. Мария Сергеевна шәкертләренә һәрвакыт болай дип аңлата: үз кулың белән нәрсә дә булса ясый белү – бик яхшы, син бервакытта да ач калмаячаксың, һәрчак ипи-тозлык кына булса да акча эшләү мөмкинлегең булачак.

КОММЕРЦИЯ ТҮГЕЛ, МӘГЪРИФӘТ

Педагог хезмәтенә күп түләнмәсә дә, Мария Сергеевна бервакытта да курчак сатып акча эшләмәгән. Үз балаңны сатып булмый, дип саный ул. Гәрчә бик йогынтылы кешеләрдән тәкъдимнәр булгаласа да...

Аның өчен башкасы мөһимрәк. «Эшемнең иң мөһим өлеше – мәгърифәт, агарту», – ди педагог Златоустова. Балалар бакчасында эшләгәндә, ул бервакыт чын спектакль куя. «Әгәр мин борынгы Казанда яшәсәм» дигән тамашада рольләрне, әлбәттә инде, аның курчаклары уйный. Шундый тамашаларның берсеннән соң Мария Сергеевна янына еламсырап бер кызчык килә һәм үзенең дә борынгы Казанда яшәргә теләвен әйтә. Мин бу сабыйны бик яхшы аңлыйм. Мария Златоустованың искиткеч курчакларына караганнан соң туган хисне бер генә дәреслек тә тудыра алмый. Әлеге нурлы йөзле матур персонажлар яшәгән дөнья чыннан да гаҗәеп булгандыр кебек тоела. Һәм аның сәләтенең искиткеч тылсымы да нәкъ менә шунда – кешеләргә үзләренең тамырларына якынаю хисе бирүдәдер.

Ә сез, курчак кына, дисез...

ТАТ МЕДИА

Телевизор, вертикаль пылесос, ипи пешерә торган җайланма һәм башка бүләкләр от. Иң зур бүләк – «Шифалы су – Ижминводы» санаториена 2 кешелек юллама!

Бүләкләрне уйнату 2024 елның 8 февралендә узачак.

ЯЗЫЛ

«ТАТМЕДИА» АҖнең бер газета һәм бер журналына языл (акциядә катнашучы басмалар белән tatmedia.ru сайтында танышып була)

ҖИБӘР

«Акция» билгесен куеп, язылу квитанцияләренең копиясен безгә 2024 елның 22 гыйнварына кадәр җибәр (телефон номерыгызны язарга онытмагыз!). Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

ОТ

Телевизор, вертикаль пылесос, ипи пешерә торган җайланма һәм башка бүләкләр от. Иң зур бүләк – «Шифалы су – Ижминводы» санаториена 2 кешелек юллама!

Әлеге чараны оештыручы, кагыйдәләре, бүләкләр саны, уйнату вакыты һәм урыны буенча мәгълүматны tatmedia.ru. сайтында белә аласыз. Акция 2023 елның 16 ноябреннән 2024 елның 20 мартына кадәр уздырыла. Гаризалар 22.01.2024 кадәр кабул ителә. Реклама. Яшь чикләве 16+. Бүләкләр рәсемдәгедән аерылырга мөмкин.

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр /

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Алдакчылар тозагына **ничек** эләкмәскә

Хәсән Туфан **кемне** «аяклары бәйле Прометей» дип атаган

Китап киштәсендә **нинди** «кышкы» китаплар бар

Якын арада **нинди** спектакальләр карарга була

АЛЛО, БҮЛЕШЕР НӘРСӘГЕЗ БАРМЫ?

ЯҢА ОСТАП БЕНДЕРЛАРГА НИЧЕК КАРШЫ ТОРЫРГА?

Евгения Чеснокова

«Әни, зинһар, борчыла күрмә, мин хастаханәдә», – Ирина Петровнаның телефонын алганнан соң ишеткән беренче сүзе шул була. Калтыранган хатын-кыз тавышы Мәскәүдә яшәүче кызыныкына да охшаган кебек…

АМЕРИКАДАН КИЛГӘН СӘЛАМ

Пенсионер ханым, бәхеткә, шалтыратучының номеры +1 префиксыннан башланганын күреп өлгерә. Ирина Петровнаның ерак туганнары Канадада яши, шуңа күрә ул нәкъ менә шундый кодның Америка һәм Канада номерларында булуын белә. Телефон алдакчылары турында безнең героиня, әлбәттә, күп ишеткән була һәм «кызы»ның аннан дару һәм кыйммәтле анализлар өчен акча сорагането көтеп тормый.

«Нәрсә, әллә син Америкадагы хастаханәдәме?» – дип төрттерә ул «яңа туганына».

Шалтыратучы, күрәсең, сөйләшүнең мондый борылыш алуыннан югалыбрак кала һәм «әйе» дип җавап бирә.

«Сезнең өчен бик шат, сез ышанычлы кулларда!» – дип җавап бирә Ирина Петровна һәм,

Фото: ru.freepik.com

үзеннән канәгать калып, телефонын басып куя. Бу очракта бары тик Россия пенсионерларының телефон мошенникларына каршы тора алырлыклары бар дияргә генә кала!

САРАНЛАНМА, АЛ...

Әлеге дә баягы Остап Бендер халыктан акча суыруның «чагыштырмача гадел» дүрт йөз ысулын белгән (яисә белəм дип әйткән).

Хәзерге мошенниклар куллана торган шундый ысулларның саны күпмедер – әйтүе кыен, әмма шунысын ныклы ышаныч белән әйтергә мөмкин: һәр көнне алар кешеләрдән ялган юллар белән акча алуның яңадан-яңа хәйләләрен уйлап табып торалар. Шуңа күрә сәер шалтыратуларга уяулык күрсәтү бик кирәк! Ирина Петровна, әлбәттә, молодец, әмма һәркем дә мондый «гадәттән тыш» хәлләрдә салкын акыл белән эш итәргә сәләтле түгел. Полиция хезмәткәрләре бигрәк тә өлкән кешеләрне гел кисәтеп тора: әгәр, имеш, якын кешегез үзе белән бер-бер хәл килеп чыгу турында хәбәр итеп шалтырата икән, телефоныгызны куегыз да үзегез аңа шалтыратып карагыз. Әгәр ул телефонын алмый икән, әлеге якыныгызның хезмәттәшләренә, дусларына шалтыратып карагыз. Һәм сәер шалтырату турында полициягә хәбәр итегез.

Дөрес, кайчак намуслы гражданнар үзләре дә аларны алдарга теләгәннәр хисабына файда алырга мөмкин. Монда иң мөһиме – чаманы югалтмау, вакытында туктап калу...

...«Wildberrieska эшкә алу менеджерыннан» смс алгач, Татьяна, тәҗрибәле һәм юридик яктан белемле ханым, әлбәттә, аңа вәгъдә ителгән җиңел хезмәт хакына (диваннан да тормыйча диярлек көненә 1000 нән алып 25 000 сумга кадәр) ышанмый. Әмма аңа кызык булып китә: ә аны ничек алдаларга җыеналар икән? Ул смска җавап бирә һәм мессенджерда тәкъдим ителгән чатка кушыла. Эш чыннан да авыр түгел: күтәрәсе-төшерәсе юк, бары тик маркетплейста теге яисә бу товарга лайклар куеп кына утырасы. Ирина беренче биремне үти һәм аның картасына 300 сум күчә. Икенче лайклар өчен дә акча ала: бу юлы – бераз күбрәк. Алга таба бирем катлаулана бара: теге яисә бу продуктны сатып алырга кирәк була башлый. Имеш, сатучыга челтәрдә аның товарын сатып алуларын күрсәтергә кирәк, ә тотылган акчаларны ул чатта катнашучыларга кайтарып бирәчәк, әле процентлар белән дә.

Чатта Иринаның «коллега»рыннан килгән сөенечле хәбәрләр артып бара: «Әйе, миңа инде вәгъдә ителгән процентлар кушылган акчалар кире кайтты! Әйе, мине бай дияргә дә була!» – шундыйрак эчтәлекле хәбәрләр пәйда булып тора. Инде Иринаның сабыры төкәнә: ул монда барысының да алдакчы булулары һәм үзенең бернәрсә дә сатып алырга җыенмавы турында яза. Шуннан соң аны чаттан чыгарып аталар. Ә менә мошенниклардан











күчкән акчалар (дөрес, зур суммалар түгел) картасында кала!

Әмма бөтен кешенең дә эше алай уңай килеп чыкмый. Социаль челтәрләрдә беренче вакытларда чыннан да әз-мәз акча алып, әлеге схемага ышанып, алга таба аны дәвам итеп, төп башына утырып калучыларның тарихлары турында бик күп языла. Ә инде эш эрерәк сатып алуларга (кем өчендер 20 мең сум да – җитди чыгым) барып җиткәч, мошенниклар элемтәләрне кинәт кенә өзә. Шуңа күрә соңгы «сатып алуны» башкаргач, беркатлы «хезмәткәр» акчасын болай гына биреп җибәргән, салынган акчасының кире кайтмаячагын (ниндидер артып кайту турында сүз дә юк) аңлап ала.

Без әлеге хәл турында Wildberries компаниясенең матбугат хезмәтенә хәбәр иттек. Менә аларның рәсми җавабы:

«Бу очракта мошенниклык факты күз алдында. Без беркайчан да үзебезнең сатып алучыларыбызга, WB-чаттан башка, берниндй дә альтернатив элемтә каналлары тәкъдим итмибез. Без клиентларыбызга смс һәм сылтамалар юлламыйбыз. Смс буенча килгән сылтамаларны, шулай ук читтән килгән шикле ресурсларны ачарга тәкъдим итмибез».



АБОНЕНТКА ШАЛТЫРАТЫП БУЛМАСКА ТИЕШ

«Банктан» шалтыратулар турында барыбыз да күп тапкырлар ишеткәнебез бар кебек: банк хезмәткәрләре счет буенча ниндидер аңлашылмаучанлыклар килеп чыгуы турында да аңлатмаячак һәм бигрәк тә сезнең белән мессенджерларда элемтәгә чыкмаячак. Әмма юк-юк дигәндә дә алданган пенсионерлар турында хәбәрләр ишетелгәләп тора. Алар мошенникларга картаның икенче ягындагы яшерен өч санны да әйткән һәм нәтиҗә буларак шактый зур акчалардан (кайчак – миллионнардан) колак каккан.

Бу очракта нәрсә дияргә соң? Халык арасында бер мәзәк тә йөри: «Әгәр сезгә банктан шалтыраталар икән, димәк, шалтыратучылар банктан түгел!» Зинһар, шуны хәтерегезгә киртләп куегыз!

Чагыштырмача күптән түгел генә яңа хәйлә куллана башладылар: кәрәзле телефон компаниясе хезмәткәрләре булып шалтыраталар һәм, сезнең абонент килешүегез бүген-иртәгә өзеләчәк, бөтенләй элемтәсез калмас өчен, тиз арада килешүне яңартырга кирәк, диләр. Әгәр кеше ризалаша икән, аңа смс аша сылтама юллыйлар, шуны ачарга кирәк. Әлбәттә, болай эшләргә ярамый, шул рәвешле мошенниклар сезнең турыдагы мәгълүматны ала. Ә алардан ничек файдаланачаклары бары тик мошенникларның оятсызлыклары һәм фантазияләре дәрәҗәсеннән генә тора.

Кайчак шактый сәер очраклар да була. Әйтик, безнең бер укучыбызга өй телефонына даими рәвештә полициядән дип шалтыраталар һәм әнисен сорыйлар. Янәсе ул ниндидер эш буенча шаһит буларак бара... Нинди эш буенча икәнен «тикшерүче» төгәлләштерми – ул сораган гражданка монда һәм тагын кайдадыр күптән инде яшәмәвен ишеткәч, трубканы ташлый.

Әлбәттә, ни өчен җинаятьчеләрнең шулкадәр искергән базадан файдалануы аңлашылмый, әмма максат ачык: стационар телефоннар бүген нигездә пенсионерларда гына калды, ә өлкән кешене алдау җиңелрәк.

Телефон хуҗасы шалтыратуларны үз мобиль телефонына күчерә һәм аның мәрхүм әнисе белән бик кызыксынган «полицейскийлар»ның Белоруссиядән, Германиядән, Швециядән шалтыратуын ачыклый...

ТЕЛ БИСТӘСЕ – МОШЕННИК ӨЧЕН ТАБЫШ

– Шалтыратуның кайсы номердан килүен ачыклау файдасыз, чөнки номерны алыштыру программалары еш кулланыла, – ди ТР буенча Эчке эшләр министрлыгының Җинаятьчеләрне эзләү идарәсенең мошенниклыкны ачу бү-

леге башлыгы урынбасары подполковник Рафаэль Мусаев. – Тик хәзерге вакытта полиция хезмәткәренең сезгә шәһәр телефоны буенча шалтыратмаячагы көн кебек ачык. Кирәк булганда, килләр, чакыру кәгазе тапшыралар яисә кесә телефонына шалтыраталар. Төп кагыйдә шул: әгәр дә ниндидер сәер сораулар бирә башлыйлар икән, сөйләшүне туктатырга кирәк.

Рафаэль Мусаев сүзләренә караганда, мәгълүмати технологияләр (телефон гына түгел, интернет та) куллану белән бәйле җинаятьләр саны 2017 елдан бирле сизелерлек арта бара. Халыктан акча «суыру»ның яңа ысуллары пәйда була. 2023 елның 11 аенда шундый 16360 җинаять теркәлгән.

– Тикшерелә торган җинаятьләр санына килгәндә, аларның саны шактый күп, – дип сөйли подполковник Мусаев. – Әгәр җинаятьләрне ачу саннары алай зур түгел кебек тоела икән, бу телефон һәм интернет мошенниклыгы белән бәйле эшләрнең чыннан да бик күп булуы белән аңлатыла. Шулай да Идел буе федераль округы төбәкләре арасында Татарстан алдакчыларны ачыклау саны буенча беренче урыннарда – 1700 дән артык кеше, һәм бу узган ел күрсәткечләреннән югарырак. Без мондый җинаятьләрне ничек ачыкларга кирәген беләбез, монда, көнкүреш җинаятьләреннән аермалы буларак, мошенник һәрвакыт ниндидер эз калдыра.

Рафаэль Мусаев күп кенә телефон мошенниклары – Россия колония һәм төрмәләрендә утыручылар дигән мифны юкка чыгарды.

– Татарстанда без төрмәдә утыручы явыз ниятле кешеләрне җиңдек, – дип сөйли ул. – Без Федераль җәзаларны үтәтү хезмәте белән яхшы хезмәттәшлек урнаштырдык, шуңа күрә соңгы өч елда төзәтү учреждениеләрендә мондый җинаятьләр кылынмый. Ә менә мондый шалтыратулар еш кына Украина территориясеннән башкарыла дигән киң таралган фикер күп яктан аклана. Кызганычка, мошенниклык схемасын оештыручыларны һәрвакытта да тота алмавыбызның сәбәбе дә шунда. Иң яхшы дигәндә, без аларның Россия территориясендәге курьерларын эләктерү белән чикләнергә мәҗбүрбез. Кайвакыт алданган гражданнарның акчасын алырга таксистлар җибәрелә, алар үзләренең җинаять схемасында катнашуларын аңламыйлар да...

Явыз ниятле җинаятьче намуслы гражданнарны сан белән (телефон шалтыратулары, яңа алдау схемалары) алырга тырышканда, аларга сыйфат белән җавап бирергә кирәк. Һәм полиция хезмәткәрләренең төп киңәшен истә тоту зарур: мәгълүмат технологияләре өлкәсендә эшләүче мошенниклар белән көрәшүнең иң дөрес ысулы – алар белән аралашмау! Әгәр сезгә полициядән, банктан яки зыян күргән туганыгыз исеменнән шалтыраталар икән (ә ниндидер шикләр булса, турыдан-туры банкка, туганыңа яки полициягә шалтыратырга) сөйләшүне өзәргә; смс аша җибәрелгән берниндн сылтаманы да ачмаска; социаль челтәр һәм мессенджерлар аша матди ярдәм сорауларга ышанмаска (һәрхәлдә, ярдәм сораучы белән шәхсән сөйләшкәнче, ул сезгә язганмы-юкмы икәнен тикшергәнче). Яңа «остап»ларның нинди хәйләләр кулланганын белү өчен вакыт-вакыт интернетны күзәтү дә начар булмас, иң мөһиме – дилбегәне алар кулына бирмәскә.



ҺӘМ ПОЛИЦИЯ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ТӨП КИҢӘШЕН ИСТӘ ТОТУ ЗАРУР: МӘГЪЛҮМАТ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ ӨЛКӘСЕНДӘ ЭШЛӘҮЧЕ МОШЕННИКЛАР БЕЛӘН КӨРӘШҮНЕҢ ИҢ ДӨРЕС ЫСУЛЫ – АЛАР БЕЛӘН АРАЛАШМАУ! ӘГӘР СЕЗГӘ ПОЛИЦИЯДӘН, БАНКТАН ЯКИ ЗЫЯН КҮРГӘН ТУГАНЫГЫЗ ИСЕМЕННӘН ШАЛТЫРАТАЛАР ИКӘН (Ә НИНДИДЕР ШИКЛӘР БУЛСА, ТУРЫДАН-ТУРЫ БАНККА, ТУГАНЫҢА ЯКИ ПОЛИЦИЯГӘ ШАЛТЫРАТЫРГА) СӨЙЛӘШҮНЕ ӨЗӘРГӘ; СМС АША ҖИБӘРЕЛГӘН БЕРНИНДИ СЫЛТАМАНЫ ДА АЧМАСКА; СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘР ҺӘМ МЕССЕНДЖЕРЛАР АША МАТДИ ЯРДӘМ СОРАУЛАРГА ЫШАНМАСКА (ҺӘРХӘЛДӘ, ЯРДӘМ СОРАУЧЫ БЕЛӘН ШӘХСӘН СӨЙЛӘШКӘНЧЕ, УЛ СЕЗГӘ ЯЗГАНМЫ-ЮКМЫ ИКӘНЕН ТИКШЕРГӘНЧЕ). ЯҢА «ОСТАП»ЛАРНЫҢ НИНДИ ХӘЙЛӘЛӘР КУЛЛАНГАНЫН БЕЛҮ ӨЧЕН ВАКЫТ-ВАКЫТ ИНТЕРНЕТНЫ КҮЗӘТҮ ДӘ НАЧАР БУЛМАС, ИҢ МӨҺИМЕ – ДИЛБЕГӘНЕ АЛАР КУЛЫНА БИРМӘСКӘ.

«АЯКЛАРЫ БӘЙЛЕ ПРОМЕТЕЙ»: ФАТИХ ӘМИРХАН

Илдус Заһидуллин

Бөек татар язучысы Фатих Әмирханга иң төгәл бәянне Җамал Вәлиди биргән: «Фатих Әмирхан – татар әдәбияты тарихында гына түгел, бөтен татар иҗтимагый тарихында иң күренекле урын тоткан, вакыты белән кечкенә, ләкин әһәмияте буенча чиксез булган бер буынның үзәгендә торган кеше».

1969 елны язган «Могикан» поэмасында Хәсән Туфан Әмирханны «аяклары бәйле Прометей» дип атый. Кешеләргә ут бүләк иткән мифик герой кебек, ул да милләттәшләренә йөрәк, акыл, рух утын бүләк итә.

ЗЫЯЛЫ НӘСЕЛ ВӘКИЛЕ

Фатих Әмирхан – Казанның зыялы Әмирханнар нәселенең дүртенче буын вәкиле. Ул 1886 елның 1 гыйнварында имам һәм мөдәррис Мөхәммәдзариф Хөсәен улы (1853–1921) гаиләсендә дөньяга килә.

Муллалар династиясенә нигез салган, Бохарада укыган Әмирхан хәзрәт (1771–1828), 1810 елда Иске Таш мәчеттә мулла булгач, Яңа Татар бистәсендә «Әмирхания» мәдрәсәсен оештыра. Аның «Шәрх әл-хикаят» исемле гарәпчә язылган дини хезмәте 1879 елда дөнья күрә.

Әмирхан хәзрәтнең улы, шулай ук берничә ел Бохарада укып кайткан, 14 исемдәге хезмәт (тәрҗемәләр, аңлатмалар, төрле күләмдәге рисаләләр, шигырьләр) язган Иске Таш мәчет имамы Хөсәен үзенең 4 китабын нәшер итә: алар арасында татарча Коръән тәфсире (1890) һәм «Тәварихы Болгария» (1883) бар.

Бабасы һәм этисенең хезмәтләрен нәшер итүгә күп көч куйган Мөхәммәдзариф хәзрәт тә «Әхәдисе Кодсия» («Изге хәдисләр», 1909) дигән, дини мәдрәсәләрнең урта сыйныфлары өчен төзелгән дәреслек авторы буларак билгеле.

Фатихның әнисе Бибирабига һәрберсе өчәр башлангыч, урта һәм урта мәктәптән югарырак сыйныфлары булган «Әмирхания» кызлар мәдрәсәсендә мөдирлек итә. Мәдрәсә хуҗалыкларының ишегалдындагы дүрт бүлмәле иске йортларында урнашкан. Остабикә – башлангыч сыйныфлар өчен язылган «Нәҗат әл-мөкәлләфин» («Җаваплыларга ярдәм», 1910) исемле уку ярдәмлеге авторы.

Шәһәрнең мәшһүр гаиләсендә беренче малай булып туган Фатихны халык данлыклы муллалар дәвамчысы итеп күрә. Ул, әтисе мәктәбендә 3 ел укыгач, белем алуын «Мөхәммәдия»дә дәвам итә. Мәдрәсә мөдире Галимҗан Баруди акыллы, гыйлемле, кеше белән мөлаем аралашучы Фатихны Ураза һәм Корбан бәйрәмнәрендә үз йортында өчәр көн дәвамында оештыра торган чәй мәҗлесләренә кунакларны каршы алу өчен чакыра торган була.

ШӘКЕРТЛӘР ХӘРӘКӘТЕ ЮЛБАШЧЫСЫ

«Тәрҗеман» газетасын, төрек әдәбиятын даими уку һәм революционерлар тәэсирендә яшүсмернең дөньяга карашы тирән үзгәреш кичерә. Фатих өч ел дәвамында яшерен шәкертләр түгәрәгенә җитәкчелек итә. Түгәрәккә йөрүчеләр, һәр атнакич җыелып,

Фотолар автордан алынды

мәктәп-мәдрәсәләрнең җитешмәгән якларын җентекләп тикшерә, татар теле кагыйдәләрен язып, кулъязма газета чыгара, сәяси партияләр эшчәнлеге белән таныша, инкыйлабый эчтәлекле җырлар өйрәнә.

Фатихта кискен үзгәрешләр 1903 елдан башлана дисәк, ялгыш булмас. Ул шул елны мәдрәсәдә яшерен рәвештә Г. Камалның «Бәхетсез егет» драмасын сәхнәләштерүне башлап йөри, шулай ук әдәби кичә дә оештыра. «Мөхәммәдия»нең урта мәктәптән югарырак дәрәҗәсенә җиткәч, 1904 елның июнь-сентябрь айларында энесе Ибраһим белән Самарада русча белемен тирәнәйтеп кайта.

1904–1905 елларда Фатих Казан университеты студенты большевик С. Гассардан рус теле дәресләре ала, экстерн рәвешендә өлгергәнлек аттестаты алырга һәм университетның юридик факультетына укырга керергә тели. Әмма әзерләнеп тә, Фатих латин һәм физика предметларыннан имтиханын тапшыра алмый. Шунысы да мәгълүм: Әмирхан гомере буе рус әдәбиятын, төрек һәм рус телләренә тәрҗемә ителгән Европа матур әдәбиятын яратып укый һәм фәлсәфәсен өйрәнә.

Шушы елларда Коръәнхафиз (Коръәнне яттан белүче) булган Фатих диннән читләшә: ике гаеткә дә йөрми, ураза тотмый, рус һәм Көнбатыш модасыннан калышмыйча, купшы киенә, руслар арасында татар икәнлеген яшереп, социалист булып йөри. Егет гаилә төзүгә тискәре караштa булып, яшьли өйләнү, гаилә һәм бала тәрбияләү мәшәкатьләре яшьлек азатлыгын югалтуга китерә, дип саный.

Чибәр, үткен, зирәк, уен-көлкегә оста, җор телле Фатих мәҗлесләрдә һәрчак үзәктә була. Егет, Казанда укый торган студент һәм курсисткаларны берләштереп, 1905-1906 елның кышында йорт спектакльләре оештыра, үзе баш рольләрне башкара.

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе җирлегендә Фатих Әмирхан рәислегендә «Әл-Ислах» (үзгәртеп кору, реформа мәгънәсендә) комитеты төзелә. Комитет, татарлар арасында революцион фикерләр таратуны максат итеп куеп, монархияне бәреп төшерергә, тулы ирек һәм азатлык алырга, Казандагы һәм Россиядәге татар шәкертләрен иске ысуллы мәдрәсәләргә дөньяви фәннәр кертергә, уку йортларындагы эчке тәртипне үзгәртергә өндәгән, җилем басмада (гектографта) листовкалар нәшер итеп тараткан. «Әл-Ислах» 1905 елның 29 ноябрендә шул ук исемдәге җилем басмада газета чыгара башлый.

Фатих, идеологик әйдәман буларак, «Әл-Ислах» комитетындагы шәһәр татар яшьләре исеменнән Санкт-Петербургта 1906 елның гыйнвар аенда узган «Иттифак әл-Мөслимин»нең II съездында катнаша, анда сыйнфый аерымлыклар мөһим дип, милләт берлегебердәмлеге фикерен алга сөрүче өлкәннәргә каршы сөйли.

1906 елның 10–15 май көннәрендә Казанда 20ләп делегат (Оренбург, Троицк, Самара, Чистай, Бубый, Сатыш, Теләнче-Тамак һ.б.) катнашында гомумроссия татар шәкертләренең съезды үтә. Аның карарларында шәһәрләрдәге мәдрәсәләрне берләштерү, урта һәм югары мәктәпнең мөстәкыйльлеген көчәйтү, программаларындагы аерымлыкны бетерү, аларга дөньяви фәннәр кертү, уку йортлары өстеннән гигиена күзәтүе оештыру, эчке тәртипне саклау өчен шәкертләрдән комиссия булдыру, көнкүрешне рус мәктәпләрендәге кебек итеп кору, шәкертләрнең рәсми газетасын – «Әл-Ислах»ны – гамәлгә кую кебек бурычлар языла. Съездны оештыру, аның кәгазьләрен әзерләү Фатих Әмирхан вазифасында була.

Ярымлегаль укучы яшьләр оешмасын жандармнар эзәрлекли башлый һәм 1906 елның мартында «Әл-Ислах» газетасының меңгә якын нөсхәсен конфискацияли. «Әл-Ислах»ның җилем белән басылган соңгы 16 нчы саны 1907 елның мартында дөнья күрә.

Шәкертләрнең II съезды 1907 елның 1–6 май көннәрендә шулай ук Казанда үтә. Бу чарада Фатих Әмирхан турыдан-туры катнашмый. Хакимиятнең реакцион сәясәте шартларында 1908 елдан комитет эшен туктата. Аның фикерләрен һәм эшен алда сүз булачак «Әл-Ислах» газетасы яңгырата.

МӨХӘРРИР ҺӘМ ЖУРНАЛИСТ

Фатих 1906 елның көзендә Кавказ халыклары каһарманы шәех Шамилнең оныгы – татар сәүдәгәре кияве Заһид Шамил (1868–1923) – чакыруы буенча Мәскәүгә китә һәм «Тәрбият әл-этфаль» («Балалар тәрбиясе») исемле беренче татар балалар журналы редакциясендә җаваплы сәркатип булып эшли башлый. Анда күпсанлы ирекле тәрҗемәләр бастыра. Жур-

Фатих Әмирхан. 1904 ел.

Беренче рәттә утырганнар (сулдан уңга:) Фатих Әмирханның апасы Сәгадәт, аның кызы Разия, әнисе Бибирабига абыстай, басканнар – Ибраһим һәм Фатих. 1906 ел.

нал, 5 саны нәшер ителгәч (1907 елның гыйнвар–март айлары), чыгудан туктый.

Казанга кайткач, 1907 елның 15 августында 21 яшьлек Фатихның аякларын, уң кулын паралич суга. Шушы авырудан аның аякларын йөрми торган булып кала. Сау вакытында көчле оптимист, җилкенчәк Фатих, коляскага беркетелгәч, җитдиләнә, ләкин күңел көрлеген җуймый, беркайчан да авыруыннан зарланмый.

1907–1909 елларда Фатих радикал карашлы яшьләр матбугаты органы саналган, атнага бер тапкыр 16 битлек булып нәшер ителгән «Әл-Ислах» газетасының рухын һәм эчтәлеген билгеләүче мөхәррире була. «Гарәфә кич төшемдә» исемле беренче хикәясе дә шунда дөнья күрә.

Уральскидан Казанга кайткан Габдулла Тукай «Әл-Ислах»та Әмирхан белән дуслашып, кулгакул тотынышып эшли. Әмирхан аның әсәрләр яза башлавына зур йогынты ясый, аның киңәшчесе һәм фикердәшенә әйләнә. Аяксыз калган Фатих Әмирхан янына иң еш килеп йөрүче һәм аралашучы кеше дә Тукай була.

«Әл-Ислах» дин кардәшләренең иҗтимагый тормыштагы артталыгын, искелек тарафдарларын һәм аларга теләктәшләрне кискен тәнкыйтьли. Әйтик, «Әл-Ислах»тан ни көтәргә ярый?» (1908 ел) исемле мәкаләсендә мөхәррир, мәктәп-мәдрәсәләрнең эчен-тышын ачык итеп күрсәтеп, халыкны башлангыч мәктәптә тәрбияләргә, урта һәм шәһәрчә белем бирә торган мәктәпләр ачу турында уйланырга, мөгаллимнәр җитештерер өчен укытучылар әзерли торган дарелмөгаллиминнәр ачарга һәм урта баскыч өчен дәрес китаплары хәзерләргә иҗтиһад итүнең кирәклеге хакында әйтеп, шуннан артыкка куәтебез җитмәүне ачык аңлыйбыз, дип яза. Милли мәктәп алдында торган төп бурычлар дип, Фатих Әмирхан гигиена таләпләренә туры килә торган уку биналары салуны, аларны белемле укытучылар һәм дәреслекләр белән тәэмин итүне атый.

Финанс кыенлыгы сәбәпле «Әл-Ислах» чыгудан туктагач, Фатих Әмирхан, журналистиканы калдырып, әдәби иҗат белән актив шөгыльләнә. Шушы елларда үзенә күренекле татар язучысы дигән ат китергән әсәрләрен иҗат итә. Аларның күпчелеге Әхмәтгәрәй Хәсәни редакторлыгында атнага ике тапкыр чыга торган «Аң» журналында дөнья күрә.

«Әл-Ислах»та эшләгәндә дә, аннан соң да Әмирхан янына һәрчак татар яшьләре килеп йөри, язучы алар белән мөһим мәсьәләләр хакында сөйләшә, акыллы киңәшләр бирә, шул ук вакытта язачак әдәби әсәрләре өчен, сораштырып, материал да туплый торган була.

Язучы 1912–1918 елларда татар китабын нәшер итүче бертуган Кәримовларның сәүдә йорты хисабына либерал юнәлештәге дөньяви рухлы «Кояш» газетасының фикри җитәкчесе, җаваплы сәркатибе һәм төп авторы сыйфатында хезмәт куя. Шулай ук мәкалә һәм әсәрләрен «Йолдыз», «Идел» газеталарында, «Ялт-Йолт» һәм «Аң» журналларында бастыра.

«Кояш»та дөнья күргән мәкаләләрендә милли сәнгать һәм мәдәният үсеше мәсьәләләрен, рус әдәбиятының дөньякүләм әһәмияте, татар морзаларының үз халкына кимсетүле карашлары һ.б. турында яза. Аяксыз калу аның дини карашларына да тәэсир итә: 1905–1907 елларда атеист булса, тәгәрмәчле коляскага калгач, дини тойгыларга бирелә. 1913 елда Харитонов типографиясендә басылган Коръән аятьләрендәге ялгышларны күрсәтеп, Фатих Әмирхан беренчеләрдән булып тирән эчтәлекле мәкалә бастыра.

Мәүлет бәйрәме уңаеннан язган мәкаләсендә (1913) бөтен тәрбия юлыбыз катылыктан, балаларга булган мөнәсәбәтебез орышу һәм хәтта кыйнаудан, аларның шәхесен һәм иреген кысудан гыйбарәт дип, татар гаиләсендәге тәртипләр өчен ачына. Балаларыбыз милләтне сакласын дисәгез, аларга милли тормышны кызыклы ясагыз, дигән фикерне ассызыклап, диннең дә, милләтнең дә матур һәм күңелле якларын күрсәтегез, аларга дин һәм миллиятләре белән бәйле шатлыклар, дини вә милли бәйрәмнәр бирегез дип, укучыларга мөрәҗәгать итә.

1914 елда татар яшьләренең, җеназа мәрасимен тантаналы уздырырга тырышып, вафат булган иптәшләре кабере өстенә чәчәкләрдән венок кую гадәтен тәнкыйтьләп чыга. «Мәгънәсез тәкълид» (тәкълид – ияру) исемле мәкаләсен «Европаларның хәятемез өчен һич кирәге булмаган гадәтләрен тәкълид иткәндә, минемчә, иң әүвәл ул гадәтнең милли рух белән белән тәнасиб итә (яраша) аламы, юкмы икәнен үлчәргә вә шундан соң гына алырга мөмкиндер. Шулай булмаганда, ул тәкълид сукыр вә мәгънәсез булып чыгадыр», дигән сүзләр белән тәмамлый.

ЯЗУЧЫ

Җамал Вәлиди: «Ул татар әдәбиятын заман теләгенә муафыйк бер калыпка, Көнбатыш әдәбияты калыбына салды, аңа җитди бер форма биреп, телне, өслүбне нечкәләп эшкәртүче булды. Фатих Әмирхан – кирәк фикер ягыннан булсын, нәфис әдәбиятыбызны

«Әл-Ислах» редколлегиясе (сулдан уңга): В. Бәхтияров, К. Бәкер, Ф. Әмирхан, И. Әмирхан, Г. Тукай. 1908 ел.



гарәбләштерүдә (Көнчыгышка якынайтуда) иң алдан чыгучы һәм киң юл ачучыдыр», – диюе белән хаклы иде.

Бу яңалыклар аның әсәрләренең эчтәлегендә дә ачык күренә. «Гарәфә кич төшемдә» хикәясендә ул татарларда Гарәфә кич чынбарлыкта һәм хыялда ничек бәйрәм ителә алуны тасвирлый. Бу хикәядә милләттәшләренең кайчан да булса дини бәйрәмнәрне дә Европа мәдәнияте югарылыгында билгеләп үтәчәгенә ышаныч күренә. Әдипнең «Бәйрәмнәр» (1908), «Танымаганлыктан таныштык» (1908), «Хәкарәт саналган мәхәббәт» (1908), «Рәхәт көн» (1910) кебек хикәяләрендә татар җәмгыятендәге аерым күренешләр, типик геройлар күрсәтелә.

Аерым китап булып чыккан «Татар кызы» (1909) татар җәмгыятендә хатын-кызга мөнәсәбәт мәсьәләсенә кагыла. Әмма Фатих Әмирханның татар әдәбиятында беренче прозаик булып танылуына аның «Хәят» (1911) повесте сәбәп була. 16 яше дә тулмаган татар кызының күңелендә рус егете Михаилга мәхәббәт уяну, әмма әти-әнисе карарына буйсынып, күрмәгән-белмәгән татар егетенә кияүгә чыгарга риза булуы тарихы татар һәм рус дөньясын капма-каршы бәяләргә, милләттәшләренең көн итүендә ирексезлекне күрсәтергә мөмкинлек бирә. Аннан соң иҗат ителгән «Кадерле минутлар» (1912) хикәясе шул заман рус яки Европа әдәбиятларындагы мәхәббәт турындагы иң гүзәл әсәрләр дәрәҗәсендә булуы белән сокландыра.

Фатих Әмирханның фантастик язу рәвешенә мөрәҗәгать итүе – «Фәтхулла хәзрәт» (1909) сатирик повестенда кадимче мулланың 1950 елларда терелүен тасвирлавы – татар әдәбиятына моңа кадәр билгеле булмаган көлү алымнарын ача. Үтергеч сатира белән беррәттән, язучының этисеннән күчереп алынган чәй яратучы «Сәмигулла абзый» (1910) яки «Хәзрәт үгетләргә килде» (1912) кебек хикәяләрдә юмор һәм ирония алымнары татар әдәбиятында яратып көлү юнәлешендәге бер төркем әсәрләр язылуга сәбәп була.

Мөхәммәдзариф хәзрәтнең олы улы үзенең әсәрләрендә татар гаиләсендә буыннар арасындагы каршылыкны төгәл, табигый итеп тасвирлаучы язучы буларак танылa. Язучының «Яшьләр» (1909), «Тигезсезләр» (1914) пьесаларында ул үзе кебек гаиләләрдә үскән яшьтәшләренең ата-аналары белән яңалык өчен көрәшүен сәхнәгә менгерә. Аның һәр әсәре татар җәмгыятендәге чынбарлыкны кире кагып, аннан көлеп, ачынып, милләттәшләрен башка – якты, матур киләчәккә өндәп язылa.

СОВЕТ ИЛЕНДӘГЕ ТОРМЫШЫ

Фатих Әмирхан 1917 елның Февраль инкыйлабын зур күтәренкелек белән каршы ала. Берничә атнадан «Иттифак әл-Мөслимин» партиясен яңадан торгызу кирәклеге турында «Кояш»та мәкалә бастыра.

Ул шулай ук Октябрь инкыйлабын да кабул итә. Ләкин тиз арада хакимият белән язучы арасында каршылык туа: аның йортына квартирантлар кертелә, яңа хакимият әсәрләрен бастырмый – аны яшәр өчен акча эшләү мөмкинлегеннән мәхрүм итә. Язучы 1919 елдан – «Кызыл Армия», 1921 елдан «Татарстан» газеталарында эшләп карый, «Марксист» имзасы белән яңа тормышны пропагандалап мәкаләләр яза. Аның «Шәрык кызы», «Кызыл Шәрык», «Безнең юл» журналларында аерым язмалары басыла. 1923–1924 елларда татар театр техникумында татар әдәбияты укыта. Әмма тормышы авыр була. Бары тик 1925 елда Татарстан АССР хөкүмәте карары белән Фатих Әмирханга 40 сум күләмендә персональ пенсия билгеләнә.

Язучы совет чорында да революциягә кадәрге татар әдәбияты традицияләренә тугры кала. Аның «Беренче ашкыну» (1918), «Тәгъзия» (1922) хикәяләре шуны ачык күрсәтә. 1923 елны Мәҗит Гафуриның 20 еллык иҗат юбилее белән котлап җибәргән хатындагы: «Сез соңгы елларда шактый нәрсәләр язарга өлгердегез. (...) Менә мин һаман әле гомеремнең шул дәверенә чыга алмыйм. Бары соңгы елларда үземнең амплуамны табып алдым», – дигән сүзләре дә шул хакта сөйли.

Фатих Әмирхан татар әдәбияты тарихында үз чорының абсурд күренешләрен каләм очына эләктергән бердәнбер татар язучысы булып кала. «Март каһарманы» (1917) хикәясендә ул, революциянең ни икәнен аңламаса да, үзе өчен файдасына төшенеп, митингтан митингка йөреп социалист булып киткән, куштан һәм яраклаша белүче кеше тибын иҗат итә. «Шәфигулла агай» (1924) повесте социализм чорында шәхесне әзер штампка әйләндерә торган яңа әхлак нормаларына шарж булып чыга.

Әти-әнисе вафатыннан соң, Әмирхан 1921–1923 елларда энесе Ибраһим гаиләсендә тәрбияләнә. Ибраһим гаиләсе белән Хиҗаздагы совет илчелегенә гарәп теленнән тәрҗемәче булып эшкә киткәч, аның хатыны Нәфисәнең энисе Газизә Яушева тәрбиясендә кала.

1925 елны Әмирханда туберкулез авыруы табыла. Каты авырудан соң, 1926 елның 9 мартында әдип бакыйлыкка күчә. Бу вакытта аңа бары тик 40 яшь тулган була. Гыйлем һәм фән кешеләре биргән мәшһүр нәселнең затлы улы Фатих Әмирхан үзенең тирән акылы, күпкырлы эшчәнлеге, бай иҗаты белән татар халкы тарихына Прометей булып язылa.

Җирләү мәрасиме комиссиясе озату чараларын тантаналы итеп оештыра, 12 март көнне башта Театр мәйданында дөньяви митинг, аннары Юнысовлар мәйданында җеназа намазы укыла. Җәсәде Татар бистәсе зиратында дәфен кылына.

Фатих Әмирхан. 1908 ел.

КЫШ ТУРЫНДА ЯҢА ӘКИЯТЛӘР

Луиза Янсуар

Кышкы ял – карлы урман-тауларга чаңгы-чанада чыгу, бозлавыкта шуу, рәхәтләнеп Яңа ел аттракционнары, күңел ачу урыннарына йөрү, бергәләп бәйрәм итү вакыты гына түгел, ә ел дәвамында «укырмын» яки «тыңлармын» дип алып куйган китапларга, подкастларга кул җитә торган чак та. «Букмейт» сервисы һәм кушымтасы укучыларына, нәкъ менә шуны күздә тотып, Яңа ел бүләге ясады – «Зимние рассказы Букмейта» сериясендә һәркем күңеленә хуш килгәнен таба ала.

Китаплар зәвыклы дизайн һәм аудиоформат белән сервиска урнаштырып барыла, әгәр сез аларга «хәбәр итү» опциясе дә куйсагыз – сервис һәр яңа пәйда булганын үзе «әйтеп» барачак. Уңайлы һәм рәхәт. «Яндекс.Музыка» платформасына кучеп тә тыңларга мөмкин. Авторлары – Россия китап бизнесы дөньясында үзен шактый танытып өлгергән язучылар.

Ә, әйтергә онытып торам икән – бу китаплар иксез-чиксез Россия киңлекләрендә яшәүче халыклар, аларның менталитеты, милли колорû, кыйммәтләре һәм символлары, көнкүреш дөньясы белән дә өретелгән. Экзотик илләр белән аларның легендаларына сәяхәт итәргә чакырган әсәрләр дә бар. Һәм, әлбәттә инде, Яңа ел, Раштуа яки төрле халыкларда төрлечә атала торган Кыш стихиясе һәм аның традицияләре. Бу ярымәкият, ярымчынбарлык бәяннарын иҗат иткән авторлар үзләре дә – Россиянең төрле почмакларында туып-үскән, аның иң ерак, кеше аягы басмаган урыннарын да белеп-күреп формалашкан кешеләр.

Фото: bookmate.ru, goodfon.ru, livelib.ru

КОЯШКА ӨЧ АДЫМ

Ольга Птицева.
«ТРИ ШАГА ДО СОЛНЦА»

Ольга Птицева 1991 елда Ерак Көнчыгышта, Чукотка автономияле округының Певек шәһәрендә дөньяга килә.

Шагыйрь, язучы, мәдәни подкастлар авторы. Аның Козинаки, Спащенко, Степанова белән берлектә алып барган «Ковен Дур» подкасты зур популярлык казанды.

Ольга Птицева Creative Writing School платформасында укыта, язу серләре белән уртаклаша. «Выйди из шкафа», «Там, где цветет полынь», «Сестры озерных вод», «Брат болотного края» әсәрләре белән билгеле. «Там, где цветет полынь» романы веб-сериалга нигез итеп алынды, аны KION сервисы экранлаштырды.

Язучы турында әдәби тәнкыйтьчеләр «шәһәр мистикасы, актуаль реализм һәм автофикшн жанрында эшли» дип яза.

«Три шага до солнца» хикәяте үзенең эчтәлеге һәм төзелеше белән борынгы бәяннарны хәтерләтә. Мидә ул испан әдәбиятының магик реализм вәкилләре белән дә, Чыңгыз Айтматовның, Фазыл Искәндәрнең риваятьләргә корылган һәм чынбарлык тукымасында аларны өр-яңадан калкыткан әсәрләре белән дә ассоциацияләр уятты. Әмма шул ук вакытта «Кышкы хикәяләр»дә гаҗәеп бер үзенчәлек бар – ничек кенә архетипик, борынгы катламнарга орынмасын, алар үтә дә заманча яңгырый. Нәкъ менә замандашларыбыз язганын шунда ук тоемлап аласың.

Җиде яшьлек Тына-твал тундрада, яраңыда (күчмә тирмәдә) әти-әнисе һәм яңа гына туган энекәше Вытван белән яши. Бирердә поляр төн үзенең озынлыгы белән кешеләрне чак кына акылдан шаштырмый, шуңа да күпчелек ул вакытта калаларга күченеп китә. Тундрада кышлыкка бары иң сабыр, иң түземнәр генә кала. Вытван тугач, Тына-твалның әтисе алмаш барлыкка килүенә куана, ул – ир бала, нәсел дәвамчысы, аңа өметләр зурдан. Ә менә Тына-твал, нинди генә нык бәдәнле һәм булдыклы кызчык булмасын, аның урыны барыбер – икенче. Аны «зур җиргә», шәһәрдәге туганнарга җибәрү турында әтисе белән әнисе инде берничә мәртәбә сүз кузгатканы бар. Бу кыштан да калдырмыйбыз, диләр. Әмма кыш башында, зәмһәрир бер төндә әтисе болан баласы алып кайта. Үзе турында газаплы уйлар өермәсендә яшәгән Тына-твал өчен бу бәләкәч болан бер юанычка әйләнә. Ул аңа «нык бәдәнле» – Омрын дип исем куша.

Ольга Птицева югалып барган дөнья турындагы бәянны үтә гади көнкүреш детальләре аша сурәтли. Поляр төн белән поляр көн алышыну мизгеле - Бөек Пэгытти килеп җиткәч, шаманнарның ритуаллары да бу кырыс җирләрдә исән калу омтылышы белән ни дәрәҗәдә тыгыз бәйләнгән булуын күрсәтә. Бу ритуалларның инде элеккеге көче, тылсымы булмаса да, җирле халык аларга тугрылык сакларга тырыша. Әмма үзләренең ышану чикләре аша атлап чыкканын күңелләре белән сизенә. Һәм менә шаман Рытхэн Тына-твал иркәләп һәм яратып үстергән Омрынны Бөек Бәйрәмнең төп боланы итеп сайлый. Әмма кызга иң мөһимен әйтергә онытканнар икән бит – төп болан, ыру боланы, җиргә кабаттан яз килсен өчен, кап-кайнар канын карга агызып, җанын бирергә тиеш. Аларның ыруын җирдә саклап торган Альтаир йолдызлыгы, үзенең утлы бөркет күзләрен бөркеп, шул канны көтә икән бит... «Омрын үз канын Альтаирга багышлар өчен туган болан, кызым. Куанырга кирәк, куанырга...» – ди әтисе. Әмма Тына-твал куана алмый. Күзеннән яшь ага да ага. Шулчак әтисе аңа катгый итеп, кистереп әйтә: «Ярый әле без сине калага җибәрәбез, син тундра өчен тумагансың, артык җебек», – ди.

Омрын белән хушлашыр мизгелләр якынлашканын сизгән Тына-твалны Пычик карчык көтеп тора. «Карт шаман йолдызларны түгел, пычагым да ишетми. Кирәкми Альтаирга безнең кан, аңа тормыш кирәк, ышаныч, – дип пышылдый ул. – Альтаирга да, безгә дә, тундраны, кояшны яңадан кабызыр, яшәтер өчен, керсез, саф йөрәк кирәк... Әнә шул чакта бу туфракка яңадан яшәү кайтачак...» Һәм менә йөрәге курку белән тулы Тына-твал шашкан карчыкка корбан итеп чәч толымын кисеп тоттыра да, Омрынны бәйдән ычкындырып, тундрага алып чыгып китә. Артында ритуал өчен хәстәрләнгән учак көйри, шаман Рытхэн пычагын кайрый. Ә Тына-твалның колагында Пычик карчыкның пышылдавы яңгырый...

– Алып бар боланыңны, бала, карлар аша алып бар.

– Ә кая алып барыйм соң?

– Альтаир белә, ул сиңа юл күрсәтер.

– Аңа кадәр еракмы икән соң, эбекәй?

– Әйтүләре хак булса, бала, Альтаир юлыннан Кояшка – нибары өч адым.

ИСКӘ ТӨШЕРЕРГӘ КЕМ ЯРДӘМ ИТӘР?

Лия Арден. «ЛОВЕЦ ДУХОВ»

Лия Арден 15 декабрьдә Санкт-Петербургта дөньяга килә. Туган елын искә алырга яратмый. Чын исеме – Влада.

Санкт-Петербург дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетын тәмамлый. Озак еллар Япония мәдәниятен һәм тарихын өйрәнә. 2011 елдан Көньяк Корея белән мавыгып китә, корея телен үзләштерә. 2013 елдан Көньяк Кореяда яши, шуннан YouTube өчен блог алып бара.

Әдәби мәйданга 2019 елда килә. 2020 елда инде кулында 12 кульъязма китап була. Башта аларны туганнарына, якын дусларына гына укый, бераздан, кыюлыгы җитеп, интернетта бастыра. Рәсми дебюты – «Мара и Морок» романы. «Невеста ноября» һәм «Золото в темной ночи» китаплары яшьләр аудиториясендә гаять популяр.

Мөгаен, «Ловец духов» хикәясе әлегә басылып чыккан текстлар арасында иң экзотик нигезлеседер. XX йөз азагы һәм яңа заман готикасы белән фэнтези чикләрендә иҗат итүче күпчелек авторларның мультикультур дөньялар белән эш итүе, төрле мифологик катламнарга орынып каравы – яхшы таныш. Арден аларны кушып уйнаудан канәгатьлек таба булса кирәк.

Хикәя сурәтләү алымнары һәм стилистик эшләнеше ягыннан чын ләззәт бирә – без аның башыннан алып азагына кадәр, әйтерсең, лабиринтларда йөрибез-йөрибез дә кабат беренче борылышына барып чыгабыз.

Сюжет буенча, рухлар аулау белән шөгыльләнүче Ю Дорён ташландык шәһәргә өрәкләрне юкка чыгарыр өчен килә. Әйтүләренә караганда, биредә, кып-кызыл камелияләргә күмелеп утырган ярымҗимерек йортлар арасында, Курчак, төлке-малай һәм төлке койрыклы кыз өрәкләре яши. Алар, имеш, авылдагыларга зыян китерә, димәк, алардан котылырга кирәк. Әмма Ю Дорён, алар белән очрашуга, кешеләр сөйләгән риваятьләрнең ни дәрәҗәдә дөрес булмавын аңлап ала. Бу өчәүнең үзләренең дә еллар буена сузылып килгән үч һәм каргыш корбаннары булуын аңлаганнан соң, ул аларга ярдәм үйлый. Ю Дорён да бирегә очраклы гына килеп эләкмәгән – бу азагы юк ритуалда аның үз роле бар, һәм корбанга иялләшкән Кара көч җиңел генә бирешергә теләми.

«Дорён камелияләр уратып алган шәһәргә таба атлавын дәвам итте. Кинәт сискәнеп катып калды – каршында өчәү тора. Уртада торган озын алсу чәчле кыз – Курчак – шулкадәр агарынган иде, шәмахә күзләрендә – бушлык. Төлке колаклы туташ аңа ара-тирә борчулы караш ташлый, ә малай борчулы туташның итәгенә чатырдатып ябышкан да Дорённан күзен алмый.

– Ю Дорён әфәнде, сез – искиткеч талантлы аучы, өрәк белән кеше кызының улы, әмма мондагы иблисләргә хәтта сезнең дә көчегез җитмәячәк. Зинһар, безнең учакта җылынысгыз да тизрәк китегез, – диде Курчак.

– Авыл кешеләре мине үзләрен Курчактан азат итәр өчен җибәрде.

– Мин авылныкыларга тимим, – диде Сольхи.

– Әйтегез аларга – монда килеп, теләкләр телмәсеннәр. Сүземә колак салсалар, беркемгә дә зыян килмәс.

Дорён аңа ышанды. Йөрәген нидер һаман кысып тора. Ул кулларын учакка сузып җылытты. Кахо аңа ысланган хөрмә китереп тоттыргач, бөтенләй аптырады – әйтерсең, бу малай аның хөрмә ратканын белә».

«Бу хикәяне язарга мине Корея легендалары илһамландырды, – ди Лия Арден. – Кореяда камелия нәкъ менә кышын кып-кызыл булып чәчәк ата. Алар турында риваять бар – имеш, алар үзен корбан итеп һәлак булган эти кеше түккән каннан үсеп чыкканнар. Ә инде кеше белән өрәктән туган баһадирлар, кеше битлеге киеп йөрүче төлкеубырлар, рухларның арадашчылары турында биредә гомумән бик күп ышанулар яши...»

Корея дорамалары, аеруча «История девятихвостого лиса», яшьләр арасында гаять популяр, ә Азия риваятьләре белән аларга нигезләнгән тарихлар – үзе бер культ. Кеше рәвешен алып, таулардан төшкән һәм урманнардан чыккан рухларның һәрберсенең үз миссиясе бар – берәүләре игелекккә хезмәт итә, икенчеләре – явызлыкка. Әмма бу көчләрнең бәрелеше һәрчак дөньядагы гармонияне кайтару өчен кирәк.

Рус телендә яңгыраган әлеге экзотик тарих, беренче карашка, ят та, сәер дә кебек тоела. Әмма аннары кабул ителә, архетиплар белән символлар дөньясының мәҗүси мифлар, без белгән борынгы тарихлар белән параллель икәнен аңлыйсың. Чынлап та, көннәрдән бер көнне безне онытырга мәҗбүр итсәләр? Искә төшерергә кем ярдәм итәр?

Һәм көннәрдән бер көнне алар барысы да алсу чәчәк таҗларына күмелгән күркәм бакчада уяна. Үле шәһәрнең ихлас яратудан һәм иркле корбаннан соң яңадан терелгән, яшәргә көч алган көне була ул.

ЯҢА ЕЛНЫ ЯМЬЛЕ ИТИМ, ДИСӘҢ...

Евгения Некрасова. «САЙГАЧИНСК ЗИМОЙ»

Евгения Некрасова 1985 елның 2 апрелендә Әстерхан төбәгендә туа. Балачагы, үсмер еллары Мәскәү янында һәм Подольск районында уза. Мәктәпне тәмамлагач, Мәскәү агентлыкларында копирайтер булып эшли. 2016 елда Мәскәү Яңа кино мәктәбенең сценарий факультетын бетерә.

2011 елда басылып чыккан «Несчастливая Москва» проза җыентыгы «Лицей» премиясенә лаек була. «Калечина-Малечина» романы (2018 ел) Елена Шубина редакциясендә дөнья күрә, хәзерге вакытта аның буенча спектакльләр бар.

Аның турында еш кына «яңа тел тудыручы», «заманча телне фольклор белән яңартучы» дияргә яраталар. Үзе ул моны бик гадәти итеп аңлата: «Фольклор – борынгылык, диючеләр ялгыша, һәр дәвернең үз фольклоры бар».

Өченче кышкы бәянны Евгения Некрасова гаҗәеп иронияле иткән – бу кышларын кар бөтенләй яумый торган Сайгачинск шәһәре һәм анда яшәүче Сайга турындагы тарих. Аңлашыла инде, кар яумагач, Яңа елны каршы алуның да бернинди мәгънәсе калмый. Җитмәсә, Сайгачинскида чыршы урынына дүңгәләк бизиләр, өстәлгә әллә ниткән сәер ризыклар чыгаралар. Менә Яңа елга бер көн кала, Сайга моңсуланып кына уяна да юынырга керә. Ул арада дусты Эт килеп җитә. Сайганың әнисе аларга дүңгәләк алырга онытмаска кушып, ашыгып, Җыр йортына китеп бара. Ул хор җитәкчесе булып эшли, ә Яңа ел алдыннан, билгеле инде, эш җитәрлек.

«Яңа елны Сайгачинскида элек бәйрәм итмәгәннәр. Әле Сайганың карт әбисе аны бөтенләй өнәмәгән, ә менә әбисе инде бәйрәм иткән. Ул яман бәйрәм дип исәпләнгән, чөнки борын-борын заманда вәхшиләр сайгак итен нәкъ менә Яңа елда ашаган. Әмма ул заманнар артта калган, сайгаклар Яңа елны бәйрәм итә башлаган һәм хәтта «сай-баба эчәкләре» дигән ризык та уйлап тапкан. Камырдан ясалган озын көпшәне ашап, сайгаклар вәхшиләр корбаны булган борынгы бабаларын искә ала, имештер, алда килә торган елга көч туплый».

Сайга белән Эт дүңгәләк эзләп барган җирдән көтмәгәндә мажараларга тап була. Ике дус алдына оча торган тәлинкә килеп төшә. «Бу инде бер ай эчендә икенчесе», – дип сукрана Эт. Тәлинкәдә иносайгачанин утыра булып чыга.

Сайгачинскида яшәүчеләр бу килә-китә йөри торган сәер җан ияләрен әллә ни өнәп бетермәсә дә, дошманлык күрсәтмиләр. Беренчедән, тегеләрнең Сайгачинскины яулап алырга килмәүләре ачыклана, икенчедән, алар каланың болай да такыррак бюджетына, туристлар буларак, шактый гына файда китереп тора. Өченчедән, Сайгачинск халкы алардан кызык таба. Монда килеп, сайгачаннарның җыруларын, фольклорын, уеннарын өйрәнгәннән соң, тегеләрнең никтер күзләре яшьләнә, күңелләре тула. Бу хакта, әлбәттә, Сайгачинскида төрле фаразлар яши. Берәүләр фикеренчә, әлеге сәер җан ияләре әлеге дә баягы «вәхшиләр», дөресрәге, аларның оланнары, югалткан Ватаннарын сагынып, кан тартуын җиңә алмыйча елый. Икенчеләр карашынча, алар элек сайгакларны ашауларын искә төшереп, оялудан һәм хурлыктан елый. Һәм менә тәлинкә төшеп, иносайгачанин белән күзгә-күз калган ике бәләкәй дус аптырап калмый, далага утырганда, һәлакәткә очрап, кулын имгәткән килмешәкне Дәвалау йортына алып китә.

Бу турыда ишеткән Сайгачинск халкы килмешәкләргә ярдәм итәргә тырыша: шаманнан кулын тикшертәләр, җәһәт кенә гипслап та куялар. Шуннан соң инде өч дус кабат мажараларын дәвам итәргә чыгып китә.

«Сайганың әнисе кухняда утны кабызды. Тәрәзәгә күз салса, иң кызыгы урамда иде. Аларның боз белән каткан каналы меңәрләгән ут белән балкып яна. Күршеләр дә, гирляндалар алып чыгып, яр буйлап әлгән. Кемнәрдер инде кардан чистартылган канал бозында рәхәтләнеп шуа: этләр – тимераякта, сайгаклар – үз тоякларында, ә еланнар – бәләкәй чаналарда. Гел йокымсырап яткан каналга җан кергән – ул шаулап-гөрләп тора, җемелдәвек утлар нурына күмелеп утыра.

Әниләре шулай ук арткы тәпиләрендә канал буйлап тимераякта шуган иносайгачанинны ике яктан җитәкләгән Сайга белән Этне күреп алды. Чит планета вәкиленең муенында Сайганың шарфы җилферди, ә алгы тәпиендә – гипс. Бик каты гаҗәпләнсә дә, әниләре дәшмәде».

Әнә шулай итеп Сайгачинск шәһәре борынгыдан калган яраларын оныта, җәйләрен төзәтә, өнәп бетерелмәгән Яңа елга яңа мәгънә өстәлә. Әлбәттә инде, бәләкәч иносайгачанинны да этиәниләре һәм токымдашлары биредә ташлап калдырмый, алырга дип килә...

...Әмма моңа карап Бәйрәмнең яме югалмый.

Гомәр Даутов – язучы, тәнкыйтьче, мөгаллим. Казан дәүләт университетының Татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультетын тәмамлаган. КФУның Алабуга институтында татар филологиясе кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты.

Бик күп фәнни һәм публицистик мәкаләләр авторы. Әсәрләре «Мәйдан», «Казан утлары» журналларында, «Мәдәни җомга», «Шәһри Чаллы» һ.б. газеталарда басылган.

Гомәр Даутов

ТОРМЫШ ЯМЕ

(әсәрдән өзек)

1943 елда Иванның энесе туды. Бу вакытта әтисе өч ел сугышта иде инде. Хәбәр итүчеләр булгандыр, шуннан соң Луканың хатлары килми башлады.

Бу баланың кемнән икәне, сугышның беренче айларында ук сул кулының өч бармагын өздереп кайтканнан соң колхоз рәисе итеп билгеләнгән Степанның Ольга янына йөрүе беркемгә дә сер түгел иде. Исереп алгач (ә ул көнаралаш диярлек исерек була), авылдагы бөтен карт-корыны, хатын-кызны куркытып бетергән Степан, сүгенә-сүгенә, Иваннарның ишеген шакый. Ольга йөгереп барып ишекне ача, аннан соң авыл хуҗасы, кыстырып килгән йә икмәген, йә капчык төбенә салынган онын мич буендагы лавкага ыргытып, чаршау белән генә бүлеп куелган мич алдына кереп китә. Кайчакта чаршау ябылып та бетми, Иван терсәге белән энеләренә төртә, тегеләр бу оятсызлыкка артларын борып яталар да, шул хәлдә йоклап та китәләр. Бераздан ыгы-зыгы тына, Степан чаршау артыннан чыга да, Иван йөгереп китереп биргән суны тустаган кырыннан гына эчеп, аның арт чүмеченә берне тамызып, нидер ырлый-ырлый чыгып китә. Ольга белән Иван, бер-берсенә карамыйча гына, лавкада яткан төенчекне алып, үзләре генә белгән җиргә җыялар. Бик кадерле ул аларга, яшәү чыганагы, тамак туклыгы. Белер иде Иван Степанны нишләтергә, ләкин тагын ике кечкенә энесе бар, үзенең дә буй җиткереп, корсакның гел үкереп, ашарга сорап торган вакыты. Югыйсә Степан текә яр буеннан үткән сукмак буйлап кайта өенә, уң якта адәм биеклеге әрем, кычыткан үскән, шул яктан чүп үләне арасыннан кулны гына чыгарып төртәсе, көчкә сөйрәлеп кайтучы исерек ир аска, бала башы зурлыгындагы чуер ташларга мәтәләчәк. Үлмәсә дә, кеше булмаячак бүтән. Урынын да карап куйды, сукмактан күренмәслек итеп юл да ясап куйды инде Иван, ләкин... Ләкин түзәргә булды, ач килеш йоклап китә алмаячагын белә ул. Җай котәргә, җай! Чыкмый калмас.

Җиңү көнен Иван уналты яшен тутырып каршылады. Чагыштырмача тук тормышта яшәгәнлектән, ул иптәшләреннән гәүдәгә зурлыгы, җилкәләренең киңлеге белән аерылып тора иде. Куллар көрәк хәтле, беләкләр ныклы, яшьтәшләре элекке кебек аны мыскыллау түгел, хәтта күренмәскә тырышып йөриләр, чөнки очраган саен ул аларны җирдә тәгәрәтеп йөртә, балчыкка, сазга буяп бетерә. Классташларының күбесе, моның ир бала өчен хурлыклы икәнен белсә дә, үксеп-үксеп елап бетә. Иван күбрәк өлкән егетләр арасында булды, дөнья күргән ирләрнең тормышта күргән гыйбрәтле дә, кызыклы да тарихларын тыңлады. Фронттан кайткан ирләрнең анда нинди кыен хәлләрдә калып, аннан ничек чыгулары, нинди шартларда яшәүләре, үлем белән күзгә-күз очрашулары хакындагы хикәяләр түгел, ә тыл хезмәтендә булганнарның нәрсә урлаулары, интендант офицерларның ничек оста итеп төрле махинацияләр аркылы акча, байлык туплаулары, тәмле ашап, матур яшәүләре кызыксынды-

Фото автордан

ра иде. Боларны ул үзенә сеңдереп кенә барды, хыялында үзен дәрәҗәле урында, зур мөлкәт иясе итеп күрде. Әйе (моны Иван үзе өчен ныклы хәл итте!), рәхәт яшәр өчен нәрсәгәдер түзәргә, кайдадыр, елыйсың килгәндә дә елмаерга, түбәнсетсәләр түзәргә, җай-форсат чыкса, ычкындырмаска өйрәнергә кирәк.

Сугыш бетте, ләкин ачлык чигенмәде. Сугыш тәмамланып ике-өч ел үтүгә, Иван авылга җәйге каникулга кайтты. Бу вакытта ул өлкә үзәге булган шәһәрдә урнашкан, хәрби ведомство карамагында булганга күрә студентлары көненә өч тапкыр ашату һәм стипендия белән тәэмин ителгән авиация техникумы студенты иде. Нигездә ир балалардан торган коллективта ул үз урынын тиз тапты, комсомол җыелышларының берсен дә калдырмады. Төгәл фәннәргә сәләте булганлыктан, укуын да җиңел укыды, шуңа күрә техникум җитәкчелеге каршында тиз арада ышаныч казанып, яхшы исәпкә керде. Иван завхоз белән дуслашып алды. Хуҗалык эшләрендә аның уң кулына әверелде, тегесе үз йорты белән тора икән, Иван кичләрен аларга барып мал карашты, яз-көз бөтен бакчасын казып бирә торган булды. Шуңа күрә ул авылга яхшы кәчтүм-чалбар, күнитек киеп кенә түгел, шактый калын чемодан да күтәреп кайтты. Монда энеләренә диган, киелгән булса да әле яхшы сакланган аяк киемнәре, пальто кебек әйберләрдән тыш, әнисенә бишмәтлек материал һәм сатарга диган ситсы төргәге дә бар иде.

Август кергән иде инде. Иван, урманга барып, гөмбә карап кайтырга уйлады. Нәрсә булмас дип, балта да кыстырды. Төшкә хәтле йөрде, гөмбәле җирләргә үзе генә барырлык итеп юл билгеләре ясады. Быел гөмбә булыр, әз генә яңгырлар кирәк, хәзер тибеп чыгачак, Ходай кушып. Димәк, кышка тагын, иш янына куш дигәндәй, теш арасына кыстырырга әйбер булачак. Алла боерса, дип куйды Иван. Техникумда атеизм укытсалар да, ул күңеленнән укытучы белән килешми, хәтта эчтән генә аның белән бәхәсләшеп тә утыра. Аның фикеренчә, дөнья артык катлаулы, фән аңлатмаларына гына сыеп бетми. Менә бу кырмыскаларны гына кара... Ул чүгәләп ояны күзәтә башлады. Ничек шулхәтле оешкан төстә эшләргә мөмкин?! Фән эшче, солдат кырмыскалар турында сөйли, ояларының төзелешен аңлата, ләкин алар бит, нindидер күзгә күренмәс көчкә буйсынып, шулхәтле төгәллек белән эшли, яши һәм үлә. Менә бу көчне фән тотып ала да, аңлата да алмый. Яки менә кошларны алыйк... Аларның сөяк эчләре буш, чөнки шулай аларның очар өчен гәүдәләре җиңеләя. Моны эволюция белән аңлаталар, ләкин каян һәм ничек шулай сөяк эче буш булган кемсә дөньяга килгән соң? Шундый уйлар белән як-ягына караган иде, кайтыр якта кинәт бер карамчык шәйләнде. Иван сагаеп балтасын кулга алды, сак кына атлап шул якка китте. Караса, Степан. Агачка аркасы белән сөялеп, җирдә утыра. Күзләре йомык, чырае гайре табигый ак. Якында кемдер барлыгын сизеп, көчәнеп кенә күзләрен ачты:

– Иван, – диде ул пышылдап, – йөрәк...

Степанны урыныннан алганнар, ул хәзер үз көнен үзе күрә. Пенсия яше әле җитмәгән, колхоз эшендә дә ирләр арасына сыймый, фронтовиклар үзләре ут эчендә йөргәндә аның монда ниләр кыланганын ишеткәннәр инде. Лука исә бөтенләй кайт-

Иллюстрация: А. Шевелев картинасы

мады, кемдер аркылы гына аның исән, кайдадыр иксез-чиксез Россия киңлекләрендә икенче гаилә корып яшәгәнлеген ишеттерделәр.

– Иван, – дип янә эндәште элеккеге рәис, – су бир.

Иван як-ягына карады. Урман тынлыктан зыңлап тора сыман. Егет авыруның бер як җилкәсенә төрткән иде, тегесе бернинди каршылык күрсәтмичә шуып китте дә аркасына ауды. Иван үкчәсе белән Степанның күкрәгенә басты, тегесенең авыртуга чыдый алмаудан иреннәре чалшайды.

– Сволочь! – дип пышылдады ул, соңгы көчләрен җыеп.

Иван басымны көчәйтте, хәзер ул ике аяклап ирнең күкрәгенә менеп баскан иде. Степанның сулышы тонык гырылдауга әверелде, хәлсез бармаклары белән Иванның балтырларына ябышты. Кинәт бер мизгелгә ул күзләрен ачты, бу элеккеге Степан иде, карашы – ачык, усал. Иван, сискәнеп, сикереп төшеп качарга гына җыенган иде, шул ук секундта Степанның күз кабаклары кире ябылды, чабата бауларына ябышкан бармаклары хәрәкәтсез калды.

Степанны бер атнадан соң гына таптылар. «Йөрәк», – диде врач. Авылда кайгыручы булмады бугай. Иван гына әнисенең кызарганына игътибар итте, әмма эндәшмәде.

***

Бозда аягы таеп чалкан барып төшкән Иван Лукичның сыны катты, арт чүмече бәрелүдән башы гүләде, күктәге ай ике булып күренде. Бераздан кемнеңдер үзенә эндәшкәнен абайлады. Ул арада көчле куллар, ике култык астыннан тотып, күтәреп бастырдылар. Кинәт басудан башы әйләнеп киткән Иван Лукич, кулларын ике якка җәеп, тигезлеген сакларга тырышты, карашын бер фокуска җыярга маташып, тавыш килгән якка текәлде. Аңа ачык, бигүк чибәр булмаса да, ирлек, ышанычлылык бөркелеп торган каратут егет карап тора иде.

– Кем син? – дип хәлсез генә сорады Иван Лукич, егылганда читкә очкан затлы, очлы башлы каракүл бүреген эзләп карана-карана.

– Менә бүрегегез, – диде бер кулы белән аның җилкәсеннән тоткан килеш егет. – мин Айдар Әюпов. Сезгә, академиягә, авиация институтыннан практикага килгән студент.

– Ә-ә, – Иван Лукичның әле бәрелгән башы бик нык шауласа һәм авыртса да, уйлау сәләте кайтты, – ә, Әюпов, сез безнең кафедрадан курс эше дә алдыгыз бит әле.

– Әйе, әйе, – Айдар академикның хәле яхшырганга сөенде бугай. – Шул эш буенча китапханәдә утырып, соңарып чыккан идем, карыйм, алдарак сез барасыз. Ул арада таеп та киттегез, барып та төштегез. Менә йөгереп килеп җиттем. Әйдәгез, озатып куям, йә тагын бәла чыгар.

Иван Лукич юл буе бозны ватмаган дворникларны сүгеп кайтты. Гадәттәгечә фатир аны ялгыз салкынлык белән каршы алды. «Өйдә ямь таба белмәделәр инде», – дип уйлап куйды Иван Лукич кайдадыр йөргән хатыны белән кызы турында.

– Рәхмәт, – Иван Лукич, ботинкаларын салып, Айдарга борылды. – Иртәгә нинди көн әле? Шимбәме? Алай планнарың булмаса, курсовоеңның сызымнарын алып кил әле, карап чыгарбыз. Хәзергә хуш!

Иван Лукич, боегып кына, бай итеп җиһазланган, ләкин ямь булмаган күп бүлмәле фатирының түренә үтеп, йокы бүлмәсенә кереп ятты.

– Айдар, – дип мыгырданды ул, – Әюпов. Татар малае, Казанда укыса да, сәләтле студент буларак аны практикага Мәскәүгә юллаганнар.

– Ыһы, – дип, үз-үзенә сөйләвен дәвам итте Иван Лукич, – сәләтлеме, юкмы – анысын шайтан белә. Сәләтлеләр күп алар, ә менә егетебез, Мәскәү тормышын күргәч, монда калырга тырышачак. Әйе, бу сиңа хәерче Казан түгел, ә сиңа, туганкаем, моның өчен ярдәм кирәк булачак. Менә бит, сиңа кинәт кенә чикләвекле имән аварга тора бит әле...

Иван Лукич калын юрганын иягенә хәтле тартып куйды. Батареялар да кайнар югыйсә, нишләптер тәне туңа. Әллә ялгызлыктан бу арканы өшетә торган суык, әллә картлыктан.

Техникумны тәмамлап, комсомол юлламасы белән Мәскәүгә укырга килгәндә Иван салкынны, эссене бар дип тә белми иде. Тәнгә ит кунган, ашказаны күгәргән кадакны да эшкәртә алыр сыман, укырга омтылышы һәм тырышлыгы ун кешегә җитәрлек иде. Башкала масштабын, монда яшәүчеләрнең амбицияләрен һәм перспективаны ул тиз аңлап алды. Монда завхоз белән генә вакланмаска, монда, монда... Монда кешеләр, шәхесләр зур, эре, болар тауны тауга бәреп эш итә, менә шулар арасына керергә кирәк, ул вакытта хуҗалык бүлеге мөдире үзе синең белән дус булуны, сораган әйбереңне өеңә китереп бирүне мәртәбәгә санаячак.

Укуы яхшы булды, ләкин аңа уку максат түгел иде. Ул Мәскәү тормышын күзәтте, иптәшләрен өйрәнде, әңгәмә-сөйләшүләрне бик игътибар белән тыңлады. Карьера, тормышта уңышка ирешүчеләр турында сәгатьләр буе гәпләшергә әзер иде. Һәм җай көтте. Аның инануынча, язмыш ага һәркемгә күтәрелергә мөмкинлек бирә, аны күрә һәм эләктереп алырга гына кирәк.

Һәм Иван аны күрде бугай, һәрхәлдә, аңа шулай тоелды. Биеклеккә, болытлар артында яшәүчеләргә баскыч аңа үзләрен

укытучы профессорның кызы рәвешендә юлыкты. Татьяна этисе янына еш килә, Иван исә һәр дәрестән соң профессорның күрсәтмә әсбапларын кафедрага китерешә, һәм алар шунда очрашалар. Тора-бара шаян сүзләр әйтелә, үз итеп, беренче авыз сүз дә алыша башлыйлар. Әкренләп Иван кыюланды, инде кандидатлык дәрәҗәсен яклап өлгергән, олыгаеп баручы кыз башта яшь студентның үзенә игътибар күрсәтүеннән кычкырып көлде. Аннан уйга калды.

– Ак атка атланган принц көткән кызның, гадәттә, ишеген пенсия китерүче почтальон шакый, – диде әнисе. Иван белән яшь аралары һәм статус дәрәҗәләре туры килмәвен аңласа да, Татьяна аның белән гаилә корырга ризалык бирде. Бәхетле булдымы ул, юкмы – моны Татьяна аңламады да, бу хакта уйламады да. Аның этисе дә, әнисе дә төп мәскәүлеләр иде, алар һәрвакыт исәп белән яшәделәр. Алар гаиләсендә хисләргә урын булмады, һәрнәрсә нинди дә булса максатка ирешүгә корылган планга буйсындырылган иде. Иң мөһиме – кеше каршында барысы да яхшы булсын. Әйе, бу яктан Татьянаның барысы да яхшы – ире бар, кызы үсеп килә. Иван профессор бабай ярдәме белән аспирантурада калды, кандидатлыгын яклады. Үҗәтлек, тырышлыгы белән докторлык диссертациясен дә җиңеп чыкты. Хәмер, тәмәке белән мавыкмады, хатын-кыз белән чуалмады. Хәзер, монысын инде кычкырып йөрмиләр, монысы инде аның яшерен эшләнелә. Ләкин ул-бу булган очракта да Татьянаның исе китмәс иде, Иванга карата бернинди хис тә булмады аның. Уртак сүзләре, фикерләре дә юк иде. Иван һәрвакыт нindидер интригалар белән яшәде, һәрвакыт кемгәдер каршы көрәште, гел нindидер Фәләневнe сүкте, алардан зарланды, нindидер Фәлән Фәләнечне мактап, аның даһилыгына сокланып яшәде. Ләкин бу фамилияләр еш үзгәреп тора иде.

Иван да максатына иреште: Мәскәүдә төпләнде, рәхәт, иркен тормыш алып бара. Хәзер инде ул Иван Лукич, фәнни даирәдә саллы сүзе бар кеше, җил уңаена йөри белүе, кирәкле кешеләр белән дуслыкка маһирлыгы академик исемен дә җилкәсенә якты. Барысы да әйбәт, ул иң югары дәрәҗәләргә ирешә, ләкин соңгы вакытта күңелендә нindидер бушлык сизә башлады. Әледән-әле үзенә күз ташлый, нәрсә җитмәгәнен, ни кирәклеген аңларга тырыша иде. Шул төшенкелектән арынырга теләп, ул бервакыт туган ягына да кайтып килде, әнисенең каберенә барды. Авыл бетүгә бара икән... Яңа өйләр бик сирәк, күбесе Иван чыгып киткәндәге йортлар, һәм алар да, соңгы көннәрен яшәгәнлекләрен белеп, кичләрен тәрәзәләре белән моңсу гына җемелди. Трассадан борылып авылга керә торган 10-15 чакрымны Иван Лукич «Жигули»е белән ике сәгать кайтты. Яңгыр гына яумасын, моннан чыгып булмаячак, дип уйлады. Авылдан ул тагын да күңелсезләнеп килде, ләкин күңел бушлыгының сәбәбен аңлаган кебек булды. Ялгыз икән ул, берүзе. Эшендә коллегалары гына, дуслары юк, өйдә – хатынының гәүдәсе генә, күңеле аның белән түгел. Кызы да үз уйлары, үз дөньясы белән яши, эти аңа акча бирүче генә. Бөтен ирешкәнe, бөтен уңышларын уртаклашыр кеше юк. Иван Лукич кинәт үзен бик тә матур, бик тә кыйммәтле уенчыкка ия булган, әмма бу уенчыгы ватылган бала кебек сизде. Әйе, уйнар, бүлешер кешесе юк, әйе, матур тәтәй бар, ләкин ул эшләми, хәрәкәтләнми, ул аны тоткан да утыра.

Бүген ул Айдар белән кайтканда беренче тапкыр нindидер сәер хис, кайгыртучанлык тойды. Айдар һич зарланмыйча, аны култыклап, өенә хәтле озатты, Иван Лукич башы әйләнүдән туктап торган вакытларда сабыр гына көтте, иренмичә юл аркылы йөгереп чыгып, кибеттән шешә белән су алып килде. Бүреген кагып кигерде, перчаткаларын озак кына эзләде, аларны кардан чистартып бирде. «Яхшы билге аласы килә» дип, боларны рациональ яктан бәяләргә тырышты Иван Лукич, ләкин моның алай түгеллеген үзе дә белә иде. Әюпов аңа бәйле түгел, ул практикада гына, бер айдан Казанына кайта да китә. Курс эше җитәкчесе дә авторитетлы кеше, ул аны рәнҗетергә бирмәячәк...

Иллюстрация: Н. Позднеев картинасы

КАРТАЙМАС ПӨШӘҢГӘР

ПӨШӘҢГӘР

Фото: Лилиана Вәлитова

Арча районынында Пөшәңгәр исемле авыл бар. Арчаның үзеннән илле чакрым ераклыкта урнашкан ул. Ә Мари Эл Республикасына якын: күрше мари авылына Пөшәңгәрдән бер чакрым гына. Чик буендагы татар авылы ничек яши? Нинди шатлык, борчулары бар? Авылга баргач, әнә шуларны белештек.

Руфия Фазылова

ЯШЬ УКЫТУЧЫЛАР КАЙТКАН

Арчаны узгач та Пөшәңгәргә бер сәгать килдек. Юл кырыенда башта Кырлай, аннан Шушмабаш авыллары калды. Һаман барабыз да барабыз. Балтачка егерме дүрт чакрым дигән язуны күреп алдык. Димәк, Пөшәңгәр Балтачка якынрак булып чыга. Йөз утыз чакрым араны узып, ниһаять, авылга килеп җиттек. Менә ул җыйнак, төзек Пөшәңгәр!

Күзгә ташланган беренче әйбер – социаль объектларның барысы да яңа. Авылга кергәч тә, башта башлангыч мәктәп белән балалар бакчасы кала (икесе бер бинада урнашкан), аннан соң – кибет, инде үзәк юлдан тагын алга таба барганда, мәдәният йорты балкып тора. Аларда әле Яңа ел рухы сизелә – һәркайсы бизәлгән. Хәер, Пөшәңгәрдә йортлар да аллы-гөлле утларга күмелгән. Баксаң, ярыша-ярыша конкурска әзерләнгәннәр икән. Авыл җирлеге идарәсе «Бизәлгән иң матур йорт» исемле бәйге игълан иткән. Аерым гаиләләр бигрәк тә тырышып эшләгән.

1

Башлангыч мәктәп 2004 елда сафка баскан.

2

Мәктәптә шахмат уеннарына зур игътибар бирелә.

3

Балалар бакчасына 13 сабый йөри.

4

– Мәктәп белән бакча бер бинада булгач уңайлы, – ди директор Гөлназ Котдусова.

Авыл белән танышуны башлангыч мәктәптән башладык. Беренче карашка аны башлангыч мәктәп дип уйламыйсың да: бик зур ул. Мәйданы да бер гектар икән. 2004 елда сафка баскан.

– Төзелә башлаганда ук шундый проект белән эшләнде, – диде башлангыч мәктәп-балалар бакчасы директоры Гөлназ Котдусова. – Бер ягында – мәктәп, икенчесендә балалар бакчасы урнашкан. Бүгенге көндә дүрт сыйныфта егерме укучы укый, ә бакчага унөч бала йөри. Бөтен бәйрәмнәрне бергә үткәрәбез. Нәниләр хәтта спортзалда шөгыльләнергә дә безгә керә. Шул рәвешле бакча балалары укырга кергәнче үк мәктәпкә ияләнә тора.

Директор белән сыйныфларны карап чыктык: иркен, якты, җылы... Балалар барлык фәннәрне татарча укый икән. Аннан соң бишенчегә күрше Апаз урта мәктәбенә баралар. (Өч кенә чакрым ераклыктагы авыл.)

– Бик зур шатлыгыбыз бар – яңа уку елына авылга ике яшь укытучы кайтты, – дип таныштырды Гөлназ Муллануր кызы. – Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогика көллиятенә махсус барып, яхшы укучы ике кызны сорадым. Аллаһның рәхмәте, шундый талантлы кызлар булып чыкты. Белемле дә, сәләтле дә, мәдәният йортында узган чарада да гел алар.

Яшь мөгаллимнәрнең берсе – Айсылу Гарәпшина. Директор Гөлназ Котдусова белән беренче һәм өченче сыйныфларны бүлеп укыталар. Моннан тыш, Айсылу башлангыч мәктәптә инглиз теле дәресләрен дә алып бара. Сөйкемле яшь мөгаллимә тумышы белән Балтач районының Норма авылыннан. Атна азагында туган авылына кайтып йөри. Икенче укытучы Нәргизә Гыйниятуллина исә Арча районының Көтек авылыннан. Ул да әти-әнисе янына атна аза-

гында гына кайта. Яшь укытучылар Пөшәңгәрдә бер әбигә яшәргә кергәннәр.

– Нәргизә белән көллияттә дә гел бергә булдык, – диде Айсылу Гарәпшина. – Хәзер менә бергә читтән торып укырга кердек, Чаллы дәүләт педагогика университетында белем алабыз. Безнең эштә югары белемсез булмый бит.

– Бүген бөтен яшьләр диярлек шәһәргә китү ягын карый. Ә сез ничек авылны сайладыгыз? – дим яшь мөгаллимәгә.

– Мин шәһәрне бер генә дә яратмыйм, шуның өчен дә, кулга диплом алгач, берәр авылга эшкә кайтырмын дип уйлаган идем. Гөлназ Муллануровна, көллияткә килгәч, безнең белән сөйләште. Нәтиҗәдә, дус кызым белән Пөшәңгәрне сайладык. Авылны тиз арада үз иттек, коллективыбыз да әйбәт. Эшебезне бик яратабыз.

– Яшьләр белән күңелле, аларга ияреп үзебез дә яшәреп йөрибез, – дип сүзгә кушылды Гөлназ Котдусова. – Ничек тә бу кызларыбызны авылда калдырырга инде. Берәр егет тә табып җибәрсәк. (Көлә.)

Яшь мөгаллимәләр белән танышкач, ирексездән балачакка кайттым. Без укыганда да шулай «квартирда» (югыйсә авылда өйләр бит, ни өчен шулай әйткәннәрдер) яшәүче укытучылар бар иде. Аларның күбесе шулай авылда калды да. Һичшиксез, бу чибәр кызлар Пөшәңгәр башлангыч мәктәбенә яңа сулыш алып килгән. Читтән күзәткәндә бу аеруча күренә. Яшь укытучыларга озак еллар биредә сөенеп эшләргә язсын. Аның өчен биредә барлык мөмкинлекләр дә бар, иң мөһиме – балалар кимеми. Узган ел гына Пөшәңгәрдә биш сабый туган. Ә бакча яшендәге сабыйлар саны егермегә якын. Авылда яшь гаиләләрнең тагын барлыгын исәпкә алсак, башлангыч мәктәпнең киләчәге өметле икәнен күрәбез.

ЭШЛЕ АВЫЛ

Әлбәттә, Пөшәңгәр күрше Апаз, Шушмабаш авыллары белән чагыштырганда кечерәк. Ләкин авыл гомергә мул тормыш белән яшәгән. Һәм халык саны да күп булган. Бүген дә биредә 347 кеше гомер итә, 128 хуҗалык бар. Күп итеп мал, кош-корт асрыйлар. Ярымфабрикатлар ясап сатучы Галәветдиновлар сигез авылдашларын эшле иткән. Иттән ни генә әзерләми алар! Тулы бер цех ачканнар.

Авылда тагын «Ватан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте бар. Эш шунда ки, биредә колхозлар системасы юк ителмәгән. Исемнәр заманчалаштырылса да, эш алымнары барысы да элеккечә калган. Ягъни җирләргә хуҗа бар, фермалар да ташландык хәлгә килмәгән. Шуның өчен дә авылда мескенлек юк.

Пөшәңгәрнең иң өлкән ир-аты Рәшит Зәйнәгетдинов янына кердек. Сиксән алты яшен тутырган. Ул гомере буе колхозда эшләгән. Җәмәгате Гатифәбану апа белән алтмыш бер ел яшиләр. Дүрт кыз тәрбияләп үстергәннәр, бер уллары белән бер кызлары кечкенә чагында ук мәрхүм булган.

Рәшит абый әле җомгадан кайтып, өс-башын алыштырып йөри иде. Башта Гатифәбану апа белән аралаша тордык.

– Мин бабайга караганда өч яшькә яшьрәк, сиксән өчне тутырдым, – диде әбекәй. – Бабаем әле егетләр кебек, Аллаһка шөкер. Ә менә миңа инсульт булды, бер кулым начар эшли. Әле ярый кызлар бар, дим, икесе – Балтач районында, берсе – Арчада, берсе Казанда яши. Атна саен кайтып, өйләрне җыештырып, ашарга пешереп китәләр. Кызлы кеше бәхетле ул, кызым. Үзләре дә игелек күрсен.

Гатифәбану апа да тумышы белән Пөшәңгәрнеке. Гел совхозда эшләгән: күбрәк төзелештә хезмәт куйган, кирпеч суккан. Рәшит абый исә гомере буе шофер булган, трактор йөрткән.

– Әйдә, нәрсә сөйлим? – дип, Рәшит абый да балкып безнең янга килеп утырды.

– Авылның үткәне кызыксындыра, – дидем.

– Безнең авыл гомергә әйбәт яшәде, кызым. Ник дигәндә, авылда 1957 елда «Северный» совхозы оешты. Без таякка эшләмәдек, ә хезмәт хакы алып көн күрдек. Шуңа да Пөшәңгәр халкының тормышы яхшы булды. Совхоз иген дә үстерде, күп итеп мал да асрады. Кыска-

5
– Авылны тиз арада үз иттек, коллективыбыз да әйбәт, – ди Айсылу Гарәпшина.

6
Нәргизә Гыйниятуллина без килгәндә физкультура дәресен алып бара иде.

7

Гатифәбану һәм Рәшит Зәйнәгетдиновлар алтмыш бер ел бергә яшиләр.

8

Сәйфуллиннар – авылның иң ишле, күркәм гаиләсе.

9

Гаилә тиздән яңа йортка күчәргә уйлый. Төп нигез янәшәсендә бик зур йорт салганнар.

сы, эшле дә, ашлы да булдык. Әле язгы чәчүгә чыкмый башлаганыма өч-дүрт кенә ел. Сиксән ике яшемә кадәр трактор йөрттем. Хәзер дә чыгар идем, яхшысынмыйм. Бабай җүләрләнгән диярләр. (Көлә.)

Совхоз оешканчы да бу якларда халыкның шөгыле булган – чыпта тукыганнар, кирпеч сукканнар. Инде XX гасыр башында ук ирләр, җирдән гипс казып алып, пыяла заводы тоткан байга алып барып саткан. Эш шунда ки, Пошәңгәр белән Апаз авылы арасында гипс (известь) ятмалары булган. Халык бу мөмкинлекне кулдан ычкындырмаган.

– Чыпта сугуны бик яхшы хәтерлим, – диде Рәшит абый. – Юкә мунчаласыннан ясыйлар иде аны. Һәр гаилә диярлек шуның белән шөгыльләнде. Мунчаланы стенага элеп куялар да, ыргак белән бер-берсенә кертеп, үреп баралар. Аннан аны капчык формасында тегеп тә куялар. Бу инде хәзерге полиэтилен капчыклар урынында йөргән.

– Без дә шулай эшли идек, – дип сүзгә кушылды Гатифәбану апа. – Әле кыз чагымда да чыпта сукканны хәтерлим. Заманасына күрә аның өчен яхшы түлиләр иде. Шуның өчен авылның һәр йорты диярлек чыпта тукыды. Аннары кирпеч сугу башланды. Пошәңгәр кирпеченә ихтыяҗ зур иде. Тирә-яклардан да килеп алдылар. Әле хәзер дә авылда да, Арчада да без суккан кирпечтән салынган йортлар бар.

Бабай белән әбекәй Пошәңгәрдә үткән яшьлекләре, авыл тормышы турында бик озаклап сөйләделәр. Зар белми торган кешеләр, моңа өстәп, Рәшит абый җор телле дә. Балалар кебек ихлас көлеп җибәрүе генә ни тора!

– Безнең урамда унбиш бала бар, менә мин шуларга карап бер дә картаймыйм, – диде ул.

«БАЛАНЫҢ АРТЫГЫ БУЛМЫЙ»

Рәшит абый шаярмаган, алар урамында чынлап та унбиш бала икән. Бер гаиләдә биш, икенчесендә дүрт, өченчесендә өч, аннары ике һәм бер бала үсә. Җәйләрен әле бу малай-кызлар янына тагын шуның кадәр бала җыела. Менә бәхет кайда ул!

Шушы гаиләләрнең иң ишлесе – Сәйфуллиннар. Бер түбә астында тугыз кеше яшиләр. Габдерәсүл абый белән Тәнзилә апа, уллары Алмаз, аның җәмәгате Раилә һәм биш бала. Яшь гаилә 2010 елда никахлашкан. Унөч ел эчендә бер-бер артлы дүрт кыз һәм әле ике ай элек кенә ир малай алып кайтканнар. Балаларның исемнәре бик матур: Зөбәйдә, Фирүзә, Газизә, Нургизә, Хәсән.

– Балаларга исемнәрен кем кушты? – дим.

– Үзем, – диде Алмаз. – Әлбәттә, Раилә, әтиәниләр белән килештереп инде.

– Өйдә кеше күп булгач, бала үстерергә җиңелрәкме әллә ул? – дим.

Сорауга Тәнзилә апа җавап бирде:

– Баланың артыгы юк, сеңлем. Һәркайсын көтеп, сөенеп алдык. Аллаһы Тәгалә бирмәсә, бала тумый. Безнең балаларны әнә ничек бүләкләде. Күптән түгел бәби чәе үткәрдек. Иремнең энесе: «Нәселне дәвам итүче малай туды», – дип хәтта елады. Без исә кызга да, малайга да бик сөенәбез. Тигезлектә, сөенеч белән үстерсеннәр. Күбәйгән саен балаларны күбрәк яратасың икән.

Габдерәсүл абый белән Тәнзилә апа бер ул, бер кыз үстергән. Кызлары гаиләсе белән Арчада гомер итә. Бер мәл ир белән хатын икесе генә яшәгән. Уллары Алмаз хәрби хезмәттән кайткач та, Казанда янгын сүндерү бүлегендә эшләгән. Ә бер очрак егетне туган нигезенә кайтырга мәҗбүр иткән.

– Казан дәүләт ветеринария академиясен тәмамладым мин, – диде Алмаз. – Тик Казанда һөнәрем буенча эшлисем килмәде, шуның өчен ГТХМ (МЧС) системасына бардым. Шулай матур гына эшләп йөргәндә, эти, аттан егылып, бил сөяген сындырды, аннан инсульт булды. Әнине авыр чакта ялгызын калдырасым килмәде, туган авылыма кайттым. Маллар да күп иде. Менә шулай итеп шәһәр тормышыннан

баш тартырга туры килде. Аннан Раилә белән таныштык, озакламый өйләнештек. «Әти-әниең белән бер йортта яшәргә каршы түгел», – диде. Аллаһка шөкер, ишле гаилә булып унөч ел матур гына яшәп ятабыз. Бер аш бүлмәсенә ике хатын-кыз сыймый дисәләр дә, бездә сыя. Аларның эшләренә әти белән кысылмыйбыз, икесе үзара сөйләшәләр, килешәләр.

Габдерәсүл абыйның бүген сәламәтлеге чагыштырмача әйбәт, Тәнзилә апа белән малларны карый. Биш савым сыеры, берничә бозаулары бар! Җәен күп итеп кош-корт үстерәләр икән. Алмаз исә «Ватан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятендә хезмәт итә, көне буе эштә. Өй мәшәкатьләре күбрәк Раиләдә икән.

– Килен булып килгәч тә: «Балакаем, менә өч суыткыч. Нәрсә пешерәсең килсә, пешер, үзегезчә эшлә», – дидем. Киленемә күз тидерүдән куркам, сөбханалла гына, – диде Тәнзилә апа.

Раиләне күзәтәм: ике айлык баласын күтәреп иплэп кенә безнең янга чыгып утырды. Биш бала тапкан һәм баккан батыр ана, каенатакаенана белән яшәүче сабыр килен, уңган хатын ул. Хәер, Тәнзилә апага да тел-теш тидерә торган түгел: ул бу йортның кояшы кебек. Барысын да белеп, кайгыртып тора. Бер кызык хәлне сөйләп шаккатырды әле:

– Җәй буе бөтен кунакка кайткан балалар да бездә. Алмаз хәтта арт якка агач беседка ясап бирде, шунда мәш киләләр. Җәен ун литрлы чиләк белән коймак пешерәм. Барысын да сыйлыйм. Ул рәхмәт әйтәләр, сөенәләр инде. Балаларны бик яратабыз, аның бит вакыты бер генә була. Аннары үсеп китәләр дә, чакырсаң да килмиләр. Үзебезнең малай белән кыз үскәндә дә бөтен урам баласы бездә иде, сүз әйтмәдек.

Ишле гаилә тиздән яңа йортка күчәргә уйлый. Төп нигез янәшәсендә бик зур йорт салганнар. Монда һәр баланың үз бүлмәсе булачак. Дөрес, әле яшь торган өйләре дә начар түгел. Ләкин Алмазның йорт саласы килгән. Кырык яшенә җиткән ир уртасы бөтен бурычын үтәгән: агач утырткан, йорт салган, улы да туган.

– Өлкәннәр дә яңа йортка күчәме, әллә биредә каласызмы? – дип сорап куйдым. Соңыннан үкенеп тә куйдым: мондый гаиләгә бу сорауны бирәләрме инде?!

– Алардан калсак, бабаем белән саргаеп үлбез, – диде Тәнзилә апа. – Без инде балалардан башка тормышны күз алдына да китерә алмыйбыз, чын менә. Ялгызлыктан Аллаһ сакласын.

...Пөшәңгәрдә яшь беләләр. Менә шулай дип кайттык сәфәрдән. Апаз авыл җирлеге башлыгы Раушан Котдусов та: «Җирлектәге иң бердәм, иң тырыш авылдыр ул», – диде. Шулайдыр, кешеләре белән аралашкач моңа ышанасың. Авылдан киткәндә тагын бер фикер туды: колхозлар системасы сакланып калган авыллар үлми, Пөшәңгәр – шуның ачык мисалы.

8

9

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

– Пөшәңгәргә иң беренче булып XVI гасыр азагы–XVII гасыр башында Биектау районы Сасмак авылыннан алты гаилә күчеп килгән, дип уйлыйбыз. Авылның өлкәннәре әйтүенчә, кешеләр бу яктан су буйлап йомычкалар агып килүен күргән һәм анда да авыл бардыр дип уйлаган. Инде әлеге җирләрне күргәч, бик ошатканнар һәм биредә төпләнергә уйлаганнар. Урманны кисеп, үзләренә йорт сала башлаганнар. Алар килгәндә монда дүрт-биш мари гаиләсе яшәгән. Алар мәҗүсиләр булган. Соңрак марилар да ислам динен кабул иткән.

Авылның исеме поши сую йоласы белән бәйле булырга тиеш дигән фараз бар. Әңгермеңгер вакытта авыл ир-атлары хайванны чалган һәм «Пөш - әңгәр» дигән исем калган, диләр. Бу хакта хәтта бәет тә бар.

(Рәйфә Сабирҗанова, Пөшәңгәр авылы китапханәчесе)

ПРЕЗИДЕНТЛАРГА ЛАЕКЛЫ БҮЛӘКЛӘР (0+)

ТРның беренче Президентына, Татарстан Рәисенә якын һәм ерак чит илләр лидерлары, Россия төбәкләре җитәкчеләре, мәдәният эшлеклеләре, дипломатлар нинди бүләкләр биргәннәр? Дәүләт сере дип уйлыйсызмы? Һич юк! Ваза һәм статуэткалар, корал, рәсем һәм графика, келәм һәм милли костюмнар бөтен кеше карасын өчен куелган. Россия, Малайзия, Япония, Согуд Гарәбстаны корал сәнгате үрнәкләре «Бүләк – мәдәниятләр дуслыгы символы» экспозициясенең бизәге булып тора. Раритетлар ТРның беренче Президенты һәм Дәүләт Киңәшчесе бүләкләре фонды һәм Татарстан Республикасы Рәисе Аппараты тарафыннан тапшырылган.

Сишәмбе–якшәмбе 10:00 сәгатьтән 18:00 гә кадәр
Җомга 11:00 сәгатьтән 20:00 гә кадәр
Татарстан Республикасы һәм татар халкы дәүләтчелеге тарихы музее
«Казан Кремле» музей-тыюлыгы

ШҮРӘЛЕГӘ ЯҢАЧА КАРАШ (12+)

«Шүрәле темасына кагылгач, мин һәрчак уйга кала идем. Борын-борын заманнарда кешеләр күзгә күренми торган ияләр, җен-пәриләргә ышанган. Аларның һәрберсенең үз урыны, үз максаты булган. Шүрәлене борынгылар урман сакчысы итеп белгәннәр. Бүгенге көндә дә Шүрәле әкият каһарманы буларак яшәп килә, әмма аның бу дөньядагы бурычы билгесез, мифына ышанучы калмады кебек. Нәрсәне саклый соң безнең көн Шүрәлесе? Бәлки мәдәниятебезнедер?

«Shurale: яңа фантазия» спектаклен эшләгәндә безне шундый хыяллар илһамландырды!» – дип сөйләде безгә либретто авторы Илгиз Зәйниев.

9 февраль 19:00 сәг.
«Әкият» Татар дәүләт курчак театры
Казан, Петербург ур., 57

ҺӘР ЗАМАННЫҢ ҮЗ ҖАН БАЕВИЧЫ... (12+)

Культуралы кеше булырга тырышып, Гаяз Исхакый комедиясенең төп герое Җан Баевич үзенең яшәү рәвешен тамырдан үзгәртә: гаиләсеннән, шул исәптән балаларыннан, нәселеннән, туган теленнән һәм гореф-гадәтләрдән баш тарта, хәтта исемен заманчага үзгәртә.

Ләкин төп геройның яңа тирәлеге, үз тамырларыннан баш тартуы аны зыялы, белемле кеше итә алырмы?

Гаяз Исхакый тарафыннан нәкъ 100 ел элек күтәрелгән милли үзенчәлекне саклау проблемасы бүген исә яңа төсмерләр ала һәм ул тагын да актуальрәк яңгырый. Гаяз Исхакый фаразлавынча, тагын 100 елдан соң булачак «Инкыйраз»га якынайдыкмы без?

Премьера!

31 гыйнвар, 18.30 сәг.; 1 февраль, 18.30 сәг.
К. Тинчурин исем. Татар дәүләт драма һәм комедия театры,
Казан, Горький ур., 13

афиша

Фото: tinchurinteatr.ru, tatar-inform.ru, russdramteatr.ru, kazan-kremlin.ru, karievteatr.ru, tatfil.ru

ПОЧТА МИНИАТЮРАСЫНЫҢ СЕРЕ (0+)

Казанның, гомумән Татарстанның истәлекле урыннарын чагылдырган марка һәм конвертлар, танылган рәссамнарның картиналары, шулай ук аларның эшләре сурәтләнгән почта түләү билгеләре – боларның барысын да уникаль «Марка сәнгате» күргәзмәсендә күрергә мөмкин. Маркалар коллекциясе Россиянең мәдәни мирасына һәм архитектура һәйкәлләренә, рәссам һәм мәдәният эшлеклеләренә, шулай ук илнең декоратив-гамәли сәнгатенә багышланган почта миниатюралары аша тәкъдим ителә.

«Манеж» Күргәзмәләр залы
«Казан Кремле» музей-тыюлыгы

ҖИР БЕЛӘН КҮК АРАСЫНДА (0+)

Глинка, Мусоргский, Римский-Корсаковның вокаль лирикасы җәүһәрләреннән төзелгән камера программасы әнә шулай атала. Башкаручылары да әлеге тыңдаучысез репертуарга туры килеп тора. Программмада Мария театры солисты, Франсиско Виньяса исемендәге Халыкара вокал конкурсы (Барселона, 2019), П.И.Чайковский исемендәге II Халыкара конкурс (Мәскәү – Санкт-Петербург, 2019) лауреаты Айгөл Хисмәтуллина, М.Глинка исемендәге XXVI Халыкара вокалистлар конкурсы (II премия, Казан, 2019), П.Лисициан исемендәге Халыкара конкурс (Владикавказ, 2013) лауреаты Эльза Исламова, һәм шулай ук М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры солисты, халыкара конкурслар лауреаты Артур Исламов катнаша. Концерт Ф.И.Шаляпин исемендәге Халыкара опера фестивале химаясендә уздырыла.

5 февраль, 19.00 сәг.
С. Сәйдәшев исем. Дәүләт Зур концертлар залы
Казан, Азатлык мәйданы, 3

ОЗЫН-ОЗАК СӘФӘР (18+)

Юл – ул универсаль метафора. Юл – кеше гомере, аның туганнан алып бакыйлыкка кадәр үткән юлы. Ул максатларга ирешү теләге дә, каршылыкларны җиңү дә. Билгесезлектән курку һәм туктаусыз алга омтылыш. Аерылышу һәм кайту символы...

Альберт Шакиров пьесасы буенча куелган спектакльдә юл – 70 яшьлек карт Сәфәргалинең татар авылы Черкиледән башкорт Актавына кадәрле маҗаралы сәфәре, һәм шул ук вакытта озак көтелгән, газаплар һәм тәүбә итүләр аша үз-үзенә кайту юлы да. Әлеге юлны пьесадагы һәр геройга үтәргә туры килә.

Авторның бер генә персонажы да уйлап чыгарылмаган. Ул алар белән үзенең журналистлык эшчәнлеге вакытында танышкан. Арада төрлесе бар, тик, нигездә, барысы да яхшы күңелләләр. Сәфәргали язмышына туры килгән вакыйгалар бик тормышчан, нечкә юмор белән сугарылган.

31 гыйнвар, 19:00 сәг.
Г. Камал исем. Татар дәүләт Академия театры,
Казан, Татарстан ур., 1

ХАНУМА: КЕМ ҖИҢӘР... (12+)

Туй традицияләрен үтәү элек-электән зур әһәмияткә ия булган. Тик мәхәббәткә кагылышлы мәсьәләдә традицияләргә таяну һәрвакыт урынлымы? Димләү – яшь парларга ярдәм итүме яисә яучы ярдәм итүме? Димләүче – яшь парларга ярдәм итүме яисә яучыдәгеләрнең бер максатымы?

Кайчандыр бик бай булган, ләкин бөлгенлеккә төшкән кенәз Пантиашвилины өйләндерергә йөргән ике димче – Кабато белән Ханума – кавышу тарихында тамашачыны шаһит итә. Ханума кенәзне Гулико исемле кәләш белән кавыштырырга тели. Ә Кабато исә кенәзне бай сәүдәгәр Микичның кызы Сонага өйләндерергә тырыша. Микич та кызын Пантиашвилига бирергә риза, чөнки аның кенәз титулына ия буласы килә. Сона исә Пантиашвилиның туганы Котэга гашыйк. Бер-берсенә гашыйк яшьләр кавыша алырмы?..

27 гыйнвар, 18:00 сәг.
Г. Кариев исем. Казан дәүләт яшь тамашачы театры
Казан, Петербург ур., 55 Б

ФАТИХ КӘРИМ – ОНЫТЫРГА ХАКЫБЫЗ ЮК...

Татар әдәбиятында фаҗигале язмышка дучар булган язучылар, шагыйрьләр байтак. Гаепләнүләр, аклаулар, газаплы үлемнәр... Һәркайсының үзенең тетрәндергеч тарихы бар. Әнә шундыйларның берсе Фатих Кәрим. Гыйнвар аенда башкалабызда татар җәмәгатьчелеге каһарман шагыйрьне зурлап искә алды.

Башкортостанда туып-үскән егет унбиш яшеннән тормышын Казан, Татарстан белән бәйли. Укый, иҗат белән шөгыльләнә. Унтугыз яшендә инде аны Казанда «Яшь ленинчы» газетасының (хәзерге «Сабантуй» журналы) редколлегиясе составына кертәләр һәм идарәнең җаваплы секретаре итеп билгелиләр. Аннан соң «Крәстиян газите» идарәсендә - әдәби хезмәткәр, «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә»), «Атака» (татар пролетар язучылары оешмасы басмасы) журналларында җаваплы секретарь хезмәтендә була. Шуннан тагын берничә басмада эшли. 1938 елның 3 гыйнварында кулга алына. Милләтчелектә, пантөркичелектә, буржуазияне яклауда һ.б. гаепләнеп, ун елга ирегеннән мәхрүм ителә. Берничә мөрәҗәгатьтән соң, СССР Югары суды Фатих Кәримнең эшен яңадан тикшерә. Һәм 1941 елның 1 декабрендә аны иреккә чыгаралар. Шул ук айда Фатих Кәримне сугышка чакыралар.

Татар шагыйре фронтта да язудан туктамый. Югыйсә яу кырының алгы сызыгында көрәшә, солдат һәм кече офицер, взвод командиры буларак Мәскәү яныннан алып Көнчыгыш Пруссиягә хәтле сугыш юлын уза. Ни аяныч, сугыш бетәргә санаулы көннәр калганда, 1945 елның 19 февралендә, Көнчыгыш Пруссиядәге соңгы сугышларның берсендә 36 яшьлек шагыйрь дошман ядрәсеннән һәлак була. Фатих Кәримне шундагы Туганнар каберлегендә җирлиләр.

Фотолар: Мария Вандышева, Милли музейның матбугат үзәге






Ф. Карим – поэт. 1944
19 февраля 1945 года погиб
на подступах к г. Кёнигсбергу
Ф. Карим – шагыйрь. 1944
1945 елның 19 февралендә
Кёнигсберг шәһәре янында хәрби бурычын
үтәгәндә каһарманнарча һәлак була
F. Karim - Tatar poet. 1944
Carrying out a co mbat mission, heroically died on the outskirts of Konigsberg on 19th of February, 1945
Самодельные тетради с фронтовыми стихами
поэта-героя Фатиха Карима. 1942-1943
Каһарман шагыйрь Фатих Кәримнең
фронт шигырьләре язылган кенәгәләре. 1942-1943
Hand made notebooks with front line verses
by the hero poet F. Karim. 1942 -1943

материалы о госпитале , сотрудниках, раненых. На родительской
конференции было рассказано директором нашей гимназии
Татьяной Петровной о планировании, оформлении этой выставки.
Летом работа была завершена.

ФАТИХ КӘРИМГӘ 115 ЕЛ ТУЛУГА БАГЫШЛАНГАН ШИГЪРИ-МУЗЫКАЛЬ КИЧӘДӘ ЯҢГЫРАГАН КАЙБЕР ФИКЕРЛӘР:

Ренат Харис, Татарстанның халык шагыйре:

– Фатих Кәрим сапёр булып хезмәт иткән. Безнең гаскәрләр үтеп керер өчен юлны миналардан чистартырга кирәк булган, шуннан соң гына атака башланган. Шундый хезмәттә булып та, ул 150ләп шигырь, тугыз поэма, ике повесть, бер пьеса иҗат иткән. Дөнья әдәбиятында мондый күренеш юк. Бөтен язучылар штабларда, фронт газеталары редакцияләрендә эшләгән, ә Фатих Кәрим менә шулай сугышкан. Шунысы сөенечле: аның бөтен язганы Казанга кайтып җиткән һәм сакланып калган.

Фоат Галимуллин, әдәбият галиме:

– Фатих Кәримнең кызы Ләйлә Кәримова белән Багратионовск шәһәреннән ерак түгел Фатих Кәрим һәлак булган урынга бардык. Анда шагыйрьнең истәлеген кадерләп саклыйлар. «Монда татар шагыйре Фатих Кәрим һәлак булган», – дип язып, таш куйганнар.

Багратионовск шәһәренең (хәзерге Калининград өлкәсе – ред. иск.) үзәк урамы Фатих Кәрим исемен йөртә. Шул урам буенча барганда, Туганнар каберлегенә килеп җитәсең. Анда җиде меңнән артык солдат-сугышчы җирләнгән. Шунда күмелгән һәр сугышчының үзәк аллея башында кабере торырга мөмкин иде. Ә менә алар Фатих Кәримне сайлап алганнар. Аның кабере үзәк аллея түрендә урнашкан. «Фатих Вәли улы Кәримов – татар шагыйре», – дип язып та куелган.

Маргарита Бәдретдинова, «Казанда исәпләү техникасы тарихы» музее директоры:

– Мин Фатих Кәримнең бертуган апасы Ада һәм кызы Ләйлә Кәримовалар белән якыннан аралаштым. Ләйлә Кәримова гомерен әтисенең иҗатын өйрәнүгә багышлады. Апасы Ада Кәримова белән Казан университетының физика-математика факультетында бер курста укыдык. Алар сөйләвенчә, Фатих Кәрим тоткынлыкта да шигырьләр иҗат итүен дәвам иткән. Хатыны Кадрия апа Ишукова, Фатих абыйның ГУЛАГтан җибәргән һәр хатын җыеп, аларны күчереп язып барган. Фронтта булганда да гаиләсенә хатлар язудан туктамаган. Ул хатларның һәрберсе бар. Шагыйрьнең гаиләсен ул яктан үрнәк итеп куярга була: Фатих Кәримнең барлык документларын, кулъязмаларын, хатларын саклаганнар.

КАЗАНДА ИҢ УҢАЙЛЫ КЕЙТЕРИНГ

Мәшәкатьсез генә тәмле һәм матур өстәл

Аш тактасына зәвыклап тезелгән ризыклар

Бәйрәмгә кадәр 2 сәгать кала да заказлар алу

Казан, Б. Урманче ур.,1
+7 (843) 203-45-00
+7 (927) 312 00 02

kazan.aigul-usmanova.ru
aigul.usmanova_kazan
aigul.usmanova1

Реклама. ИП Усманов Линар Марселевич

АКВАРИН®

Суда эри торган комплекслы минераль ашлама

фертигация
тамырдан тыш тукландыру
тамчылап сугару

АКВАМИКС®

Комплекслы микроашлама

орлыкларны эшкәртү өчен
тукландыруны көйләү
хлорозларны бетерү

КАЛИЙ МЕТАБОРАТЫ

БОРОТЭМ®

Суда эри торган борлы ашлама

тамырдан тукландыру
тамырдан тыш тукландыру
тамчылап сугару

ХЕЛАТЭМ®

Хелат формасындагы микроэлементлар

тамырдан тукландыру
тамырдан тыш тукландыру
тамчылап сугару

Fe 13% ЕДТА **Fe** 11% ДТПА **Fe** 6% ЕДДГА
Mn 13% ЕДТА **Zn** 15% ЕДТА **Cu** 15% ЕДТА
Ca 10% ЕДТА **Co** 13% ЕДТА **Mg** 6% ЕДТА

apk_volga
apk-v@mail.ru
@apk_volga.58
vk.com/id736033849
+7 (8412) 45 81 78
+7 (8412) 45 81 79

РЕКЛАМА

apk-volga.ru

«БУЙ ХИМИЯ ЗАВОДЫ» ААҖ вәкиле - «Идел буе АСК» ҖЧҖ
Сату офисы адресы: 440011, РФ, Пенза ш., Кече Бугровка ур., 17
Склад адресы: 440015, РФ, Пенза ш., Байдуков ур., 65